Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ
## поиски и открытия

Выпуск 6

Казань
2018

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# РУХИ МИРАС
## эзләнүләр һәм табышлар

6 нчы чыгарылыш

Казан
2018

УДК 908
ББК 63.2(=632.3)-8
Р 82

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

Басма Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлек буенча төп чаралар планын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы хөкүмәтенең матди ярдәме белән нәшер ителә

**Редколлегия:**
*И.Г. Гомәров (проект җитәкчесе һәм җаваплы мөхәррир), М.И. Әхмәтҗанов, З.З.Рәмиев*

**Төзүчеләр:**
*Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова*

**Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия** / редкол.: И.Г. Гомәров (проект җит. һәм җав. мөх.), М.И. Әхмәтҗанов, З.З. Рәмиев. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 6 нчы чыг. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-279-1

Җыентык татар халкының рухи мирасы нигезен тәшкил итүче әсәрләрне өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, татар текстларын өйрәнү барышында яңа тикшеренүләр белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Чираттагы чыгарылыш күренекле дин әһеле һәм галим Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) тормышы һәм иҗатына багышланган. Әлеге җыентыкта Ш. Мәрҗани хезмәтләре, аның эшчәнлеге белән бәйле архив документлары, XX гасыр башы татар газета һәм журналлары битләрендә аның турында басылган мәкаләләр, галимгә багышланган кайбер шигырьләр бирелә. Текстлар, кирилл язуына күчерелеп, укучылар игътибарына беренче тапкыр тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-279-1
© Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2018

# Кереш

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» китабының алтынчы чыгарылышы күренекле татар рухание һәм галиме Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) тормышы һәм эшчәнлегенә багышлана. 2018 ел дәвамында татар җәмәгатьчелеге бу мөхтәрәм затның тууына 200 ел тулуны билгеләп үтте: фәнни конференцияләр оештырылды, күргәзмәләр эшләде, китаплар нәшер ителде. Әлеге хезмәтне дә бу юлдагы бер адым дип бәяләргә мөмкин. Биредә Шиһабетдин Мәрҗанинең моңа кадәр нәшер ителмәгән яки гарәп графикасында кала килгән хезмәтләре, аның иҗаты турында XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында чыккан язмалар һәм башка характердагы материаллар туплап бирелә. Аларның күпчелеге хәзерге графикада беренче тапкыр нәшер ителә.

Китапның беренче бүлегендә Шиһабетдин Мәрҗанинең үз хезмәтләренә урын бирелде. Мәсәлән, аның 1865 елда Оренбург Диния нәзарәтенә язылган гаризасы әнә шундыйлардан. Мәгълүм булганча, XIX гасырның икенче яртысында Диния нәзарәте моңа кадәр Казанда басылган Коръәннәрдәге хаталарны ачыклау, яңа нәшер ителәчәкләрен алардан арындыру, аерым бер сүзләрнең язылышын унификацияләү, ягъни Коръән текстларын редакцияләүне Шиһабетдин Мәрҗанигә йөкли. Алда искәртелгән гариза – аның әлеге юнәлештәге эшчәнлегенең аерым бер үзенчәлекле якларын ачыкларга ярдәм итәрлек, шул сыйфаты белән игътибарга лаеклы чыганак.

Галимнең күпчелек хезмәтләре гарәп телендә язылган. Кызганыч, аларның бик аз өлеше генә татар яки рус телләренә тәрҗемә ителеп дөнья күргән. Мәрҗани әсәрләренең тәрҗемәләренә ихтыяҗның бүген дә зур булуын истә тотып, аның гарәп телендә язылган ике хезмәте – «Коръән гыйлеме һәм Госман мосхафләре белән бәйләнешле файдалы һәм мөһим өстәмәләр («Әл-Фәваид әл-мөһиммә вә-л-мәваид әл-мөтиммә әл-мөтәгаллика би-гыйльмел-Коръән вә рәсм мәсахиф Госман»,

1880) һәм «Ислам дине кануннарының күркәм сыйфатлары турында ачык хакыйкать» («Әл-Хакк әл-мөбин фи мәхасин әвдаг әд-дин», 1889) исемле әсәрләре рус теленә тәрҗемә итеп бирелде. Алар киң катлам укучылар игътибарына беренче тапкыр тәкъдим ителә.

Җыентыкның икенче бүлегенә Мәрҗанинең тормышы һәм эшчәнлеге хакында XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты битләрендә басылган мәкаләләр тупланды. Алар арасында «Йолдыз» (Казан), «Кояш» (Казан), «Идел» (Әстерхан), «Ил» (Мәскәү), «Тормыш» (Уфа) газеталарында, «Шура» (Оренбург), «Әд-дин вә әл-әдәб» (Казан) журналларында Ризаэтдин Фәхретдин, Закир Кадыйри, Габделбари Баттал, Шәһәр Шәрәф, Әхмәдзәки Вәлиди, Ибраһим Бикколов, Нәҗиб Гасрый авторлыгында чыкканнары аеруча игътибарга лаек. Шулай ук бу бүлектә, гасыр башы язмалары белән бергә, берникадәр соңрак чорда (1935–1945 еллар аралыгында) татар мөһаҗирләре тарафыннан Ерак Шәрыкта нәшер ителгән «Милли байрак» (Мукден) газетасының аерым бер саннарындагы мәкаләләргә дә урын бирелде. Төрле күләмдә, стильдә һәм жанрлардагы бу язмаларда Шиһабетдин Мәрҗанинең татар тарихындагы урыны һәм роле, дини һәм гыйльми эшчәнлеге турында фикер йөртелә, мирасының киләчәктә дә тәфсилләп өйрәнеләчәгенә ныклы ышаныч белдерелә.

Җыентыкның өченче бүлеген хатлар алып тора. Ризаэтдин Фәхретдин «Шура» журналы битләрендә: «Мәрҗани хәзрәтләре үз гомерендә иң күп мәктүб язган һәм дә мәктүбләрнең мөндәриҗәсе (эчтәлеге) гыйльми, әдәби вә фәнни мәҗлесләргә даир (бәйләнеше) булган адәмнәрнең бере булса кирәк», – дип билгеләп узган иде. Бу җәһәттән караганда Шиһабетдин Мәрҗанинең үз шәкерте һәм фикердәше, мәгърифәтче галим Хөсәен Фәезханов белән язышкан хатлары игътибарга лаек. Әлеге хатларның тарихи яктан кыйммәтле чыганак булуын истә тотып, Ризаэтдин Фәхретдин үз чорында ук аларны махсус рәвештә туплый һәм төп өлешен «Асар» хезмәтендә, калганнарын «Шура» журналында бастырып чыгара. Аларның хәзерге графикага күчерелгән текстлары галимнәребез М.Госманов,

Р.Мәрданов, А.Ахунов хезмәтләре аша фән дөньясына таныш.

Бу хатларга янәдән бер кат мөрәҗәгать итү Шиһабетдин Мәрҗанинең гыйльми эшчәнлеген, остаз-шәкерт арасындагы дустанә, эшлекле мөнәсәбәтләрне тулырак ачарга һәм аңларга ярдәм итәр дип уйлыйбыз. Шул максаттан чыгып, өченче бүлектә алты хат тексты татарча һәм русча вариантларда укучыларга тәкъдим ителә.

Дүртенче бүлекнең үзәген Шиһабетдин Мәрҗанигә атап язылган нәзым һәм шигырьләр тәшкил итә. Биредә Акмулла, Н.Думави, Г.Тукай, Ә.Сәгыйди, Г.Габдерахман, Г.Сөнгати әсәрләре белән танышырга, алар аша XIX гасыр азагы – XX гасыр башы шигъриятендә Мәрҗани образының гәүдәләнешен күзәтергә мөмкин.

Шунысы игътибарга лаек: бу төр әсәрләрдән берничәсен Мәрҗани хәзрәтләре үзе исән вакытта ук «Мөстәфадел-әхбар» китабына керткән була. Шәһәр Шәрәф галимнең эшчәнлегенә багышланган бер мәкаләсендә Мәрҗанигә атап шигырь язган егерме биш авторның исемен телгә ала. Кызганыч, бу шигъри әсәрләрнең күпчелеге бүген әдәбият фәнендә мәгълүм түгел.

Шиһабетдин Мәрҗани шигъри сүзне үзе дә чит итми, хезмәтләрендә аерым бер фикерләрен нәзым белән шигъри юлларга салып әйтә торган була. Алга таба аның бу шигъри юллары башка авторлар тарафыннан да кабул ителә. Әйтик, Ризаэтдин Фәхретдин, Морад Рәмзи һ.б.ның хезмәтләрендә Мәрҗанинең шигырь белән белдерелгән уй-фикерләренә еш юлыгабыз.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» китабының әлеге чыгарылышында урын алган текстлар, шәрех-комментарийлар Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, текстология бүлеге галимнәре З.Рәмиев, Ә.Алиева, И.Гомәров, Л.Гарипова, А.Ахунов, Г.Ханнанова, А.Сәлахов, Ч.Хәмидова, А.Хасавнех, В.Усманов, Ф.Фәйзуллина, Э.Галимҗанова, Г.Хөснетдинова, Г.Зәйниева тарафыннан гамәлдәге язуга күчерелде һәм язылды.

*Китапның җаваплы мөхәррире*
*И.Г. Гомәров*

# I бүлек
# Шиһабетдин[1] Мәрҗанинең иҗат мирасыннан

*Гыйлем һәм мәгърифәт белән шөгыльләнү, акыл белеменә һәм камиллеккә омтылу – һәр сәламәт акыл, аек аңга ия һәркем өчен, һичшиксез, кирәкле сыйфат, ә бу өлкәдә тырышлык һәм бер-береңә киң ярдәм күрсәтү – берсүзсез күркәм эш.*

*Ш.Мәрҗани*

## Шиһабетдин Мәрҗанинең Оренбург Диния нәзарәтенә басма Коръәндәге хаталарны төзәтү турындагы гаризасы

*Мәхкәмәи исламиядә әл-казаи-шәригә Мөхәммәдия*
*Ырынбургски Духовный собраниягә*
*бәлдә-ү Казанда Җамигъ әүвәлдә имам*
*Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗанидән*

гариза

Мәхкәмәи исламия Духовный собрание 1865 Гакрәб 31нче яүмендә 5274 рәкымдә фәрман илә Казан шәһәрендә Нәби Юныс мәсҗедендә указной мулла Салиховның гаризасындан нөсхә йибәрүб, шуның мокабәләсенә җаваб бирмәгә әмер итәдүр. Мәзкүр әмергә имтисалән түбәндә мөхәррир вәҗһеләрне түбәнчелек илә тәкърир кыламын.

Бу тарика Ырынбургски собрание 1859 Мизән 12 нче яүмендә 3325 рәкымдә указ илә әмер кылды, безгә шәһре Казанда бәгъдел-яүм басдык мәсахифны Нәби Юныс мәсҗедендә мулла Салихов берлән мокабәлә кылмага, дарел-мөлек Петербургда 1786да

[1] Чыганак текстларында «Шиһабеддин» дип биреләчәк.

басылмыш вә Казанда Нәби Юнысның әүвәл кәррә басдырмыш мосхәфләре вә Әмирханов мосхәфендән мокабәлә кылмага. Бәс, без Салихов берлән мәган, сәнә 59 Гакрәб 13 нче яүмендә собраниядән 46 рәкымдә гариза берлән сорадык. Без мәсахиф сәлясә мәзкүрәнең үзендә күб хата табамыз, ул мәүзыйгларны һәм безгә тәсхыйх кылмак ляземме яки бәхале куймак кирәкме дийү. Безгә собрание сәнә 65 Дәлү 19 нчы яүмендә 44 рәкымдә янә указ илә бәян әйләде. Мәсахиф сәлясәнең сыйххәте Министерствога вә Собраниягә мәгълүм түгел. Ул мәсахиф сәлясәне зикер кылмак гайреләргә караганда дөрестрәк булганга, әмма сезгә лязем мәсахиф җәдидәне гыйлем вә фән әш-шәргъ вә моктәза тәсхыйх кыласыз вә мәзкүр мәсахиф сәлясәдәге хаталарны бәхале әбка кылмаска әмер кылды. Бәгъдә зәликә матбагаи Кукубинда табгъ кылына башлаган мосхәфне бу фәкыйрь галә кадреттака тәсхыйх вә мокабәлә кылып бирдем. Әмма Салихов, гәрчә без мокабәлә кылганга кәгазьләргә кәнди ризасы вә хөсне ихтыяры берлә дөрес вә мәгъкуль дийү имза вә кул куйса, һәм ләкин үзе аслан мокабәлә вә тәсхыйх кылмады, мәгәр ике кәгазьне карап төзәтдем имди, дөрест булды дийү кул куеп бирде. Ләкин ул кәгазьләрдә биниһая хатасы сәбәбле, без риза булмадык вә имза кылып кул куймадык. Вә лиһәзә Салихов безгә мохалиф булып, фи зәгъмиһи бездән гаеб табып, бездән шикаятән собраниегә гариза күндергән. Гаризасында күренәдер, кәәннәһү без анысыз, миңа мөгайян, бән үзем белгәнчә тәсхыйх кылдымын, дийү әйтәмен имеш. Вә саниян, указда мәзкүр мәсахиф сәлясәнең ничә маддәдә рәсмне тәгъйир кылып, гаммә мөслиминнең могтәд рәсмләрене тәгъйир кылып, анларны тәгълитга сәбәб буладыр. Вә салисән, хәваши мәсахифда мәстур күб нәрсәне калдырган дийү. Һәзә кәләм Салиховның бу сүзләре һәм хата вә хилаф вакыйг, чөнки мин, аслан, мәзбүрәсен фәкать мөгайян дигәнем юк. Вә мәзбүр үзе ничә сафхагача разыйян кул куйды, вә бәгъдә зәликә низаг башлап, Собраниягә гариза ирсәл кылган. Мин ничә кәррә Кукубин матбагына кәгазь берлә мәгълүм кылдым, гәрчә мин эшкә тәвакъкыф булмасын дийү мөкабәлә кылып бирәм. Ләкин рафикымыз Салихов разый булмаса, сез ул сафханы табгка шоруг итмәйәсез дийү. Хәтта 65 сәнә Сәүр яүмендә

25 нче рәкымендә бу хосусда форменный отношение берлән через бәлитсә мәгълүм кылдым вә мән рәсмел-хатт әш-шәргыяне тәгъйир кылганым юк. Бәлки галә вәфкан әш-шәргъ хаталарны ислях кылдым вә бу рәсмел-хаттда һич әхәдәгә зарар юк. Гаер мәрсүмне укый белгән кеше мәрсүмне һич битәвакъкыф укырга кадир. Хәтта гавам вә әтфаль битәвакъкыф вә биля фәркъ укыйлар. Русия мөлкендә мондай мәрсүм Коръәнләр күб, җөмләдән бере – шәһре Казанда 1851 мәгә ригайә рәсмел-Хода Габделгазиз Борашев басмасы вә гайре зәликә, хәтта халык рәсме илә мәктүб мосхәфләрне бәхә кыйммәт берлән гайре мөлкләрдән китерәләр. Коръәндә рәсмел-хатт мәрги булмак әмер лязим вә важиб иҗмагы сәхабә берлән сәбит. Рәсме әсхабе рәсүлуллаһны тәгъйир вә анларга мохаләфә надөрест вә хәрам. Вә гаммә мәмалик исламиядә рәсмел-хатт әл-Коръәни мәргый вә мәкъбуль. Мондан мөкаддәмдә бу мөлекдә табгъ кылдыргучылар голямаи шәригать вә Духовный начальствога мөрәҗәгать кылмый үз раиләренә эш кылганлар. Вә лизәлик бихисаб хаталар вакыйг булган. Бу мөлекдә матбуг мәсахиф һәммәсе бер илле гадәд мәүзыйгка кариб күллән. Бердәй мөттәфикъ хаталар вә мондан гайре рәсмел-хаттлары вә әгъдаде суар вә мәхале аять вә әүкаф вә мәвазигы сәждат вә хәвашидә мөхәррир вөжүһ кыйраәт вә мәгәни кәлимәт. Вә мәгани кәлимәт әксәр, бәлки галибән хата вә галтанан вә мәстурел-гамәл. Вә нәмунә иделгән Әмирханов нөсхәсе нәфс назмел-Коръәнгә мөтәгалликъ түрт йөздән зиядә галатга мөштәмәл. Вә кәзаликә вә дарел-мөлкдә сәнә 1789 табг кылынмыш вә ничә йөз нөсхәләрендә никадәр хаталар вакыйг булган бу гаризада, тәфсыйлән тәгъйин мөмкин дәгел. Салихов безгә рәсмел-хаттны тәгъйирне нисбәт биргән мәүзыйгда нам мөтәмәссик могтәбәр кутубның җөмләдән бере «Иткан голумел-Коръән» әш-шәйх Җәлаледдин әс-Суюти вә «Кавагыйд» әш-шәйх Зәйнеддин әл-Хафиз вә «Рисалә» әш-Шәйх Ибраһим вә гайриһим анлардан мәэхуз риваятьләр бер гаризага мәган сафха саниядә сабит иделер, бәлки бәгъзеләре хәваши мәсахиф матбугада сабит иделгән. Вә мин җөмлә «аять» 8 нче сафхада вә «китаб» 11 сафхада, вә «кыямә» 339 вә «сиҗән» 221 сафхада, «сәхават» 399 сафхада мәзкүр. Салихов, гәрчә бездән

шикаятен гариза күндергән, әмма үзенә махсус тәсхыйх кылдым, табг кылың диб, кул куйып биргән кәгазендә ничә мәүзыйгда мәсахиф сәлясәгә хилаф кылган: 15 кәгазь 62 сафха 11 сатрда ләфзы «аять»дән вә биш мәүзыйгда ләфзы «сәмават»дән әлифне хызф кылып, «айәт» вә «сәмавәт» дийү сабит кылган. Вә мәга зәликә нәфсе назмел-Коръәнгә мөтәгалликъ никадәр хаталары бар. Вә мин рәсмел-хаттны төзәтдем, Коръән табг кылдыргучылар ирадәсе берлән кутуб могтәбирәдә мөбин тарика. Вә лиһәзә игътимад кыламын Духовный собрание рәсмел-хатт әл-Коръәнине бәян кылган кутуб могтәбирәдән тәфтиш кылганда бу хосусда бездән гаеб табмаслардыр дийү. Вә түбәнчелек берлән сорыймын, мәзкүр Салихов мәга әннәһү указда мәзкүр мәсахиф сәлясәгә хилафына галәвә бер-ике кәгазьдә никадәр хаталар аерып, янә мондаен юк нәрсәләрне безгә ифтира кылып, хариҗ ганел-канун гаризалар берлән рөәүсәгә тасдигъ биргәне өчен аңар муафикъ низам хөкем йөртелсә икән дийү.

Гариза ирсәл кылгучы шәһре Казанда Җәмигъ әүвәлдә фәлән 1865 Кавәс 22 яүмендә 68 рәкымдә.

**Гаризаның хәзерге әдәби телгә тәрҗемәсе:**

*Мөселман мәхкәмәсендә*
*Мөхәммәд пәйгамбәр шәригате буенча*
*хөкем итүче Оренбург Диния нәзарәтенә*
*Казанның Беренче җамигъ мәчете имамы*
*Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗанидән*

гариза

Мөселман Диния нәзарәте 1865 елның Чаян ае 31 нче көнендә [имзалаган] 5274 санлы фәрманы белән, Казан шәһәренең Нәби Юныс мәчетендә указлы мулла Салиховның гаризасыннан нөсхә җибәреп, шуңа җавап бирергә кушты. Әлеге әмергә буйсынып, биредә [Коръән басмасын] төзәтү рәвешләрен түбәнчелек белән аңлатып бирәмен.

Бу мәсьәләдә Оренбург Диния нәзарәте 1859 ел, Үлчәү аеның 12 нче көнендә 3325 санлы указы белән, безгә, Нәби Юныс мәчете

муллaсы Салихов белән килешеп, Казан шәһәрендә бүгеннән соң нәшер ителәчәк Коръән басмаларын, башкалабыз Петербургта 1786 нчы елда чыккан һәм Казанда Нәби Юнысның беренче тапкыр нәшер иткән Коръәннәре, Әмирханов басмасы белән чагыштырып карарга әмер итте. Шуңа күрә без, Салихов белән бергә, 59 нчы елның Кысла ае 13 нче көнендә Диния нәзарәтенә [язылган] 46 номерлы гариза белән: «Без алда телгә алынган өч басманың үзләрендә күп хата табабыз. Ул җирләрне дә безгә төзәтергәме, әллә ничек бар шулай калдырырга кирәкме?» – дип сорадык. Диния нәзарәте безгә 65 нче ел Сукояр аеның 19 нчы көнендәге 44 санлы указы белән янәдән аңлатты: «Бу өч басманың дөреслеге Министрлыкка һәм Диния нәзарәтенә мәгълүм түгел. Ул өч басманы башкаларына караганда дөресрәк булганга искә алдык. Әмма сез яңа басмаларны гыйлем һәм шәригать фәне буенча тиешенчә төзәтегез һәм алда искә алынган өч басмадагы хаталарны да ничек бар шулай калдырмагыз», – дип әмер итте. Шуннан соң Кукубин нәшриятында басыла башлаган Коръән басмасын мин, фәкыйрь, кулдан килгәнчә төзәтеп һәм чагыштырып бирдем. Әмма Салихов, гәрчә без чагыштырган кәгазьләргә үз ризалыгы һәм ихтыяры белән «дөрес һәм аңлаешлы» дип имза һәм кул куйса да, үзе, гомумән, чагыштырмады һәм төзәтмәде, мәгәр ике кәгазьне карап, «төзәттем инде, дөрес булды» диеп, кул куеп бирде. Ләкин ул кәгазьләрдә хатасы бик күп булу сәбәпле, без риза булмадык һәм имза кылып кул куймадык. Шуңа Салихов, безгә каршы чыгып, әйтүенчә, бездән гаеп табып, өстебездән шикаять итеп, Диния нәзарәтенә гариза илткән. Гаризасыннан шулай күренәдер ки, әйтерсең лә без аннан башка «бу миңа кушылган, мин үзем белгәнчә төзәттем» диеп әйтәбез имеш. Икенчедән, указда телгә алынган өч басманың аерым бер өлешләрендәге рәсмне[1] үзгәртеп, бөтен мөселманнарның гади рәсмнәрене үзгәртеп, аларның хаталануына сәбәп булыр [диелгән]. Өченчедән, басмаларның хашия-аңлатмаларында язылган күп нәрсәләрне төшереп калдырган, дигән. Салиховның бу

[1] Биредә һәм алга таба сүз «рәсмел-хатт Коръән» мәсьәләсе, ягъни Коръән текстының сәхабәләр чорында ничек язылган һәм укылган, бүген дә шул рәвешле язылырга һәм укылырга тиешлеге хакында бара.

сүзләре хата һәм дөреслеккә туры килми, чөнки минем, гомумән, «әйтелеп үтелгәннәр фәкать [миңа гына] кушылган» дигәнем юк. Инде искәртелгәнчә, үзе ничә биткәчә ризалашып кул куйды һәм шуннан соң, низаг башлап, Диния нәзарәтенә гариза җибәргән. Гәрчә мин ничә тапкыр Кукубин нәшриятына «эшкә тоткарлау булмасын өчен чагыштырып бирәм, әмма дустыбыз Салихов риза булмаса, сез ул битне бастырмагыз» дип, кәгазь белән мәгълүм кылдым. Хәтта 65 нче ел, Үгез аеның ... көнендә 25 нче санлы отношение белән «минем рәсмел-хатт әш-шәргыяне үзгәрткәнем юк» дип, бу хакта рәсми рәвештә полициягә мәгълүм кылдым. Бәлки шәригать буенча килешенгән хаталарны төзәттем һәм бу рәсмел-хатта һичкемгә зарар юк. Кабул ителмәгән рәвештә язылганны укый белгән кеше сәхабәләр иҗмагы[1] белән кабул ителгән рәвештә язылганны да тоткарлыксыз укый ала. Хәтта гади халык һәм балалар тоткарлыксыз һәм аермасыз укыйлар. Русия илендә мондый рәвештә басылган Коръәннәр күп, җөмләдән берсе – Казан шәһәрендә 1851 елда мәгә ригайә рәсмел-Хода Габделгазиз Борашев басмасы һәм аннан башка [басмалар]. Хәтта халык рәсм белән язылган Коръән басмаларын зур бәя белән чит илләрдән китерә.

Коръәндә рәсмел-хатт булуы гади, кирәкле һәм үтә тиешле, сәхабәләр иҗмагы белән исбатланган әйбер. Рәсүлуллаһ әсхабларының рәсмен үзгәртү һәм аларга каршы чыгу дөрес түгел һәм хәрам. Һәм бөтен ислам илләрендә рәсмел-хатт әл-Коръәни гадәти һәм кабул ителгән.

Моңа кадәр бу илдә [Коръән] бастыручылар, шәригать галимнәренә һәм Диния нәзарәте җитәкчелегенә мөрәҗәгать итмичә, үз фикерләренчә эш кылганнар. Шуңа күрә бихисап хаталар барлыкка килгән. Бу илдә чыккан Коръән басмаларының һәммәсен исәпкә алганда, илле тирәсе булыр. Аларның бөтенесендә дә бердәй килешенгән кебек хаталар бар. Шулардан канунлашкан язу рәвешенә туры килмәү, сүрәләр саны, аятьләр урыннары, туктау урыннары, сәҗдә ясау урыннары, хашия-аңлатмаларда укуны төзәтү рәвешләре һәм сүзләрнең мәгънәләрендәге хата вә

[1] Иҗмагъ – теге яки бу дини мәсьәләләрдә абруйлы галимнәрнең бергәләшеп килешенгән фикере.

ялгышлыклар күбрәк очрый. Һәм үрнәккә китерелгән Әмирханов нөсхәсе үзе дә шул ук Коръән төзелеше [мәсьәләсенә] бәйле дүрт йөздән артык хата белән тулы. Шулай ук башкалада 1789 елда нәшер ителгән [басманың] ничә йөз нөсхәләрендә никадәр хаталар барлыкка килгәнен бу гаризада тәфсилләп аңлату мөмкин түгел. Салиховның безнең рәсмел-хаттны үзгәртүгә кагылышлы язганнарына, шәрәфле китаплардан шәех Җәлаледдин әс-Суютиның «Иткан гулюмел-Коръән», шәех Зәйнеддин әл-Хафизның «Кагыйдәләр», Шәех Ибраһимның «Рисәлә» исемле китаплары һәм башкалардан алынган риваятьләргә таянып, икенче бер гаризада бергә исбатлана, кайберләре исә басылган мосхәфләрнең аңлатмаларында дәлилләнә. Шулардан: «айәт» 8 нче биттә, вә «китаб» − 11нче биттә, вә «кыямә» 339 нче вә «сиҗән» − 221нче биттә, «сәхавәт» 399 нчы биттә телгә алынган. Салихов, гәрчә бездән шикаять итеп гариза җибәрсә дә, үзенең махсус «төзәттем, бастыр» дип, кул куеп биргән кәгазендә ничә җирдә [югарыда телгә алынган өч Коръән] басмасына хилафлык кылган: 15 нче кәгазь, 62 нче бит, 11нче юлда «айат» (ايات) сүзендә һәм биш җирдә «сәмәват» (سموات) сүзеннән әлифне төшереп калдырып, «айәт» (ايت) һәм «сәмәвәт» (سموت) дип төзәткән. Һәм моннан башка шул ук Коръән төзелешенә бәйле никадәр хаталар бар.

Һәм мин, рәсмел-хаттны, Коръән бастыручылар теләге белән, абруйлы китапларда, күрсәтелгәнчә, ачык итеп төзәттем. Шуңа күрә Диния нәзарәте рәсмел-хатт әл-Коръәнине аңлаткан әлеге игътибарга лаек китапларны тикшергән очракта, бездән гаеп табылмас дип ышанамын. Һәм түбәнчелек берлән сорыймын, Салиховның указда югарыда сөйләнгән өч басмага каршы чыгуына өстәп, бер-ике кәгазьдә никадәр хаталар аерып, янә монда юк нәрсәләрне безгә яла ягып, канунсыз гаризалар белән [Диния нәзарәте] җитәкчеләренә баш авыртуы ясаганы өчен, аңа тиешле хөкемен бирсәләр, мин риза, диеп гариза җибәрүче Казан шәһәрендә Беренче Җамигъ мәчетендә фәлән. 1865 нче ел, Укчы аенының 22 нче көнендә, 68 санында.

*Текст һәм тәрҗемәне басма өчен*
*Чулпан Хәмидова һәм Илһам Гомәров әзерләделәр*

**Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең үз каләме илә язылган гыйльми вә дини мәкаләсе**

Бисмиллаһир-рахманир-рахим

Хак Тәбарәкә вә Тәгалә Кәляме мәҗидендә әйтәдер:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنْسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ (56) مَا أُرِيدُ مِنْهُمْ مِنْ رِزْقٍ وَمَا أُرِيدُ أَنْ يُطْعِمُونِ (57) إِنَّ اللَّهَ هُوَ الرَّزَّاقُ ذُو الْقُوَّةِ الْمَتِينُ (58) [1],

ягъни яратмадым, юкдан бар кылмадым мән җен вә адәмне, мәгәр анлар мәне танып, мәне белеп, мәңа анлар тиешенчә гыйбадәт кылмаклары өчен, вә иллә, әләман[2], мән анлардан теләмәймен анлар миңа ризык бирмәкләрене вә һәм теләмәймен анлар миңа тәгам бирмәкене; хакыйкатән, Аллаһы Тәгалә һәммә җан иясенә ризык биргүче, шәдид әл-куәт[3], кәмаль әл-кодрәтдер.

Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтене танымак вә мәгърифәт вә белмәк гыйлем берлә хасил буладыр. Җәмигъ[4] гыйбадәтләрнең дөрес вә сәхих[5] булып, күп сәваблар хасил улмакы бу гыйлем берлә хасил буладыр.

Хәләл вә хәрамне аерыб тәмиз кылыб кәсебләр вә һәркайсы гамәлләрне муафыйк вә сахих кылыб кәсебләр хәләл вә ризыклар тоеб улмагы бу гыйлем берлә хасил буладыр.

Хәрам вә мәкруһ[6] вә бозык эшләрдән сакланып, Алла Тәгаләнең газап вә гыйкабындан хәлас булмак[7] бу гыйлем берлә хасил буладыр.

[1] Коръәннең «Зәрият (Таратучы)» исемле 51 нче сүрәсенең 56−58 нче аятьләре. Ногманиның «Коръән тәфсире»ндә аларның татарчасы: «56. Кеше белән җенне халык кылмадым, мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым. 57. Мин кешеләрдән һич ризык теләмим, ягъни сорамыйм, дәхи Мине ризыкландыруларын да сорамыйм. 58. Шиксез, ул – Аллаһ барча мәхлукатны бик ризыкландыручы, һәм бик олуг куәт ияседер».

[2] Әләман – коткарыгыз.

[3] Шәдид әл-куәт – куәте көчле.

[4] Җәмигъ – барлык, бөтен.

[5] Сәхих – чын, дөрес.

[6] Мәкруһ – начар, ямьсез.

[7] Гыйкабындан хәляс булмак – газабыннан азат булу, котылу.

Адәминең гакыл вә вәһеме[1], вә идряк[2] вә тәмйизе[3] артып, җәмигъ өмуре мөстәкыйм булмак[4] берлә хәйваннар дәрәҗәсендән юкары вә анлар рөтбәсендән[5] ерак булмакы бу гыйлем берлә хасил буладыр.

Халыкның динне сакламакы[6] дин вә дөньясының артмакы[7] бу гыйлем берлә хасил буладыр.

Кайсы халыкда гыйлем булмаса, динләре җуела, гакыллары җуелып хайван сыйфатына вә холыкларына кереп, дөньяда хайван кебек ашау-эчү, яту-торудан башкадан ләззәт тапмас дәрәҗәсенә тәнәззел кыла[8], төшәдер.

Вә бил-җөмлә[9] бу гыйлем аның кәмаль сыйфат вә җәүһәр шәриф Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бәни адәмне үзенең бу кәмаль сыйфатындан мәхзуз[10] вә хәссадар булмакга мөстәгыйд вә муафыйк әйләгән[11].

Әгәр адәми, бу гыйлем сыйфаты берлә үзенә кәмаләт хасил кылганда, фәрештәләрдән юкары дәрәҗәгә тәрәккъый кыладыр вә әгәр үзене мөһмил[12] тотып, гыйлем хасил итмәсә, вә гамәле салих[13] кылмаса, хайвандан һәм түбән дәрәҗәгә тәнәззел буладыр[14], нитәк Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә әйтәдер:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنْسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ (4) ثُمَّ رَدَدْنَاهُ أَسْفَلَ سَافِلِينَ (5) إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا

---

[1] Вәһеме – хыялы.

[2] Идряк – уйлау, аңлау сәләте.

[3] Тәмйизе – (чынбарлыктагы хәлләрне) аерып фикерли алуы.

[4] Җәмигъ өмуре мөстәкыйм булмак – барлык эшләре дөрес булуы.

[5] Рөтбәсендән – дәрәҗәсеннән.

[6] Сакламакы – саклавы.

[7] Артмакы – артуы.

[8] Тәнәззел кыла – түбәнәя.

[9] Бил-җөмлә – бөтенләе белән, барлык.

[10] Мәхзуз – шат.

[11] Хәссадар булмакга мөстәгыйд вә муафыйк әйләгән. – (башкалар белән) бүлешүчән булуга сәләтле һәм ирешүче булган.

[12] Мөһмил – илтифатсыз.

[13] Гамәле салих – яхшы гамәл.

[14] Тәнәззел буладыр – төшәдер.

الصَّالِحَاتِ [1] وَمَنْ يُؤْتَ الْحِكْمَةَ فَقَدْ أُوتِيَ خَيْرًا كَثِيرً[2]
هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ[3]
أُولَئِكَ كَالْأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ[4]

бу гыйлем сыйфатының мәдхендә Коръән аятьләрендә Рәсүлуллаһи салаллаһу галәйһи вәссәлләмнең хәдис шәрифләрендә бихисап сүзләр вардыр.

Бәс һәрбер мөэмин вә мөселман бәндәләргә бу гыйлемне бик гали нәрсә вә гали әл-кыйммәт белеп, аны кәма янбагый[5] кадәр вә хөрмәт итмәк вә тәгъзим кылмак важиб[6] вә ләземдер. Һарун әр-Рәшид хәлифә[7], имам Мәликкә «Муватта»[8] китабыңызны безгә алып килеңез, без андагы гыйлемне ишедәек дигәндә, имам Мәлик әйтде: «Йә әмир әл мөэминин, гыйлем газиз нәрсә,

[1] Коръәннең 95 нче – «Әт-Тин (Инҗир)» сүрәсенең 4 нче, 5 нче, 6 нчы (өлешчә) аятьләре. Ногманиның «Коръән тәфсире»ндә аларның татарчасы: «4. Тәхкыйк. Без адәм баласын күркәмрәк сурәттә халык кылдык. 5. Соңра, ул итагатьсез кире кешене түбәннәрнең түбәненә кайтардык, ягъни җәһәннәмгә. 6. Мәгәр иман китереп Аллаһыга һәм рәсүлгә итагать иткән, гөнаһлардан сакланып изге гамәлләр кылган кешеләрне генә түбәннәрнең түбәненә төшермибез, аларга һич киселми, кимеми торган, мәңгегә җәннәт нигъмәтләредер» (6 нчы аять тулысынча китерелде).

[2] 2 нче – «Бәкарә (Сыер)» сүрәсенең 269 нчы аяте (аятьтән өзек). Ногманиның «Коръән тәфсире»ндә татарчасы: «Киңлек иясе булган Аллаһ хикмәтне Үзе теләгән бәндәсенә бирер, Аллаһының бәрәүгә хикмәт бирелсә – ул кешегә бик күп яхшылыклар бирелде. «Хикмәт» дигән сүзгә ислам диненең бөтен хөкемнәре керә. Коръән Кәрим белән һәрбер кеше вәгазьләнмәс, мәгәр саф акыллы кешеләр генә вәгазьләнерләр»(аять тулысы белән китерелә).

[3] 39 нчы – «Зүмәр (Халык төркеме)» сүрәсенең 9 нчы аяте (өлеше).

[4] 7 нче «Әл-Әграф» сүрәсенең 179 нчы аяте (өлешчә). Ногманиның «Коръән тәфсире»ндә аның татарчасы: «батыйлны белеп, батыйлдан ерак булган, хакны белеп, хак тарафында булган хак мөэминнәр батыйлны да, хакны да белмичә адашып йөргән сукырлар белән бертигез булырлармы? ... алар хайван кебиләр, бәлки хайваннарга караганда да, файда белән зарарны аера алмауда гакылсызраклар».

[5] Кәма янбагый – ничек кирәк шулай, тиешле рәвештә.

[6] Важиб – тиеш, кирәк.

[7] Һарун әр-Рәшид (февраль 766, яисә 17 март 763 – 24 март 809) — гарәп хәлифәсе.

[8] Имам Малик ибне Әнәс әл-Әсбахи (713–795) төзегән «әл-Муватта» исемле хәдисләр китабы турында сүз бара.

сез газиз итсәңез – газиз булыр, хур тотсаңыз – хур булыр. Гыйлемнең үзенә килергә тиеш, аны икенче йиргә алып барырга ярамыйдыр». Хәлифә бу җавапны хуш күрде. Бу гыйлем шундай бәләнд пәрваз[1] нәрсә, бик күп кеше арасыннан бик азы табгы сәлим[2], фәһме кавим[3] теләп, гыйлем вә тарикы шәргъдә мөстәкыйм[4] булып, чын ихлас берлә кәма янбагый сәгый[5] вә иҗтиһадына чалышган кешенең бәгъзесе генә бер кәмал[6] булып чыгадыр. Әмма аның азы һәм кәмал табганда[7] тәмам дөнья вә ма фиһа[8] бәһасына торадыр, нитәк кем[9], әмма Әбү Йосыф[10] әйтәдер: гыйлем шундай нәрсә – үзеңнең нитәк көлләңне[11] бирсәң, ихтимал, ул сиңа азыны бирер дип.

Гыйлемне кадер кылмак, газиз тотмак – ул гыйлемне бик әгъля[12], яхшы нәрсә ирдекене белеп, һәркем үзе аны хасил итәргә иҗтиһад кылмак өйрәнмәк (үгрәнмәк) вә балаларыны вә якынларыны сабак укытмак, бәлки, мөмкин булса, ятларны да вә гыйлем тәхсил итә торган кешеләрне кадер вә хөрмәт кылмак вә газиз тотмак берлә хасил булыр. Анларны кадер-хөрмәт кылмак, газиз тотмак, анларга гыйлем өйрәтергә, гыйлем тәхсил итәргә ярдәм итмәк берлә вә хаҗәтләрене йиткүрмәк берлә булыр. Мәсәлән, тора торган урынларыны яхшы кылмак, мич вә тәрәзә, вә ишек, вә ашханәләре вә шәмгъләре[13], бәлки, мөмкин булса, китаплары вә хадимләре, вә тәгамләрене мөһәййә[14] кылмак берлә булыр.

[1] Бәләнд пәрваз – биек оча (торган).
[2] Табгы сәлим – саф табигать, нормаль табигать.
[3] Фәһме кавим – дөрес аңлау.
[4] Тарикы шәргъдә мөстәкыйм – шәригать юлында туры.
[5] Сәгый – тырыш.
[6] Кәмал – камиллеккә ирешкән; җитешкән, өлгергән.
[7] Кәмал табганда – камиллек тапканда.
[8] Ма фиһа – аның эчендәге нәрсә.
[9] Нитәккем – ничек, ни рәвешле.
[10] Әбү Йосыф – 731–804 елларда яшәгән фәкыйһ (ислам кануннары белгече), исламда беренче югары дәрәҗәдәге казый.
[11] Көлләңне – бөтенеңне.
[12] Әгъля – югары, кадерле.
[13] Шәмгъләре – шәмнәре.
[14] Мөһәййә – әзер.

Кадимдә хәлифә вакытында ислам дәүләтләрендә, бәлки, хәзер ислам мәмләкәтләрендә, һәм голяма вә таләбә, гыйлем биниһая кадерле вә тәхсил вакытларында, мохтаҗ нәрсәләре һәммәсе бер кәмал хәзер вә урынлары бик иркен яхшы вә бик хуш булыр иде. Гыйлем тәхсил идеп кәмаләтгә ирешкән бәгъдендә[1] ул гыйлем мөсәббиб[2] бик зур дәрәҗәләргә менеп, бик зур дөнья дәүләтене малик табып, миллион вазифалар алыр иде. Мәсәлән, хәзрәте имам Әбү Йосыф рәхмәтулла галәйһи үзе бер бүз юа торган тол хатынның углы иде, анасы бүз юучыга хезмәткә биреп, ул андан качып, гыйлем эстәргә шөругъ идеп[3], кәмаләтгә ирешеп, гыйлеме сәбәпле Һарун әр-Рәшид вә Һади[4] хәлифәләр берлә фирүзә вә якут табакларындан тәгам йимәк дәрәҗәсенә ирешде; вафат улганында йөз мең талә[5] Мәдинәи-Мөнәүвәрә әһалисенә, йөз мең Мәккәи-Мөкәррәмә, йөз мең Күфә, йөз мең Багдад әһалинә кәнд[6] малындан васыять кылды. Безем хәзерге хәлемездә мондай эшләрнең меңдән бере сурәт тотмайдыр. Тәхсил кылган вакыт таләбәи гыйлемләремез үзе икмәкне алып килеп кимереп, бер кеше тора торган урында егерме унысы торып, гыйлем тәхсил итеп кәмаләткә ирешсә, ниһаять, бер мәсҗедгә имам булып, үлек ашы ашап көн итәдер. Аның өстенә әһле гыйлем һәртөрле тәхфиф[7] вә төрле бәһанәләр[8] берлә ифтира[9] вә хәкарәт күрәдер. Болай булгач, гыйлемгә ничек рәгъбәт кылынып[10], ничек дин куәт табарга кирәк. Бу сүзләр торсын, ләкин мөмкин кадәренчә гыйлемнең рухына кадәри хәл иҗтиһад кылмак кирәк вә иллә, алай булмаганда дин җуялмакыннан курыкмак кирәк. Сәдака вә хәерләрнең һәр каюсында әҗер вә сәвап күп булса да, әмма

---

[1] Бәгъдендә – соңында.

[2] Мөсәббиб – сәбәпле.

[3] Шөругъ итеп – керешеп.

[4] Һади – Муса әл-Һади, 785–786 елларда Гарәп хәлфәтендә дүртенче хәлифә, Һарун әр-Рәшиднең бертуган абыйсы.

[5] Талә – алтын.

[6] Кәнд – үз.

[7] Тәхфиф – кимсетү.

[8] Бәһанәләр – сылтаулар, ялган сәбәпләр.

[9] Ифтира – яла ягу.

[10] Рәгъбәт кылынып – омтылыш барлыкка килеп, кызыксыну туып.

дәрәҗәләре бик мөтәфавит:[1] каюсында бергә бер сәвап, каюсында ун вә йитмеш, вә йөз вә йиде, йөз вә андан зиядә[2] бихисап мозагафь кыладыр[3] Аллаһы Тәгалә. Мәсҗед салдырмак, күпер сукдырмак вә халык файдасына кое казымакта вә гайре эшләргә сәвап. Болар арасындан мәсҗед салмакда сәвап күбрәк булса да, мәдрәсә вә мәктәбханә бина кылмак вә әһле гыйлемне тәрбия кылмак һәммәсендән әфзаль[4] вә биниһая сәваплыдыр. Мәсәлән, берәү мәсҗед бина кылса, шул мәсҗеддә нәкадәр кеше намаз укыса, ничә елгача барыр шул сәвап гына булыр. Андан артык булмас. Мәсәлән, ун ел торса, унгача, йөз ел торса, йөз елгача савабы барыр. Тузса яки янып китсә, савабы киселер, әмма мәдрәсә яки мәктәпханә бина кылынса, гыйлемгә ярдәм итсә, дөнья барынча, тәгаллем[5] барынча бер дә киселмәс вә бил-фарыз, егерме-утыз сәнәдән соң фани булса яки янса да, гыйлем берәүдән берәүгә күчеп калып, галәлдәвам[6] әҗер вә сәвабы барып, мәдрәсә бетүе берлә бетмәс. Бәс, һәркайсы дин вә исламда мәхәббәтләре булган мөэмин-мөселманлардан гынадыр илтимас[7]. Бу сүзләрне укып, фәһемләп, һәрвакыт зикердә тотып, мөляхәзә кылып гамәл кылырга сәгый[8] вә иҗтиһад идә вә иллә дөнья тарафател-гаендә[9] үтәдер, гамәл киселәдер, мәгәр шушы эшләр берлә әйтәдер Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә :

إِنَّا نَحْنُ نُحْيِي الْمَوْتَى وَنَكْتُبُ مَا قَدَّمُوا وَآَثَارَهُمْ [10]

[1] Мөтәфавит – төрле.
[2] Зиядә – артык.
[3] Мозагафь кыладыр – кабатлыйдыр, өстидер.
[4] Әфзаль – артыграк.
[5] Тәгаллем – укыту, өйрәтү.
[6] Галәлдәвам – һәрвакыт.
[7] Илтимас – үтенү.
[8] Сәгый – тырышлык.
[9] Тарафател-гаендә – бик тиз, күз ачып йомганчы.
[10] 36 нчы – «Ясин» сүрәсенең 12 нче аяте (өзек). Ногманиның «Коръән тәфсире»ндә татарчасы: «Тәхкыйк без үлекләрне тергезәбез, һәм аларның үлмәстән элек кылган яхшы һәм яман эшләрен, һәм дә үзләре үлгәннән соң калдырган яхшы һәм яман әсәрләрен язабыз. Без һәрнәрсәне санадык һәм яздык Ачык Китапта». (12 нче аять тулысынча китерелде.)

Казый Насретдин әл-Бәйзавый боның тәфсирендә әйтәдер:

اثارهم الحسنة من علم علموه اوحبيس و قفر و القبيحة كتاسيس بدعة و احداث ظلم (аларның эзләре гүзәл: биргән белемнәре начарлыктан тыелырга, тискәре гадәт-тәртипләрдән, көч кулланудан баш тартырга өйрәтәләр), ягъни безләр хакында, әлбәттә, үлекләри тергезермез, артларында калдырган нәрсәләрене һәм, мәсәлән, гыйлем өйрәтеп яки мәдрәсә вә мәктәпханә бина кылып калдырса, сәвап вә әҗере һәмишә барып торыр, вәссәлам.

*Мәкалә 1914 елда «әд-Дин вәл-Әдәб» журналының 2 нче санында басылган.*

*Текстны басма өчен Зөфәр Рәмиев әзерләде*

## Важные пользы и дополнения, связанные с наукой о Коране и списком свитков ‘Усмана[1]

*Достоверность текста Священного Корана обеспечивается наличием многочисленных цепочек передатчиков его чтения, восходящих непосредственно к пророку Мухаммаду (да благословит его Аллах и приветствует). Распространенный сегодня список Корана является копией (не учитывая диакритические знаки) текста единых канонических Свитков ‘Усмана, составленных в правление праведного халифа ‘Усмана бин ‘Аффана (576–656). Достоверные варианты и правила рецитации Корана зафиксированы знатоками этой науки, наиболее выдающимися представителями которой являются: Абу ‘Амр ад-Дани (981–1053) – автор книги «Хирз ал-амани ва ваджх ат-тахани», ал-Касим аш-Шатиби (1144−1194) – автор сокращения сочинения Абу ‘Амра ад-Дани, Мухаммад ал-Джазари (1350–1429) – автор книг «Тахбир ат-тайсир фи-л-кира’ат ал-‘ашр», «ал-Мукаддима…», Джалал ад-дин ас-Суйути (1445–1505) – автор книги «ал-Иткан фи ‘улум ал-Кур’ан» и др. На труды этих и других ученых опирался ал-Марджани в своей редакции списка Корана.*

*В предлагаемом читателю переводе трактата ал-Марджани «ал-Фава’ид ал-мухимма ва-л-мава’ид ал-мутимма ал-мута‘аллика би ‘илм ал-Кур’ан ва расм масахиф ‘Усман» («Важные пользы и дополнения, связанные с наукой о Коране и списком свитков ‘Усмана») изложены особенности составления текста списка Корана, связанные с написанием отдельных слов, использованием диакритических знаков, символов, указывающих на места совершения пауз и границ аятов.*

Возношу хвалу Аллаху, как это подобает тем, кто благодарен Ему за дары, и да пребудет благословение и мир над господином посланников Мухаммадом, его близкими и сподвижниками.

---

[1] Ал-Марджани Ш.Б. Ал-Фава’ид ал-мухимма ва-л-мава’ид ал-мутимма ал-мута‘аллика би ‘илм ал-Кур’ан ва расм масахиф ‘Усман // Хакк ал-ма‘рифа ва хусн ал-идрак би ма йалзам фи вуджуб ал-фитр ва-л-имсак и другие сочинения. – Ред. Л.‘А. Ал-Халили. Амман: Дар ал-Фатх, 2016. С. 255–332.

Далее. Это важные пользы и дополнения, связанные с наукой о Коране и списком свитков ‘Усмана; я продиктовал их во время своей работы в бюро свитков Корана, изданных в типографиях Казани.

Знай, что свитки Корана издаются в России уже в течение ста лет, однако вопрос их редакции был оставлен на усмотрение обывателей, их ломаному языку, этим занимались те, кто не обладал знанием и пониманием, которые бы приводили их к истине. В этой связи в их свитках продолжали находиться некоторые неисправленные ошибки. Они написали на полях Свитка много из того, что касается вариантов чтения [Корана], различий в передачах [чтений] и смыслов слов без знания, так что связанное [с тем или иным словом] расположено на другой, второй и третьей страницах. Они написали в них лишнее и неверное.

После того, как в 1276 году по хиджре на меня была возложена редакторская работа, я удалил из Свитка лишнее, исправил ошибки. Первое, чем я занялся в тот раз в деле редактирования списка свитков ‘Усмана, забота о которых возложена на умму, было то, что связано с чтением, и пренебрежение чем приводит к изменению положений [Шариата], – слитное чтение (васл) и пауза [в чтении], написание буквы и опускание [буквы], например: آيت, كتب, رحمت, رحمة, أَلَّن, إِلاَّ и другое из того, что содержится в «ал-Мукаддиме» ал-Джазари[1], не касаясь – за небольшим исключением – слов во множественном и двойственном числах, имен собственных, опускания и написания *хамзы*. Поскольку правила чтения этих слов различаются в зависимости от раздельного либо слитного прочтения, долгой и короткой гласных, наличия буквы на письме и ее опускания. Так, в случае раздельного прочтения أن لا при необходимости дозволяется пауза с разделением [слов] и возобновление чтения с последующего слова, в отличие от случая слитного прочтения – أَلاَّ. На словах, оканчивающихся на длинную *та*, например: رحمت, ‘Асим, Нафи‘, Ибн ‘Умар, Хамза останавливаются на *та*, тогда

[1] «Ал-Мукаддима» ал-Джазари («Введение» ал-Джазари) – один из наиболее авторитетных трудов по правилам рецитации Корана. – Прим. пер.

как другие [чтецы] – на *ха*. В отличие от короткой *та* – на ней, по согласию [всех чтецов], пауза делается на *ха*.

Написание *алифа* в [некоторых случаях] может приводить к оставлению достоверного чтения от Посланника Аллаха (да благословит его Аллах и приветствует).

Когда дело подготовки того издания подошло к завершению, в его конце я написал следующее: «Завершилось, благодаря заботе Царя Достохвального, издание Великой Книги в типографии Кукубина, в городе Казани, с приложением сил в деле исправления и сличения [списка Корана] настолько, насколько это в возможностях человека, с учетом согласованных сподвижниками и написанных ими в правление ‘Усмана списков Корана». Таким образом появился, хвала Аллаху, наиболее правильный из свитков Корана, изданных в этой стране, хотя в нем и имеется то, чего не избежать никому из рабов [Божьих]. Случилось сие в четверг, по прошествии семи ночей месяца мухаррам 1277 года. Дело составления списка Корана для жителей этой страны, как для простолюдинов, так и образованных, было необычным, преданным забвению, ввиду чего они сочли это измышлением и упрекнули меня за мое начинание; возникло много споров и сомнений; был искажен прямой путь для желающих идти по нему; меня обвинили в тяжких грехах и заявили: «Он искажает слова Корана, удаляет многие аяты; вместо يا موسى написал يموص , вместо يا مريم написал يمورم». Не ограничившись этой порцией лжи, они написали прошение о моем отстранении и рассмотрении моего дела на коллегии. Питавшие ко мне злобу за некоторые вещи ее члены улучили возможность отмщения и вызвали меня на допрос. Я показал им поставленную ими же подпись относительно исправления [списка Корана] в соответствии с действительным [списком] ради достижения благоволения Законодателя. Затем они потребовали от меня аргумент относительно каждого слова, которое я внес в Свиток. В доказательство я написал им фрагменты из [книг] ад-Дани «ат-Тайсир», аш-Шатиби «ал-‘Акила», ас-Суйути «ал-Иткан» и других сочинений великих ученых в виде передач и версий [списка Корана]. Они потерпели крах в

моем обвинении и споре со мной. Однако они отстранили меня от этого дела, сославшись на то, что у меня не имеется достаточно времени для занятия сличением [списка Корана], что это дело является для меня обременительным, поскольку мне приходится рассматривать множество судебных вопросов и улаживать споры между подданными из числа мусульман в городе Казани и ее окрестностях.

Когда же люди уяснили, что дело в действительности обстоит именно так, и увидели лживость догадок противников, те выдвинули ложное заявление о том, что список ‘Усмана неизвестен в этой стране детям, обывателям и женщинам, ввиду чего принятие его во внимание приведет к обвинению их в ошибках [при чтении] и искажении [текста Корана].

После моего отстранения на мое место были назначены Шах-Ахмад бин Абу Йазид ал-Маши и ‘Абд ал-Карим бин ‘Абд ар-Рахим ат-Такнаши. Впоследствии, когда второй совершил переселение, остался лишь Шах-Ахмад. Он явился ко мне в дом со старыми, написанными пером свитками, и спросил совет относительно написания нового Свитка по их образцу, а также осведомился о том, что произошло между мной и коллегией. Я призвал его придерживаться Свитка [‘Усмана] и оживить Сунну сподвижников (да будет доволен ими Аллах). Вручив ему книги, посвященные правилам написания Свитка, я сказал: «Как тебе видно из подписи, коллегия отстранила меня от работы не по причине составления списка [Корана], но сославшись на мою занятость. Они питали ко мне злобу за некоторые вещи, а к тебе же у них претензий не будет». Первоначально Шах-Ахмад хотел составить список [Корана] без исправлений в соответствии с искаженным, но впоследствии решился и с юношеской заносчивостью приступил к исправлению Свитка в соответствии со списком ‘Усмана, указывая на места пауз, насколько ему позволяло его понимание и знания.

*Поднялись люди ради высоких свершений,*
*Когда увидели устремившимся к ним меня.*

Позже, в 1278 году он издал его и в конце разместил слова следующего содержания, взятые им из начала *дивана*[1] ал-Фудули: «Речь Аллаха извечная, необходимо почитаемая; в ее словах и окончаниях [слов] ввиду нерадения одного из числа современных редакторов были допущены ошибки; по причине ошибки в письме не различается [слово] العذب от العذاب; из-за выпадения головки буквы *ха* [не различается слово] البحر от [слова] البر; ввиду черной точки [слово] النعمة стало [словом] نغمة; из-за добавления другой [точки оно же стало] نقمة. Таким образом, Коран едва ли не был искажен полностью. По этой причине со стороны представителей Московского государства этому рабу [Божьему] было поручено дело исправления и сличения [списка Корана]». Таков смысл его речи.

Помимо того, что она написана ломаным языком, ее построение неправильно, а слова неточны, она представляет явную ложь. Ибо с моей стороны ни в одном слове, ни в одной букве не было допущено серьезных ошибок, искажений и описок, за исключением редких мест в виде огласовки, *сукуна*[2] или точки, поскольку человеку свойственно ошибаться и забывать.

Напротив, грубые ошибки и явные искажения были совершены им. Наименьшей из допущенных им ошибок, является пропуск на одиннадцатой строке триста девяносто шестой страницы в суре «Ангелы»[3] слова ذلك в словах Всевышнего: ذلك هو الفضل الكبير («Это и есть большая милость»)[4]; на шестой строке четыреста двадцать седьмой страницы в суре «Верующий»[5] слова من в словах Всевышнего: ما لكم من الله من عاصم («… но никто не защитит вас от Аллаха»)[6]; на девятой строке четыреста пятьдесят первой страницы суры «Дым» слова والأرض в словах Всевышнего: فما بكت عليهم السماء والأرض («Ни небо, ни земля не

[1] Диван – сборник стихов. – Прим. пер.

[2] Сукун – диакритический знак, передающий отсутствие после согласного гласного звука. – Прим. пер.

[3] Другое название суры «Ангелы» – «Творец». – Прим. пер.

[4] Сура «Творец», аят 32. Здесь и далее перевод Э.Р. Кулиева, за исключением мест, требующих прямого перевода. – Прим. пер.

[5] Другое название суры «Верующий» – «Прощающий». – Прим. пер.

[6] Сура «Прощающий», аят 33.

оплакивали их…»)[1]. Также он оставил многие из старых ошибок, которые не заметил. Что касается ошибок, связанных с текстом, местами пауз, начал аятов и тем, что он написал на полях, то их великое множество.

В завершении второго издания он на том же ломаном языке написал те же лживые слова, где были такие же и более грубые ошибки. В частности он пропустил слово لا в словах Всевышнего: عهدوا الله من قبل لا يولوهم الأدبار («А ведь прежде они заключили завет с Аллахом о том, что не обратятся вспять»)[2].

В изданиях 1282 и 84 годов на десятой строке сто шестидесятой страницы в суре «Сыны Исра’ила»[3] он пропустил слово إلا в словах Всевышнего: ما أنزل هؤلاء إلا رب السموت («… не кто иной, а только Господь небес и земли ниспослал их…») [4] наряду с другими грубыми ошибками и неточностями.

Помимо этого Шах-Ахмад возвел на меня ложь, заявив, что представители [Московского государства] утвердили его для этого дела после того, как обнаружили наличие в свитках [Корана] искажений. Тогда как в действительности Шах-Ахмад был утвержден для этого дела после моего отстранения ввиду моей большой занятости, обремененностью разрешением множества тяжб и рассмотрением [судебных] случаев, как это упомянуто [в письме] за подписями. Шах-Ахмад стал гордиться тем, что он приложил усердия в деле восстановления и распространения списка ‘Усмана; его невежественные друзья и скверные приятели стали хвалить его за то, что он исправил список [Корана] и оживил Сунну. При этом они все вместе осуждали меня, обвиняли в искажении [списка Корана], подстрекали против меня простонародье и знать.

После того, как дело сличения и исправления [списка Корана] вновь было возложено на меня, и он был издан под моим надзором, в конце Свитка я написал следующее: «Хвала Аллаху за Его щедрые дары и очевидные благодеяния, и да пре-

---

[1] Сура «Дым», аят 29.

[2] Сура «Сонмы», аят 15.

[3] Другое название суры «Сыны Исра’ила» – «Перенос ночью». – Прим. пер.

[4] Сура «Перенос ночью», аят 102.

будет благословение и мир над Мухаммадом – Его посланником и рабом, над его близкими и сподвижниками.

Далее. На этот раз к сличению Его Книги и ниспосланного Его Обращения [людям] обратил взор Его раб, надеющийся на Его милость и прибегающий [к нему же] от Его гнева, Шихаб ад-дин бин Баха' ад-дин бин Субхан ал-Марджани. Я утвердил его (список Корана) в соответствии с чтением 'Асима по версии Хафса бин Сулеймана; его слова расположены согласно списку свитка имама 'Усмана бин 'Аффана, утвержденного покойными имамами[5] уммы. В вопросе количества аятов сур я опирался на числа куфийцев, которые зафиксировал в соответствующих местах, приложив предельное усердие и старание. За короткое время он[6] исполнил то, с чем иной бы не справился. Это случилось, несмотря на отвлекающие препятствия и недостаток времени. Да простит Аллах то, что не усмотрели глаза и упустила мысль. Работа была завершена в субботу, по прошествии двух ночей месяца джумада ал-ахира 1285 года. Хвала Аллаху – Господу миров».

Когда Шах-Ахмад увидел мою редакцию списка Корана, его охватил гнев. В конце другого издания списка Корана под его редакцией он написал следующее: «Говорит раб [Божий], признающий [собственные] бессилие и недостатки, мулла Шах-Ахмад бин Байазид, нуждающийся в заботе своего Милостивого Господа: «Завершилось, в соответствии с послушанием, порученное мне редактирование [списка] Корана в конце месяца рамадан 1286 года от переселения Пророка, отправленного из [рода] бану 'аднан. Я признаю собственное бессилие, ибо человеку не избежать ошибок и упущения из памяти; он не защищен от отклонения пера и языка. Посему я прибегаю к Аллаху от дьявола языком и всеми органами и прибегаю к Нему всем сердцем от козней души, ибо поиск защиты только лишь на словах – одно из самых низких качеств. Этот прибегающий [к Аллаху человек], оставляющий [предписания религии] весьма вреден, особенно если учесть, что он обвинил того, кто

[5] Речь идет о знатоках рецитации Корана. – Прим. пер.

[6] Имеется в виду ал-Марджани. – Прим. пер.

признался в [собственных] упущениях, и, исполненный высокомерия и тщеславия, приписал совершение должного себе. Ибо успех, избавление от ошибок и вреда дает Отстраняющий беды, равно как и совершением должным наделяет Исполняющий нужды. Прибегаем к Аллаху от зла наших душ и скверны наших дел; хвала Аллаху в начале и завершении; молим Его достичь [наших] благих целей»». Таковы были слова надменного пустослова.

Когда осуществилось [очередное] издание Корана под моей редакцией, в его завершении я написал следующее: «Хвала Аллаху, благодаря благодеянию Которого свершаются праведные дела, и по милости Которого прощаются грехи, и да пребудет благословение и мир над Его Посланником Мухаммадом – лучшим, кто ходил по земле, и самым благородным, кто садился верхом, а также над его близкими и сподвижниками, далекими от низостей, почтенных, чистых от скверны грехов.

Далее. Пречистый Аллах по Своей благодетели и милости облегчил Своему рабу, нуждающемуся в Его прощении и помощи, Шихаб ад-дину бин Баха' ад-дину ал-Марджани, да сохранит его Аллах от грехов и ослушаний, сличение Его Хранимой Книги, которая: «К нему прикасаются только очищенные»[1], согласно чтению Хафса от 'Асима в соответствии со списком 'Усмана, руководствуясь в вопросе числа аятов мнением ученых Куфы. Прошу Великого Аллаха простить то, что осталось незамеченным для глаз, и что ускользнуло от мысли, ибо к Нему обращаются с просьбами, и Он принимает извинения. Сие случилось в воскресенье, за восемь ночей до истечения месяца зу-л-ка'да 1287 года. Хвала лишь одному Аллаху».

*Таковы моя и его истории,*
*Взгляни же на нас, между нами и для нас.*

Когда с него была удалена завеса и стала очевидна его ошибка, он, упустив время, признал собственную ущербность. Отрекаясь от совершенного, он сказал, что сейчас приносит

[1] Сура «Падающее», аят 79.

покаяние, однако [теперь] его вера не помогла ему, коль не было у него [прежде] послушания, соответствия со стороны сердца и ума. И был он «… подобен тому, кто простирает руки к воде, чтобы поднести ее ко рту, но не может этого сделать»[1].

ются в различных обстоятельствах, отличаются друг от друга по уму и способности понимать. На это он указал в произошедших случаях, на основе которых были утверждены базовые нормы шариата. [В своем совершенстве] эти предписания не были известны достойным мудрецам и незаурядным ученым. При этом Пророк не подражал примеру кого-либо, не руководствовался каким-либо законом, не посещал какую-либо страну, не обращался к кому-либо, не читал какую-либо книгу, не получал [знания] посредством общения с людьми и получения от них сведений, не выстраивал [логических] посылок и не [судил по] аналогии, как сказал Величайший: «Ты не читал прежде ни одного Писания и не переписывал его своей десницей. В противном случае приверженцы лжи впали бы в сомнение. Напротив, это – ясные аяты в груди тех, кому даровано знание, и только беззаконники отвергают Наши знамения»[1]. Посланник Аллаха (да благословит его Аллах и приветствует) сказал: «Мы – община неграмотная[2]: не умеем писать и считать. Месяц – вот так и так[3]». [Все это он явил] благодаря одному лишь божественному дару и господнему Откровению. Он обнаружил свет Его религии и истину за кратчайшее время, превознеся ее над всеми другими религиями[4]. Пророк (да благословит его Аллах и приветствует) начал свой призыв в одиночестве среди народа невежественного, неверного, упрямого. В нем было обыденным кровопролитие, притеснение, детоубийство, разрушение; у него не было представлений о науках и правил приличия. Все, что его отличало, – это невежественный пыл, единение и приверженность племени, обусловленные заблуждением, как сказал Величайший: «... чтобы ты предостерег людей, отцов которых никто не предостерег, из-за чего они оставались беспечными невеждами»[5].

[1] Сура «Паук», аяты 48–49.

[2] Имеются в виду мусульмане, жившие во время Пророка (да благословит его Аллах и приветствует). – Прим. пер.

[3] То есть Пророк (да благословит его Аллах и приветствует) указал на количество дней месяца посредством пальцев. – Прим. пер.

[4] См.: сура «Покаяние», аят 33. – Прим. пер.

[5] Сура «Йа Син», аят 6.

Пророк (да благословит его Аллах и приветствует) искоренил все это посредством своего ясного призыва и того, чем он обладал из способности искусно обучать и излагаться. Все, что он вменил, – то, что содержит ниспосланная ему от Аллаха Мудрая Книга и Великий Коран, и иное из Откровения и вдохновения, что заключено в достоверных сводах Сунны, переданных многочисленными передатчиками, он наилучшим образом без упущений исполнил самолично. Каждое изречение Пророка представляет собой море мудрости и мир знания. Если бы над ними принялся размышлять человек недюжинный и набожный с тем, чтобы извлечь из их бездны заключенные в них знания и мудрость, то он не познал бы и толики из его чудесных и удивительных дарований, даже если бы он посвятил всю свою жизнь и утомил взор, как на это указал Пречистый: «Мы ниспослали тебе Писание для разъяснения всякой вещи, как руководство к прямому пути, милость и благую весть для мусульман»[1]; «Мы преподнесли им Писание, которое разъяснили на основании знания, как верное руководство и милость для верующих людей»[2]; «Он ниспослал вам Писание, подробно разъяснив его»[3].

В этой связи Пророк всячески побуждал к чтению Его Книги и размышлению над ее смыслами, чтобы увидеть ее ценность и постичь суть. Призывал бы Пророк к этому, не будь он убежден в достоверности и истинности Корана? Взгляни же, разумный человек, на величие и смыслы Корана, и состояние Пророка и поразмышляй: не это ли истинное пророчество и призыв людей от имени Аллаха? Или тебе известно что-то иное? Ведь Пророк являлся неграмотным, не умел писать и считать, не обучался когда-либо; он рос в эпоху невежества, неверия и заблуждения сиротой на попечении своего бедного [дяди]. Та великая добродетель, которой он обладал, те совершенные знания, которые он явил, с учетом известных обстоятельств его жизни, являются величайшим свидетельством его правдивости и истинности его пророчества и Послания. Все это может скрыть разве что рок

[1] Сура «Пчелы», аят 89.

[2] Сура «Преграды», аят 52.

[3] Сура «Скот», аят 114.

несчастья и заблуждения. Как верно подметил ал-Бусыйри (да смилуется над ним Аллах):

*Достаточно тебе в качестве чуда наличие знания у неграмотного,*

*В невежестве и этикета у сироты.*

Это чудо гораздо убедительней всевозможных доводов, тверже указаний анналов и времени, избавляет сердце от колебаний и различных сомнений. Если ты рассмотришь одно относительно другого, то познаешь истинным познанием Послание Мухаммада и истинность его пророчества, не нуждаясь в доказательствах, подобно тому, как ты знаешь правдивость человека, который говорит, что он знает по памяти [весь] Коран, поскольку ты слышал его чтение, и подобно тому, как ты знаешь правдивость того, кто говорит, что он перенес такой-то вес железа, поскольку ты наблюдал воочию, как он его поднимал. Достохвальный сказал: «Скажи: «Воистину, знамения – у Аллаха, а я – всего лишь предостерегающий и разъясняющий увещеватель». Неужели им не достаточно того, что Мы ниспослали тебе Писание, которое им читается? Воистину, в этом – милость и напоминание для верующих людей»[1]. Это явилось ответом на требование многобожников: «Почему ему не ниспосланы знамения от его Господа?»[2], желавших увидеть сверхъестественное и чудо, подобно тому, как [Аллах] даровал самудитам в качестве ясного знамения верблюдицу[3], сделал мягким железо для [пророка] Дауда (да пребудет над ним мир)[4], даровал Мусе сияющую руку[5], превращение посоха в змею[6], [даровал] ‘Исе способность исцелять слепых, оживлять мертвых.

Всевышний Аллах опроверг неверных посредством следующего.

Во-первых. Подобного рода чудеса и сверхъестественные явления не являются необходимостью пророчества и предтечей Послания; пророк Мухаммад не являлся единственным, кто

[1] Сура «Паук», аяты 50–51.

[2] Сура «Паук», аят 50.

[3] См.: сура «Перенос ночью», аят 59. – Прим. пер.

[4] См.: сура «Саба’», аят 10. – Прим. пер.

[5] См.: сура «Та Ха», аят 22. – Прим. пер.

[6] См.: сура «Та Ха», аят 20. – Прим. пер.

обладал подобными чудесами. Они представляют собой один из светов пророчества и то, что ему сопутствует. Этими чудесами распоряжается Аллах, показывая их тогда, когда пожелает; Он наделяет Своей милостью кого пожелает.

Во-вторых. Многобожники могли видеть доказательства [истинности] послания Мухаммада и знамения его правдивости, истинность того, что ему даровал Аллах из Ясной Книги, наблюдали воочию его праведное поведение в повседневной жизни, что является наиболее правдивым доводом и самым справедливым свидетельством относительно утверждаемого. Вместе с этим их отрицание Пророка и требование предоставить иное чудо означало требование получить меньшее при наличии большего, покупку заблуждения за истину, замену лучшего худшим. Ибо состояние обладателя всякого умения или ремесла лучше всего становится известным посредством наблюдения плодов его труда и речей. Ведь ты, не испытывая сомнений, знаешь Абу Ханифу, благодаря его познаниям в фикхе, Абу ‘Али[1] – благодаря его мудрости, если тебе знакомы фикх и мудрость. Обоих ты узнал посредством плодов их труда и знания их речей. Это позволяет тебе знать, что такое суть фикх и мудрость.

Подобно этому отношение всякого ремесла к ее обладателю, будь то поэзия, красноречие и иное; даже вторичные ремесла, такие как окраска одежды, шитье и пр. Достохвальный сказал: «Скажи: «Я призываю вас только к одному: встаньте ради Аллаха по двое и по одному, а потом призадумайтесь. Ваш товарищ не является бесноватым. Он лишь предостерегает вас перед наступлением тяжких мучений»[2]. Пророк призвал своих соплеменников подняться искренне ради Аллаха, отрекаясь от всего, что кроме Него, из подражания [предкам], и разойтись по двое и по одному, чтобы познать суть его дела и разобраться в том, с чем он явился, путем размышления над тем, что содержит его призыв из знаний, что заключает в себе из мудростей. Это позволит прийти к истине, познать правдивость Пророка и то, с чем он явился. Каждый из двоих, поразмыслив, предложит

[1] Имеется в виду Ибн Сина. – Прим. пер.

[2] Сура «Саба’», аят 46.

итог своих размышлений своему товарищу, над чем они честно и беспристрастно поразмышляют совместно, не отклоняясь под воздействием страсти, подавляя порыв племенного пыла, чтобы праведная и правильная мысль привела их к истине. Ибо человек в одиночестве оказывается способен выполнить задачу, размышляет сам с собой искренне и беспристрастно, представляет мысль на суд разума, остается наедине со своим рассудком без лицемерия. Тогда как при скоплении людей путаются мысли, слепнут умы, портится мышление, возникает предвзятость и оставляется беспристрастность, возбуждается слепая приверженность [предрассудкам].

При этом многобожники признавали целомудрие Мухаммада (да благословит его Аллах и приветствует), правильность его ума, кротость, остроту сознания, основательность суждения, его достоинства мужа и совершенные качества.

Если бы Пророк не был убежден относительно своего дела и в его истинности – в том, что он является избранным от своего Господа для пророчества и Его Послания, то не стал бы призывать к опасному делу, рискуя благами жизни мирской и уделом жизни вечной, оказаться разоблаченным на глазах у свидетелей и подвергнуть себя вечной гибели. Такое не постигается посредством мечтаний и с помощью каких-либо средств. Ведь чем дороже и благороднее цель, тем труднее оказывается путь ее достижения и тем больше возникает преград.

В том, кто заявляет о пророчестве, наличествуют две вещи.

Либо одержимость и отсутствие страха оказаться разоблаченным в случае, если потребуют предоставить аргумент. Если не сказать, что таковому и вовсе неизвестно, что такое разоблачение и опасность его последствий. Либо погружение в красоты мирской жизни, предание ее страстям и наслаждениям, стяжание ее польз и стремление к ее вершинам.

Но каждому было известно о совершенстве и степенности ума Мухаммада (да благословит его Аллах и приветствует), его полном отрешении от мирской суеты. Всевышний сообщил об отсутствии этих двух качеств в Своем Пророке, сказав: «Ваш товарищ не является бесноватым. Он лишь предостерегает вас

перед наступлением тяжких мучений»[1]; «То вознаграждение, которое я прошу от вас, предназначено вам самим, а меня вознаградит только Аллах. Он – Свидетель всякой вещи»[2].

Посему не уподобляйтесь неверным, которые обвинили Мухаммада (да благословит его Аллах и приветствует) во лжи, ослушались и отвергли знамения Аллаха, утверждая, что Мухамммад не явил чудес. Ибо аяты Корана представляют собой большее чудо, чем чудеса какого-либо иного посланника; Коран – величайшее из чудес пророков, «не подберется к нему ложь ни спереди, ни сзади»[3]. Коран является доказательством пророчества Мухаммада для каждого; его Послание адресовано всем людям и будет действовать до скончания времени; это чудо имеет возможность наблюдать каждый. То, о чем говорится в Коране, является самим пророчеством, содержащиеся в нем предписания являются самой его миссией. Наличие Корана избавляет от потребности в других знамениях. Образ жизни Посланника – да пребудут над ним лучшие благословения и приветствия – является доказательством прямого пути, как на это указал Всевышний Аллах: «Уверуйте же в Аллаха и в Его Посланника, неграмотного (не умеющего читать и писать) Пророка, который уверовал в Аллаха и Его Слова. Последуйте за ним, дабы вы последовали прямым путем»[4]. Пророк вместо [глагола] первого лица употребил [глагол] третьего лица с тем, чтобы применить эти – побуждающие к вере в того, кто обладает ими, и следованию за ним – качества в отношении всякого, будь таковым он сам или кто-либо иной. Тем самым Пророк предоставил наилучший аргумент [для веры в него], обнаружил для людей беспристрастных [истину], предостерег от домыслов, вызываемых слепой приверженностью [предрассудкам], указал на то, что совершенство его познаний, при том, что он не умел ни читать, ни писать, является одним из его чудес и неопровержимым доказательством совершенства его религии

[1] Сура «Саба'», аят 46.

[2] Сура «Саба'», аят 47.

[3] См.: сура «Разъяснены», аят 42. – Прим. пер.

[4] Сура «Преграды», аят 158. – Прим. пер.

и закона и очевидным, удаляющим сомнения свидетельством относительно истинности его пророческой миссии.

К истинности изложенного нами приведут всесторонние размышления и укажут различные сообщения; его приняли прозорливые праведники. Коран ввиду общности пророчества Мухаммада адресован всем людям; его закон действителен в каждом месте и во все времена. Коран доступен [для изучения] каждому человеку в любое время, позволяет видеть Послание воочию и общаться с ним. Его ниспослал Святой Дух от твоего Господа с истиной, чтобы укрепить тех, которые уверовали, и как прямой путь и радость для верующих[1]. Тот, кто уверовал, увидев сияющую руку [Моисея] и змею, возможно, впадет в неверие, увидев «изваяние тельца, который мычал»[2].

*Кереш сүз һәм тәрҗемәне басмага Абдулла Сәлахов әзерләде*
*Введение и перевод на русский А. Салахова*

[1] См.: сура «Пчелы», аят 102. – Прим. пер.
[2] См.: сура «Преграды», аят 148. – Прим. пер.

# II бүлек
# Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлеге хакында вакытлы матбугат

*Мәрҗани бик олуг, XIX гасырның бер дә көтелмәгәндә безгә бүләк ителгән бер даһисы иде...*

*З. Кадыйри*

## Йөзьеллык юбилее көннәрендә...

Ш.Мәрҗани яшәгән елларда татар телендә әле бер генә дә газета яисә журнал нәшер ителми иде, чөнки патша режимы моңа һәрчак каршылык тудырып торды. Шунлыктан да бу вакытларда аның фәнни-иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлегенә теге яки бу рәвештә мөнәсәбәт белдерү мөмкинлеге юк иде. Бары тик 1905–1907 елгы инкыйлабый хәрәкәтләр чорында гына татар зыялыларының вакытлы матбугат органнары булдыру теләк-омтылышы тормышка аша алды. Билгеле ки, аларның битләрендә, барыннан да бигрәк, үз заманының сәяси, икътисади, милли, дини, мәдәни, әдәби проблемалары яктыртылырга тиеш булды. Әмма шунысы да мәгълүм: татар журналистлары, публицистлары, нашир-мөхәррирләре көн кадагында торган – яңа заманда аеруча актуаль яңгыраш алган проблемалар белән бәйләнештә халкыбызның үткәненә нисбәтле мәсьәләләр турында да фикер йөрттеләр, укучылар игътибарын татар милләтенең тарихи язмышында чагылыш тапкан, катлаулы, үкенечле дә, кайчак исә горурлык та тудыра торган сәхифәләренә дә юнәлттеләр. Вафатына әллә ни күп гомер узып өлгермәгән бөек мәгърифәтче, тарихчы, дин галиме Ш.Мәрҗани исеме дә, 1910 еллардан башлап, вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле урын ала башлады. Татар зыялылары аның дөньяга килүенә

һиҗри белән 100 ел тулуын хәтергә алып, 1915 ел башында төрле характердагы язмалары белән газета һәм журналларда шактый актив чыгыш ясыйлар. Бу шулай ук Мәрҗани күтәргән дөньяви һәм дини-фәлсәфи мәсьәләләрнең актуальлеге яңа вазгыятьтә дә һич кимемәгәнлеге белән дә аклана иде. Аның турындагы материаллар 1915 елда ук махсус бер китап-җыентык рәвешендә «Мәрҗани» дип исемләнеп нәшер ителде. Шунысы да бар, зыялыларыбыз, аның дөньяга чыгуын көтеп тормастан да, газета һәм журналларда әледән-әле чыгыш ясап торалар. Алар татар иҗтимагый фикер тарихына караган гыйльми эзләнүләрдә дәлил-чыганаклар сыйфатында кулланыла ала. Ике йөзьеллык юбилее уңае белән әзерләнгән ошбу китапка бу чыгышларның беркадәресен кирилл язуында әзерләп урнаштыру мәслихәт күрелде. Билгеле ки, аларның эчтәлеге, тематикасы ягыннан да, материалның бирелеше, текстларының төзелеше ягыннан да төрлелек күренә. Редакциягә хатлар, хәбәрләр, җаваплар, әңгәмәләр, кайчакларда проблемалы мәкаләләр рәвешендәге бу язмалар төрле тарафта чыккан матбугат чараларында басылган. Алар – «Йолдыз», «Кояш» газеталары, «Әд-Дин вә әл-Әдәп» журналы (Казанда чыкканнар), «Идел» (Әстерхан), «Ил» (Мәскәү), «Тормыш» (Уфа) газеталары, «Шура» (Оренбург) журналы. Чыгыш ясаучылар арасында татар әдәби процессында, публицистикасы һәм журналистикасында, милли-иҗтимагый хәрәкәтендә шактый зур роль уйнаган иҗади шәхесләрне күрәбез. Мәсәлән, Ризаэтдин Фәхретдин, Габделбари Баттал, Закир Кадыйри, Шәһәр Шәрәф, Нәҗиб Гасрый, Әхмәдзәки Вәлиди, Габдерахман Гомәровлар. Мәкаләләрнең кыскаларында да, күләмлеләрендә дә Шиһабетдин Мәрҗанинең язма хезмәтләре, кырык ел дәвамында имам, мөдәррис буларак алып барган эшчәнлеге хөрмәт белән тәкъдир ителә, татарларда беренче мәртәбә үзенең бөек улына 100 еллык юбилейны лаек рәвештә, аеруча зур әзерлек белән уздыру кирәклеге басым ясап әйтелә, олпат галимнең хезмәтләре, бәһасез мирасы, киңкырлы эшчәнлеге хакында фикерләрен, борчуларын да белдереп, бу эшнең киләчәктә дә дәвамлы булуына ышаныч белән карала: «Вакыты

берлән, иншааллаһ, бөек Шиһаб хәзрәт милләткә үзенең әсәрләре вә аның хакында язылачак рисаләләр, китаблар белән тәмам аңланыр. Шулвакыт милләт аның юбилеен газамәтле[1] рәвешдә Шиһаб хәзрәткә муафикъ сурәтдә ясар» (Н.Гасрый). Закир Кадыйриның «Бу көн Мәрҗани туды» исемле язмасында, Ш.Шәрәф, Ягъкуб Хәлили мәкаләләрендә Мәрҗанинең биографиясенә кагылышлы кызыклы мәгълүматлар да китерелә. З.Вәлиди исә «Йолдыз» газетасында: «Ул дөньяның мәдәни хәятында зур урын алырлык булмаса да, безнең үзебез өчен зур. /... / үземездән килгән олуг бер шәрык галиме дип кенә түгел, бәлки ошбу яңа мәдәни хәрәкәт ноктасындан искә аламыз. /.../ череп беткән Бохара эчендә торып, ислам галәмендәге башка мөнтәхәб (сайлап алынган) мөтәфәккирләр арасына керүләре һәм шуларның монда кайтып хезмәт күрсәтүләре – тарихымыз бабында гаять кызык бер эшдер», − дип яза. Шәриф Хөсәенов исә «Сөембикә» журналындагы язмасында Мәрҗани һәм хатын-кыз темасына тукталган («Мәрҗани үзенең бөеклегенә мөнасиб рәвештә хатын-кыз сыйныфын да олуглаган. Аларны укытуны, әлбәттә, ул бик кирәксенгән, бик химая иткән»). Сүзен «юбилей безнең гомуми булып, татар хатыннары да үзләренең бөек кешеләрен хәтерли белүләрен күрсәтергә, тавышларын гомуми матбугатта яңгыратырга тиешлеләр», – дип тәмамлый[2]. Галиәсгар Чыгътай «Шиһабетдин әл-Мәрҗани хакында фикерләр» исемле мәкаләсен: «Мәрҗани хәзрәтләрен һәркем үз күзе белән карый, аның хакында һәркем үз фикерен алга сөрә», – дип башлап, ары таба Галимҗан Баруди, Һади Максуди, Габделбари Баттал, Габдулла Гыйсмәти, Кәшшаф Тәрҗемани, Исмәгыйль Габиди, Зәки Вәлиди, Фатих Әмирхан, Ибраһим Бикколов фикерләрен китерә.

Бу китапка Шәһид Әхмәдиевнең «Юбилей көне» исемле язмасы да урнаштырылды. Ул мәкалә жанрында түгел, утопик хикәя рәвешендә иҗат ителгән. Анда Мәрҗанинең юбилей көнендә (бүгенге заманда) 50 яшьлек булып терелеп (уянып),

[1] Газамәтле – тантаналы.

[2] Китапка З.Вәлидинең тагын ике мәкаләсе кертелде. «Мәрҗани» китабында да (1915) аның ике мәкаләсе бар.

туганнары белән шатланып сөйләшүләре, татар тормышындагы яңалыкларга гаҗәпләнүләре хикәя ителә (балалар кичәсендә 6–7 яшьләрдәге кыз бала «Туган тел»не җырлый, Мәрҗани «шатлык вә дулкын эчендә кала»). Анда Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» сатирик повестенда кулланылган әдәби алым иҗади файдаланылган шикелле. Хәтта ике хәзрәтнең дә уллары Әхмәд исемлеләр. Ш.Әхмәдиев хикәяләвендә Мәрҗани образы позитив яссылыкта бирелә, ул яңалыкларга шатлана, аны «татар матбугаты гарешкә күтәрә». Әхмәд «халыкка хезмәте белән мәшһүр унъеллык гәзитәнең баш мөхәррире Һ.[1], халык хадиме ... газетасының баш һәм эшлекле мөхәррире F.», «татарның зур әдибе, ... татарга әдәбият нигезен салган һәм тел биргән кеше G[2].»ларны атап күрсәтә, мөхәррирләрнең, шагыйрьләрнең Мәрҗанине тәкъдир итүләрен сөйли.

Гомумән, XX йөз башы вакытлы матбугаты үзенең сәхифәләрендә татар милләтенең бөек улына зур ихтирамын чагылдырган, аның исемен халкыбыз күңелендә яшәтү юлында зур өлеш керткән.

*З.Рәмиев, Л.Гарипова*

## Мәрҗани хакында җавабым

«Шура»ның 11нче саны «Мөхабәрә» кыйсмендә өч сөаль язылыб, карилардан шуңа җаваб таләб иделмеш иде. 3нче сөаль хәзрәт Мәрҗани хакында улыб, «милләтемезә нә кеби хедмәтләр күстәрде вә бу хедмәт фикрияләренең тәэсирене дөньяда вакытында күрделәрме?», – дия язылмышдыр. Бән исә, Мәрҗанинең шәкерде улдыгымдан, 3нче сөальнең җавабы бәнем тарафымдан язылмасы лязим кеби күренеб, «Шура»ны укыгач да, җавабымы хәзерләб куймыш идем. Ләкин төрле мәванигъ[3] сәбәбле, ошбу көнгәчә калдырылды. Ул тугрыда башка кемсәләрдән җаваб күренмәгәнендән, җавабны күндермәк булдым.

[1] Һади Максуди истә тотыла.

[2] Сүз Гаяз Исхакый турында барса кирәк.

[3] Мәванигъ – каршылыклар; киртәләр.

Остаз мөхтәрәм хәзрәт Мәрҗанинең хезмәт мәлияләре күб булса да, монда фәкать бәгъзеләрдән[1] языб, тәфасыйлене китабларындан караб белмәкләре илә тәүсыя идәмен[2].

Мәрҗани хәзрәтләренең милләтемезә күстәрмеш хедмәтләре, башлыча, шулардан гыйбарәтдер:

1) Коруне вөстә[3] вә коруне мөтәаххирәләрдә[4] гыйльме игътикад илә гыйльме калям тәфрик иделмәй[5]. Хәтта бер кемсә мәсаил[6] калямиядән бер мәсьәләгә инкяр итсә, аны тәзълил[7] идеб, кяфер булды дия хөкем идеб, олуг хаталарга төшәр идек. Хәтта боның хата икәне дә хәтеремезә килмәз иде. Хәзрәте Мәрҗани исә ошбу маддәләргә дөшенеб, гакаиде сәляф башка вә гыйльме калям дәхи башка бер гыйлем улыб, соңындан пәйда улмыш бер әмре мөстәхәддис[8] вә сәләф гыйндендә[9] мәзмум[10] гыйлемләрдән улдыгыны китабларында бәян идеб, күб ихтиляфларның[11] киселмәкенә сәбәб улдылар.

2) Әдилла[12] ки тимсәк, мөҗтәһидләр шаэнедер[13]. Заман иҗтиһад исә дүрт йөз елдан соң мөнкарыйздыр[14], соңындан киләнләрнең әдилләгә тәмәссекләре[15] җаиз улмаз[16], Коръән Шәриф вә «Әхадис Нәбәвия»не укысак да, фәкать саваб өчен, әхадисне дә рәсүлулланың кауле диб, фәкать тәшәрреф өчен

---

[1] Бәгъзеләрдән – кайберәүләрдән.

[2] Тәүсыя идәмен – васыять итәмен.

[3] Коруне вөстә – урта гасырлар.

[4] Коруне мөтәаххир – соңгы гасырлар.

[5] Тәфрик иделмәй – аерылмаган.

[6] Мәсаил – мәсьәләләр.

[7] Тәзълил – туры юлдан чыгару; адаштыру.

[8] Әмре мөстәхәддис – яңа карашлар, кагыйдәләр.

[9] Гыйндендә – янында.

[10] Мәзмум – хурланган, сүгелгән.

[11] Ихтиляфларның – каршылыкларның.

[12] Әдилла – дәлилләр.

[13] Шаэнедер – эшедер.

[14] Мөнкарыйздыр – бетәчәк.

[15] Тәмәссекләре – тотынулары.

[16] Җаиз улмас – әзер булмас.

генә укыр идек. Бу хикмәт чишмәләрендән, башкача һич шәй[1] мөляхәзә иделмәз[2], хәтта бонлар илә истидлялне[3] җаиз күрмәй, «дәлил алмакдан каул әл-мөҗтәһид вә каул фикъһа мөкаддәм бер әдиллә нәкълия[4], безләр исә һәр кайсымыз мөкалләдемез[5]. Безләргә каул фикъһа йитәдер, риваять китабларында күрелмеш кулларны һич тәфтиш итмәздән, кабул итмәк тиеш вә гамәл итмәк лязим» дия йөрер идек һәм шулай булдык. Мәрҗани хәзрәтләре бу фикернең хата идекенә дөшенеб, әдилләгә тәмәссек, икътидары[6] вар адәмләрнең һәр кайсына җаиз вә һәр мәсьәләне әдилләгә татбикъ[7] важиб вә бу кеби хасаләт[8] ифрат өметдән һичкемгә хас дәгел, заман иҗтиһад һич мөнкарыйз улмаз, Җәнабе Хакның кодрәте заман вә мәсафәләр[9] илә тәхдид иделмәз[10] дия бәян идеб, әүләде өммәткә[11] бер төрле хөррият фикрия вирде; тәкълид[12] корытылмакымыза вә һәр шәйнең асылын вә түбән эзләмәкемезгә сәбәбче улды. Гәрчә бу мәсьәлә хакында башлаб тәнбиһ[13] идүче Курсави хәзрәтләре улса да, мәсьәләне тәмам ачыб, әдилләләрен бәян вә нәшер идүче ошбу Мәрҗани хәзрәтләредер.

3) Әкъсаре ләялдә[14] гыйшаның[15] сөкүте[16] олуг-олуг ихтиляфлар[17] вар иде. Һәр ике тараф бер-беренә җәрех[18] идәрләр вә

---

[1] Шәй – әйбер; нәрсә.

[2] Мөляхәзә иделмәз – каралмас; күзәтелмәс.

[3] Истидлялне – нәтиҗә чыгаруны.

[4] Нәкълия – күченгән.

[5] Мөкалләдемез – иярелгәнебез.

[6] Икътидары – мөмкинлеге, куәте.

[7] Татбикъ – туры килгән.

[8] Хасаләт – нәтиҗә; эшнең нәтиҗәсе.

[9] Мәсафәләр – аралар.

[10] Тәхдид иделмәз – формалашмас.

[11] Әүләде өммәткә – милләт балаларына.

[12] Тәкълид – берәр төрле традицияләргә, фикерләргә иярү.

[13] Тәнбиһ – игътибар.

[14] Әкъсаре ләялдә – иң кыска төннәрдә.

[15] Гыйшаның – кичке намазның.

[16] Сөкүте – эчтән укыла торган догалар турында сүз бара.

[17] Ихтиляфлар – бәхәсләр.

[18] Җәрех – яра.

рисаләләр язышырлар иде. Әксәрият исә Гыйшаның фарызлыгында яки казаның лөзүмендә[1] булса да, дәлилләре куәтле улмадыгындан ихтиляф һаман тәмам булмады. Хәзрәте Мәрҗани ошбу хакда «Назурәтел хак» китабыны тәэлиф идеб, әкъсаре ләялдә хәтта һич төн булмаган урынларда да гыйшаның фарызлыгын куәтли вә әсаслы дәлил илә исбат идеб, ошбу низагның киселмәкенә сәбәб улдылар.

Бондан магыйдән күб өмур[2] дөньяда ма һуввәл хак[3] вә мөхассес савабны бәян идеб, гаять дәкыйк[4] вә мөһим мәсьәләләргә тәнбиһ кылдылар. Бахосус Каләм Шәрифне тәсхихдә[5] иҗтиһадлары вә тәсмия әүлад тугрысында булган тәнбиһләре – шаян дикъкать вә олуг хедмәтләрдер.

Каумымыз[6] арасында җәһаләт галиб улыб[7], хакыйкый гыйлем илә иштигаль итмәй, фәкать җәдәл[8] вә бераз фикъһ илә иштигаль идеб, сәләфләремезнең безә калдырмыш йимешләре улан китаб вә сөннәт галимләрендән вә сәбәбе тәмәдден улан фәнләрдән бил көллият мәхрүм идек. Мәдаре кәмаләт һәм дә каумемез арасында игътибар шул җәдәл вә мөназарәләргә мәһарәтдән гыйбарәт улдыгындан, һәр кайсымыз газиз гомерләремез вә кыйммәтле улмаян вакытларымызы шул юлда заигъ[9] идеб, китаб вә сөннәт гыйлемләрендән бихәбәр улыб, тарих, җәгърафия вә хисаб китабларыны гыйлемдән санамай, хәтта бонлар илә иштигальне тәзйигъ гомердән гадд[10] идәр идек. Мәрҗани хәзрәтләре исә бу рәвешле булмаенча, һәр гыйлемдән ма һувә әл-максуд[11]ны аңлаб, китаб вә сөннәт гыйлемләрен би камәлә тәхсил идеб, тәхсил мөмкин улган фәнләрнең һәркай-

---

[1] Лөзүмендә – кирәклегендә.

[2] Өмур – хәлләр.

[3] Ма һувәл хак – нәрсә ул хак.

[4] Дәкыйк – төгәл.

[5] Тәсхихдә – төзәтүдә.

[6] Каумымыз – халкыбыз.

[7] Галиб улыб – күпчелек булып.

[8] Җәдәл – бәхәсләшү.

[9] Заигъ – кимчелекле.

[10] Гадд – кире кайту.

[11] Ма һувә әл-максуд – максат нәрсәдә.

сындан хәбәрдар улыб, милләтемезнең ризаләтдән корытылыб, тәрәкъкый юлына кереб, шул фәнләрнең зарур улдыгыны вә бу фәнләр динемезгә хилаф улмай, бәлки шәригатемезнең боерыгы улдыгыны «Әш-шәрига ля түкәззиб әл-хикмә»[1] вә «Әл-фән хәйр көллү»[2] дия китабларында кычкырыр булды. Әксаме фөнүнне вә ул фәнләрне әһле исламда кемләр башлаб чыкардыгыны вә бу фәнләрнең әһле Ислам арасында интишары[3] кай рәвешдә булдыгыны вә бу фәзаильдән мәхрүмиятемезгә сәбәб нә шәйләрдер... Барчасыны языб, каумемезгә сәгадәт юлы күстәрде. Бу кеби хәлләргә дөшенмәк өчен баш сәбәб тарих улдыгындан гомуми вә хосусый тарих китаблары язмая башладыйу, билхосус каумемезнең тарихын язмак әһам[4] улдыгындан шул юлда үзен кызганмай иске китаблар вә иске мәктүбләрдән[5] мәгълүмат туплаб, хәтта каберстанларга йөреб, зиярат ташлары караб асар гатикаләр[6] күз салыб, Болгар вә Казан тарихларын язмакка муафыйк улды. Каумемез арасында мәгарифе җәдидә һич юк икән, аңа башлаб, күз салыб мөһим идеген бәян идүче, әдәбиятымыз һәм башлаб нәзар салучы[7] вә милләт Ислам элек хәлендә дөнья йөзендә беренче тәмәдденнән[8] каумләрдән улыб, анлар заманасында тәрәкъкыяләр[9] кай дәрәҗәдә булган вә бу тәмәдденнең сүнмәкенә ниндәй афәтләр сәбәб булганлар... барчасын башлаб язучы вә таифәмезә[10] башлаб белгертүче ошбу Мәрҗани хәзрәтләре булды. Бу җәһаләтемезгә олуг сәбәбдә тәхсилемездә тәртиб юклыгы, чын гыйлем хасыйл итмәгемез өчен мөкаддимәләр берлә генә иктифа итмәй[11], бәлки һәр гыйлемнең мәсьәләләрендән хәбәрдар улмак вә тәртиб илә тәхсил итмәк зарур вә каумемез

[1] «Шәригать алдамый хикмәттә».
[2] «Барлык фәннәрдә бары тик файда, игелек кенә».
[3] Интишары – таралуы.
[4] Әһам – мөһим.
[5] Мәктүбләрдән – хатлардан.
[6] Асар гатикаләр – борынгы эзләр; элек булып үткәннәрнең калдыклары.
[7] Нәзар салучы – күз салучы.
[8] Тәмәдденнән – цивилизациядән.
[9] Тәрәкъкыяләр – үсешләр.
[10] Таифәмезә – төркемебезгә.
[11] Иктифа итмәй – канәгатьләнмичә.

өчен дәүләтемезнең язу вә лисанны[1] вә каванин мәүдугасыны[2] белмәк важиб вә лязимдер дия башлаб язучы, таифәмез өчен башлаб кайгыручы вә шул юлда булган дәкаике[3] өмурларга төшенүче – остаз мөхтәрәм хәзрәт Мәрҗанидер.

Гәрчә ул кеби олуг вә тәкъдирсез хедмәтләрдә булынса да, аның кадерен белүче, китабларын вә әфкярләрен кабул итүчеләр заманасында аз иде. Алкышларга вә ярдәмләшергә тиеш булган хедмәтләре бер-беренә гасырдашлары тарафындан җәфалар күрер вә күб ифтиралар ишедер иде. «Гасырдашларым, гәрчә кадереме ул кадәр белмәсәләр дә, соңлар шаяд кадереме белерләр, бән сүземне дә шунларга караб сөйләдем», – дия һәрвакыт бәян идәр вә шуның илә мөтәсәлли улыб, таифәмезнең аякланууларындан һаман өмидене кисмәй, хакиманә сурәтдә иҗтиһадларында даим улыб, хаклыкны язмакдан вә тугры юлны күстәрмәкдән һич ялыкмаз иде.

Остаз Мәрҗанинең дидекләренчә, бу көндә аның кадерен белүчеләр күбәйде, хәтта вафатына 25 ел якынлашу мөнәсәбәте илә ядкәр хәзерләмәк сәдәдендә[4] булынмаклары да ишеделмәя башлады. Бу кеби хәлләр – таифәмезнең уйгануына вә тәрәкъкый юлына керүләренә олуг дәлилдер.Чөнки җәһаләтемезнең баш сәбәбе дә шул гыйлемнең вә әһленең кадерен белмәвемез иде.

Остаз мөхтәрәмнең хедмәт мәлияләрен тәмаман тәгаддад[5] мөмкин улмадыгындан, фәкать бераз әхвален языб, әхвалендән сораб язучы әфәндегә тәхсин идеб[6], укучыларга ошбу бәянат гарыз әйләдем[7].

*Мәкалә Х.Үтәки тарафыннан язылып, 1911 елны «Шура» журналының 23 нче санында дөнья күрә.*

*Текстларны басма өчен Алсу Хасавнех әзерләде*

[1] Лисанны – телне.

[2] Каванин мәүдугасыны – законнар темасын.

[3] Дәкаик – төгәл.

[4] Сәдәдендә – ниятендә.

[5] Тәгаддад – санау; барлау.

[6] Тәхсин идеб – яхшылык күрсәтеп.

[7] Гарыз әйләдем – күрсәттем.

## Идарәгә мәктүбләр: Габделхәбир әл-Мөслими вә Мәрҗани хакында

(12 нче гадәд «Шура» тышында Питрапаул халыкларына язылмыш мәктүб мөнәсәбәте илә)

Дамелла Габделхәбирнең хәфиде[1] хакында Тәүфыйк әфәндедән «Шура» тышында язылдыгына күрә, Мәрҗани мәктүбләрене сораб вә эзләб карадым исә дә, нам вә нишанлары беленмәде. Аллаһы әгъләм[2], бу мәктүбләр шимди заегъ[3] улмышлардыр. Безнең «Питрапаул» әһалисе[4] гомумән диярлек, искедән җәһаләт хамисе вә гыйлем дошманы улыб килмешләрдер. Габделхәбирне лаек дәрәҗәдә белмәк кайда, бәлки аны кадерсез кылыб, хәтта аның хакында «карта уйнаб алмыш акчаларны хәләл күрә вә фахишәләр илә кәсеб итү дөрест дия фәтва бирәдер», димәк кеби ничә төрле ифтираләр иҗад иткәнләр. Шул вакытда Питрапаул байларындан ялңыз Хәмзә бине Мостафа Сүтүшев исемле адәм дамелланы һәрвакыт ихтирам кылыр вә өенә чакырыб, әңгәмәләр кылыб, төрле бабдан сүзләр сөйләтеб вә китаблар укытыб утырыр улмышдыр. Дамелла даләләте илә мәзкүр Хәмзә бай хаҗ сәфәрендән «Тәфсир кәшаф», «Бохари шәрехе Касталәни» кеби файдалы әсәрләр алыб кайтмыш исә дә, мәзкүр әсәрләрнең дәрәҗәләрене Габделхәбирдән башкалар белмәгән вә мөталагә идеб дә шөгыльләнмәгәннәр. Дамелла Габделхәбирнең үз каләме илә язылмыш нөсхәләр бу көндә һәм күб, фәкыйрь китабханәсендә дә егерме-утыз данә рисалә вә китаблары вар. Дамелла Габделхәбирнең сыйфат хакында улан бер мәкаләсенә (шимди бу мәкалә «әл-Хикмәтел бәлигател җинния» ахырында мәтбугъдер) мөнакыйшә идеб[5], 1273 һиҗридә казанлы Гаяс мәхдүм тарафындан язылмыш бер мәктүб ошбу җөмләдәдер.

Дамелла Габделхәбир китаблары арасында Мәрҗани каләме

---

[1] Хәфиде – оныгы.

[2] Аллаһы әгъләм – Аллаһы белсен.

[3] Заегъ – югалган.

[4] Әһалисе – кешеләре.

[5] Мөнакыйшә идеб – бәхәс корып.

илә язылмыш шәйләр күб, «Назурә...» тәкъризлары[1] да вар.

Габделхәбир вафатына унбиш-егерме еллар үтде исә дә, аның хакында: «Галим вә фазыйл адәм иде» дия сөйләүче безнең Питрапаул шәһәрендә күрелмәде вә ишеделмәде. 1902 милядидә бер адәм: «Бән дамелла Габделхәбирдән укыдым» дия сөйләдекендә: «Укыган булсаң, остазыңа бер хәерле эш кылган булырсың» дия, каберенә таш яздырыб куярга даләләт кылдым, мәзкүр адәм шуны кабул идеб, таш яздырыб куйды. Фәкыйрь иншасы илә язылмыш язуның сурәте будыр: «Һәза мәшһад гыйззәтел фазыл вәл әдәб вә зөһрәтел камил вә гайятел адәб, сәййидел китабел әкарим би-һөҗҗәт уләл әлбаб хилйател фәзаил фаикел әвахир вәл әваил хамилел гыйлмел кәсир сахибел фазлеш шәһир әш-шәйхел гарифел галләмәт Габделхәбир бине Габдеваһһаб әл-Мөслими әл-мөгътәсыйм би-хәблилләһел мәтинел мөтәассәсел бинйан галә тәкъва мин Аллаһ вә ризван җәгалә Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгалә кабруһу раузатан мин рийазел җәнна вә әхла мәхәллел коддус. Тәвәффа гам ситт вә тисгыйн вә миатайн вә алф мин гомри җаузел хамсин»[2].

Вә агасы Габделфәттах каләме илә язылмыш әсәрләрдән бездә байтак китаб вә рисаләләр вар, ләкин сез сорамыш Мәрҗани мәктүбләре юк. Аллаһы биһа галим, анлар табылырмы икән? Мәга ма фиһи[3], безләр һәнүз[4] сорашыб вә эзләб йөримез. Бездә бер «Гамдәт тәдфикат» вар. Мөәллиф[5] Шаһиәхмәд бине Рафикъ әс-Сәмәкинең үз каләме дәгелме икән? Тәмам улмыш тарихы

---

[1] Тәкъриз – 1) язылган әсәр һәм хезмәткә мактап бәя бирү; 2) китап азагында библиография.

[2] «Габделхәбир бине Габделваһһаб әл-Мөслими – белемле, дәрәҗәле, фазыйләте һәм әдәбе камил дәрәҗәдә булган заттыр; күпсанлы китаплар язган галим кеше, белем ияседер. Шулай ук шәехләр арасында бөек дәрәҗәле шәех, остаздыр, әл-мөгътәсыйм би-хәблилләһел (ягъни Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә таянган. Бу эпитет бөек дәрәҗәле суфи шәехләргә карата әйтелгән – *А.Х.*). Аллаһы Тәгалә аның каберен җәннәттәге якты, нурлы бакча итсен иде, үзен мөкаддәс урын иясе итсен иде. Ул [Габделхәбир бине Габделваһһаб әл-Мөслими] 1296 (милади буенча 1879 нчы ел – А.Х.) сәнәдә 50 яшендә үлгән».

[3] Мәга ма фиһи – шуның белән.

[4] Һәнүз – гел.

[5] Мөәллиф – автор.

1236 һиҗридер. Баш тарафында ингыйкясел мөрәккибат (?) хакында бер тәхрир улыб, ахырында «Шаһиәхмәд әс-Сәмәки» дия язылмыш вә аерымрак бер урында да: «Фәләгаллә һәза мин хавасина лианни ләм әҗид фи көтөби әсхабәна лиһәза дәлилән» дия языб куймышдыр»[1].

«Әл-маэез зәлял фи хашиятел җәлял»[2]нең баш ягына Мәрҗани хәзрәтләре үз каләме илә:

يا صديقا افادنيه زمان له ضن بالاصدقاء كبير
بين شخص و بين شخصك بعد غير ان الوصل في الخيال سمير
و انما اوجب التباعد بيننا اني شهاب و انت خبير[3]

дия язмышдыр.

*Хәсән бине мулла Әхмәд әл-Кызылҗари Пономарев,*

*27 июнь 1912 сәнә*

---

Питрапаул шәһәрендә Мәрҗани мәктүбләре табылмакындан һәмишә мәэюс дәгелмез[4]. Барысы улмаса да, инша Алла бәгъзесе мәйданга чыкар. Питрапаул хәзрәтләре үзләренең китабханәләрендә улан китабларның тузанларыны берәр берәр мәртәбә сөртеб чыксалар, шәб эш булыр, бәлки шул вакытда Мәрҗани мәктүбләре, хәтта Курсави рәсми хатлары да табылыр иде. Шаһиәхмәд әс-Сәмәкинең бездә бер-ике мәктүбе вар иде. Тентү вакытында кулымыздан алындылар. Бер кемсәдә бер рапорты варлыгы мәгълүм, шуны сораб алыб, сезгә йибәререм, чагышдырыб карадыгыз соңында «Гамдәтет тәдкыйкат»нең үз каләме улыб-улмадыгы белерсез. Бу дәфга[5] Мәрҗани мәк-

---

[1] «Бу безнең үзенчәлектер, чөнки мин бу дәлилләрне яклаучы кешеләрне китапларда тапмадым».

[2] «Бөек хашияләрдә чишмә суы».

[3] Хатның кыскача тәрҗемәсе: «И дустым! Безнең арада аерылышу. Син дуслык хисләренә саранлык күрсәттең. Мин исә хыялымда синең белән очрашырга омтылам! Мин – Шиһаб, ә син – Хәбир».

[4] Мәэюс дәгелмез – өметебезне өзмибез.

[5] Бу дәфга – бу юлы.

түбләре хакында сөенечле бер хәбәр язмадыңыз исә дә, яздыкларыңыз безем өчен һәмишә файдалыдыр. Без бу мәктүбне «Асар»да Габделхәбир тәрҗемәсенә нәкыль[1] кылачакмыз. Бондый хәбәрләр табылса, язуыңыз мәтлуб[2]. «Һәл мин мәзид?»[3]

*Ризаэддин бине Фәхреддин,*
*12 июль 1912 сәнә. Оренбург*

*Мәкалә тарихчы, тюрколог Ризаэддин Фәхреддин (1859–1936) тарафыннан язылып, 1912 елны «Шура» журналының 14 нче санында дөнья күрә.*

*Текстларны басма өчен Алсу Хасавнех әзерләде*

## Дамелла Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең намын таәбәд итү[4] хакында

Шул исем берлә 798 нче нумер «Йолдыз» гәзитәсендә бер мәкаләчек күрелде. Галиәсгар Камал әфәнде бу мәкаләдә «Шиһаб хәзрәтнең намын[5] таәбәд итү мәсьәләсен Казан башларындан берничә кеше мәйданга куйганлар иде. Ләкин анлар Мәрҗани җәнабләренең вафат тарихы тугрысында бераз йаңлышканлар икән» дигәннең соңында «Йолдыз» идарәсенең дә бу көнгә иштирәк итәргә[6] теләгәнлегендән, «шул хакда мәгълүмат алыр өчен, мулла Борһанеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренә мөрәҗәгать кылган идек һәм бу тугрыда берникадәр истифсар[7] да кылган идек. Кайсы көнне вафат булганлыгын ул безгә хәбәр итәргә вәгъдә кылды» диеб, «Йолдыз» укучыларына гүя Борһан хәзрәтнең вәгъдәсе берлә бәшарәт[8] бирә вә Казан яшьләренә дә зур бер хаталарын тәнбиһ кыладыр.

[1] Нәкыль – күчерү.

[2] Мәтлуб – сорала.

[3] «Тагын ни кирәк?», «Тагын ни сорала?» мәгънәсендә.

[4] Таәбәд итү – мәңгеләштерү.

[5] Намын – исемен.

[6] Иштирәк итәргә – катнашырга.

[7] Истифсар – тулы аңлатуны сорау.

[8] Бәшарәт – шатлыклы хәбәр.

Әлбәттә, Борһан хәзрәтдән Шиһаб әл-Мәрҗанинең кайчан вафат булганлыгындан хәбәр бирергә вәгъдә алу зур бер һиммәт[1] вә милләт өчен дә зур бер хезмәтдер һәм буны гәзитәдә хосусый мәкалә языб, милләткә әгълам[2] кылырга тиешдер. Шуның өчен дә Галиәсгар әфәнде мәкаләсендә Борһан хәзрәтнең вәгъдә кылганлыгын бер ике кат тәэкид кыладыр[3]. Милләт юлында хезмәт яшерен калырга тиеш түгелдер. Бусы өчен Галиәсгар әфәндегә «әфарин» вә «Борһан хәзрәтнең вәгъдәсен тизлекдә вөҗүдгә чыгарырга һиммәтеңезне кызганмаңыз!» диюдән башка сүз юкдыр. Фәкать «Казан яшьләре Мәрҗани җәнабләренең вафат тарихы тугрысында бераз йаңлышканлар икән» дигән хакиманә мәслихәт вә тәнбиһләренә каршы берәр сүз әйтергә үземне борчулы диб беләмен.

Үткән көн Казанның могтәбәр голәмасындан вә яшьләрендән берничә адәм Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең хезмәте диния вә миллиясене вә тәрҗемәи халене тәхкыйк[4] вә тәдкыйк[5] һәм дини вә милли әдәбиятымызда күрсәткән хезмәт вә, тоткан урыныны тәгайен итүнең күбдән тиешлеге хакында мөзакәрә кылыб, бу хакда садад[6] вә хезмәтенә дә керешкәнләр иде. Бу адәмләр бу ел кыш буена күб хезмәт итделәр вә шул юлда байтак мәгълүмат да җыйды вә хазирләделәр. Җыелган вә тәдкыйкать вакыты берлә гаммәнең моталәгасенә тәкъдим итәчәкдер. Затән[7], бунның кеби фәнни тәдкыйк вә тәхкыйкать өчен әһли булган адәмләрнең зур хезмәт вә иҗтиһад итүләре лязимдер, моның өчен байтак айлар, хәтта еллар сарыф ителергә тиешдер. Мәзкүр голяма вә яшьләрдә эшнең бу ноктасын яхшы аңлыйлар, шуның өчен алар «таәбәд итү» көнен бу ел йә фәлән вакыт ясыйк, диб берәүгә дә һәм бер йирдә дә игълан кылган-

---

[1] Һиммәт – тырышлык.

[2] Әгълам – галәм.

[3] Тәэкид кыладыр – кабатлыйдыр.

[4] Тәхкыйк – хакыйкатькә чыгару.

[5] Тәдкыйк – дикъкатьләп тикшерү.

[6] Садад – бәйләнешле.

[7] Затән – нигездә.

лары юк. Зиммәләренә[1] алган хидмәтләре тәмам булгач, әдәбият базарына куярлар. Әлбәттә, моның кеби хидмәте фәния вә гыйльмиянең мәүзугысы[2] булган шәхеснең (Мәрҗани хәзрәтнең) вафатына йегерме биш йыл, йахуд туганына йөз йыл кеби бер тарихи көненә тугры китереб чыгару муафикърак булачакдыр. Шуның өчен дә Галиәсгар әфәнде берлә безнең кеби адәмләргә Мәрҗанинең вафаты вә вилядәте тарихы хакында Борһан хәзрәт кебиләргә мөрәҗәгать иткәләргә вә мөрәҗәгать иткәнлегемезне дә гәзитәләрдә игълан кылыб торгаларга тиешдер. Шулай мөрәҗәгать иткәли торгач, шаяд, берәрсе килеб итмәсме. Голяма вә яшьләр тәхкыйк, тәдкыйк, вә тәрҗемәи халь язсалар, бергә шулай көнләр вә еллар тикшерә торырга кирәк. Милләт эше гомуми булырга тиеш. Юкса бер кешегә генә авырга килә ул.

*Хаҗизадә*

Борһанеддин хәзрәтнең идарәмезгә хәбәр бирүенә караганда, дамулла Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре 1889 ел 15 апрельдә вафат итмешдер.

Идарә.

*Мәкалә Хаҗизадә тарафыннан язылып, 1912 елны «Йолдыз» газетасының 806 нчы санында дөнья күрә.*

*Текстны басма өчен Венер Усманов әзерләде*

## Шиһаб хәзрәт Мәрҗани җәнабләренең юбилейсы мәсьәләсенә даир

Мәүлиде шәриф бәйрәме мөнәсәбәтилә булган бер мәҗлесдә берничә әфәнделәр мәрхүм Шиһаб хәзрәтнең юбилейсына иштирәк[3] кыяфәтендә берничә фикерләр күргәзделәр.

---

[1] Зиммәләренә – өсләренә, йөкләмә итеп.

[2] Мәүзугысы – темасы, проблемасы.

[3] Иштирәк – катнашу.

Рухын ихтирам вә намын таәбәд[1] өчен:

1) Хаҗитархан мәктәбләрендән бер мәктәбене зур итеп, программасын тәүсигъ итеп[2], шул мәктәбне Шиһаб хәзрәт исеме илә атау кирәк диделәр;

2) Шиһаб хәзрәт исеменә Хаҗитарханда зур бер кыйраәтханә ачу кирәк диделәр;

3) шәһәрнең хөкүмәт урта мәктәбләренең берсендән бер мөселман баласы өчен урын алу, ягъни гимназияме, реальныймы вә яхуд тиҗарәт вә һөнәр мәктәбеме, кайсындан булса да берсендән бер мөселман баласын Шиһаб хәзрәт намына тәрбия кылып укыту кирәк, ул тәмам итеп чыккач, икенче баланы биреп, шулай дәвам итү кирәк, – диделәр;

4) ошбу фикерләрне Хаҗитархан мөхтәрәм мөселманларына да гарыз итеп[3], үзләренең дә фикерләрене сорыймыз; тагы да мөмкин булгандай гүзәлрәк фикерләр булса, идарәмезгә язып йибәрсәләр, яхшы булыр иде.

*Мәкалә «Идел» газетасының 1912 елның 21 февралендә (429 нчы сан) имзасыз басылган.*

*Текстны басма өчен Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Мәрҗани хәзрәтләренең юбилеена даир. Красноярдан

«Идел» гәзитәсенең 229 номерәсендә Әстерханда мәүледеннәби мәҗлесенә җыелган әһле гыйрфан арасында мәрхүм җәннәте-мәкян[4] Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең юбилеесенә иштирәк хакында тәгате әфкяр[5] улдыгын, мәрхүм мөшар иләйһи[6] хәзрәтнең рухын ихтирам вә намен таәбәд ичүн, хәзер бил-мәҗлес уланлар микъдар тәбгыләренчә фикерләрен

---

[1] Таәбәд – мәңгеләштерү.

[2] Тәүсигъ итеп – киңәйтеп.

[3] Гарыз итеп – җиткереп.

[4] Җәннәте-мәкян – урыны җәннәттә булган.

[5] Тәгате әфкяр – фикер алышу.

[6] Мөшар иләйһи – югарыда күрсәтелгән.

хәвалә кылдыгын[1] һәм мондан соңгы фикерләргә дә «Идел» сәхифәләре ачык, бәлки «Идел» мөтәмәнни[2] идекен укыдыгымла, Краснояр әһалисенең дә бу эшкә ничек карауларын белмәк ичүн, аларны күреп, фикерләрен сорадыгымда хәвалә иделгән фикерләр күп булса да, татвил мәкаләдән ихтираза[3], ахыргы карар берлән кифаяләндем. У карарда мөзакәрә әснасендә[4] әһалимезнең игътибарлыларындан әл-Хаҗ әл-Хәрамәйн Галәветдин әфәнде: «Мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләренең тәнвире әфкяр[5] вә тәүсигы фөнүн[6] ичүн беренче сәбәб улдыгын, ничә гасырлар мөнкарыйз хисаб иделән мәсдүд торан[7] иҗтиһадының ишекен әүвәл ачдыгын, бу фазылның юбилеесенә дә фазланә[8] эшләр тиешлеген сөйләдекдән соңра, хәзердә гыйльме исламда милләтемездә, милли лисанымызда гасырымызга муафикъ мәдәният хазирәгә мотабикъ[9] гыйльме тыйбда, ягъни химический әҗзаләр[10] буенча дәва тәркиб идәргә дәстүр әл-гамәл тотарлык[11] бер китаб булмадыгын, госманлы, иранлы вә гайреләр дә бондан мәхрүм булдыгын, кулымызда булганларның биш-алты гасырдан да әүвәлге китаплар идекен, бу иске таш китаблар берлән милләтемез арасында тыйбабәт[12] рәваҗ таба алмадыгын, госман вә гайре мәдәни ислам мөселманларымызың латин, француз китабларын дәстүр әл-гамәл тотдыкларын, бу исә безең кауме нәҗиб милләте ислам намына зур намус идекен, Аурупа мәдәниятенең, бигрәк дә гыйльме тыйб, гыйльме табигать саясендә күтәрелдеген бу тыйб-тыйбабәт саясендә аурупалылар-

[1] Хәвалә кылдыгын – тапшыруны.

[2] Мөтәмәнни – теләүче.

[3] Ихтираза – *монда*: качып.

[4] Әснасендә – вакытында.

[5] Тәнвире әфкяр – фикерләрне нурландыру.

[6] Тәүсигы фөнүн – фәндә тарату, киңәйтү.

[7] Мәсдүд торан – чикләнгән.

[8] Фазланә – лаеклы.

[9] Мотабикъ – туры килгән.

[10] Әҗзаләр – медикаментлар.

[11] Дәстүр әл-гамәл тотарлык – практик кулланма булырлык.

[12] Тыйбабәт – табиблык.

ның зур дәүләт улдыкларын безең әһалимез бу эшкә әһәмият вирсә, гасырымызга муафикъ әсәрләр булдырса, шөбһәсез, зур рәваҗ[1] табачагын, бу эшнең инсаниятемез, мәдәниятемезгә беренче сәбәп улачагын күрсәтәрәк мәрхүм җәннәте-мәкям хәзрәтләренең рухын ихтирам вә нам шәрифләрен[2] таәбәд илә ахырзаман ичүн, Аурупаның иң соң системда булган (фармакопея)сен[3] иң хәзакатьле[4], иң фәсахәтле, иң мәгълүматлы доктор профессордан төрки лисанымыза тәрҗемә кылдыртып, (Шиһаб әт-тыйб) тәсмия кыйлмакыны[5], тәрҗемә кылынган соңында күбрәк басдырып, һәр җәмгыятьләр файдасына вәкыф кыйлмакыны мәгъкуль күрдеген хәвалә соңында хазыйр бил-мәҗлес улан әһали мөттәфикъ әл-раи[6] кабул вә саваб күреп, һәркайусы кадыйр-әлхаль[7] мадди ярдәм дә булырга карар вә вәгъдә вирделәр, бу эшне дә кәгазь өстендә калдырмас ичүн, тиздән бер комиссия сайлауны вә комиссия рәисенә дә «Идел» нашире Г. Гомәрев әфәндене мәгъкуль күрделәр.

Гаунет-тәрәкъкый[8] җәмгыятенең рәисе Фаяз Фәрзан. «Идел»: Краснояр җәмәгатенең юбилее хакында фикерләре будыр.

Әфкяре гаммә[9] үзе эстәдекчә назыйр идәр.

Фәкать бән юкарыда мәзкүр комиссиядә риясәт[10] вазыйфасыны буеныма ала алмаячагыны белдереп, Краснояр җәмәгатенә күстәрдекләре илтифатлары ичүн тәшәккер илә игътизарымы[11] бәян итдем.

*Г. Гомәров*

---

[1] Рәваҗ – таралу.

[2] Нам шәрифләрен – кадерле исемнәрен.

[3] Фармакопеясен – дарулар ясау, җитештерү сыйфатын тикшерү рәсми документлар җыентыгы.

[4] Хәзакатьле – оста.

[5] Тәсмия кыйлмакыны – исемләүне.

[6] Мөттәфикъ әл-раи – гомум фикер [итеп].

[7] Кадыйр-әлхаль – хәленнән килгәнчә.

[8] Гаунет-тәрәкъкый – тәрәккыяткә ярдәм.

[9] Әфкяре гаммә – күпчелекнең фикере, карашы.

[10] Риясәт – рәислек итү.

[11] Игътизарымы – гозеремне.

*Мәкалә дин әһеле, галим, мәгърифәтче, нашир һәм журналист Г. Гомәри (1867–1933) тарафыннан язылып, «Идел» газетасының 1912 елгы 2 март санында (№ 434) басылып чыга.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

## Мәрҗани хәзрәтләренең юбилеена даир

Могтәбәр «Идел» газетасының 432 нче номерында, Красный Ярдан, Мәрҗани хәзрәтләренең юбилеена даир, Фаяз Фәрзанов тарафындан бер мәкалә дәрҗ иделмеш[1] иде. Бу мәкаләне язучы гомум Красный Яр әһалисенең фикере дип аңлатканга, түбәндәге сүзләрне язарга карар бирдек. Мәзкүр мәкаләдә бәян улдыгына күрә, шул юбилей хакында бер мәҗлес булып, анда Галәэддин әфәнденең гарыз идүе[2] буенча бөтен мәҗлес тарафындан билиттифак[3] кабул иделеп, шуңар карар бирелмеш: мәрхүмнең исемене мәңгелек онытмас ичүн, Йаурупаның иң соңгы системдагы бер фармакопеясыны бер доктор профессор тарафындан татарчага тәрҗемә иделеп, һәр җәмгыятькә берәр нөсхәсене вәкыф итмәк! Менә мәрхүмгә ядкәр! Без, Красный Яр мөселманлары, бу мәҗлесдән хәбәремез булмадыкы кеби, бондагы фикергә дә кушыла алмыйбыз. Без мөхтәрәм татар милләтенә беренче мәртәбә рух өрүче, тарихымызи ислях идүче[4], вә динемезгә, дөньямызга тәгаллекълы[5] күп нәрсәләрнең лөзүмене кәшеф идеп[6] бирүче Мәрҗани хәзрәтләрене тәгъзыйм идәмез[7], аның юбилеена да кушылырга җан вә тән берлә ашкынып торамыз, ул мөхәрриремезнең исемене мәңгелек онытдырмаслык бер ядкяр дә кирәк димез, әмма 4–5 ел саен алмашына торган ысвижий[8] гомере фәкать 4–5 ел гына булган фармакопея бул-

[1] Дәрҗ иделмеш – кертелгән.
[2] Гарыз идүе – тәкъдим итүе.
[3] Билиттифак – беравыздан.
[4] Тарихымызи ислях идүче – тарихыбызны яңартучы.
[5] Тәгаллекълы – бәйләнешле.
[6] Лөзүмене кәшеф идеп – кирәклеген ачып.
[7] Тәгъзыйм идәмез – зурлыйбыз.
[8] Ысвижий (свежий) – яраклы.

мас! Мөхәрриремез исеменә милләт тарафындан кылына торган ядкәр гомумга файдалы вә әһемләрдән[1] дә әһемрәк булыр, безнең халык шушы якын арада гына табибларга аралаша башладыклары мәгълүмемездер. Белер-белмәс татар табибчыларына (мөтәтаббибларга[2]) татарча фармакопея тотдырсак, бу безнең табиблардан бырагаюмызга сәбәб булачак, бу исә мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләренең теләгенә билкөлли хилафдыр[3].

Без, Красный Яр мөселманлары, гаҗиз фикеремезгә күрә, мәрхүмнең рухыны шадландыру ичүн, иң олуг ядкяр – халкымыз арасында гыйлем вә мәгърифәт тарату, аның исеменә мәктәбләр, мәдрәсәләр вә китапханә вә кыйраәтханәләр ачмак, яхуд мәрхүмнең ничә сәнәләр күз нурын түгеп, иҗтиһад[4] вә гайрәт сарыф идеп тәэлиф итдеке[5] олуг тарихи «Вафиятел әслаф...»не басдырып таратмакдыр. Уемызча, бу соңгысы олуг галимемезне артыграк шадландырса кирәк. Менә безнең фикеремез шулдыр.

Милләт хәрәкәт иткәндә, безләр хәлемездән килгән кадәр хәрәкәт итсәк кирәк.

Бу мәкалә Красный Яр әһалисенең үтенүе буенча язылды.

*Ф. Госманов*

*Мәкалә «Идел газетасының 1912 елгы 9 март (№ 434) санында басылган.*

*Текстны басма өчен Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Шиһабеддин әл-Мәрҗани

Бу бөек галимемез Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вафатына бүген 25 ел тула. Ошбу мөнәсәбәт илә аны яд итү[6] хакында берничә сүз әйтүне тиеш-

[1] Әһемләрдән – иң мөһимләрдән.
[2] Мөтәтаббибларга – ялган табибларга.
[3] Билкөлли хилафдыр – тулысы белән каршы килә.
[4] Иҗтиһад – тырышлык.
[5] Тәэлиф итдеке – җыйнавы.
[6] Яд итү – искә алу.

ле табдык. Бу якда үзенең зур кәшфият[1], ихтираг[2] вә иҗадлары, гаҗиб[3] нәтиҗә вә сәмәрәләре[4] илә гакыллыларны хәйран калдырырлык гареб мәдәниятенә һич илтифат итмичә, мөселманлар бар кәмалятне үз араларындан – мөселман шәркындән эзлиләр, тия (дөя) даласында адашыб – зар сәргәрдан (аптыраган) булыб йөргән бәни Исраил кеби, шул, гыйлем чишмәләре кибкән, мәдәният бакчалары корган, тәрәкъкый хәрәкәтләре туктаган «дияре исламия»нең бер башындан икенче башына гыйлем вә кәмаләт артындан чабалар иде. Вакыйган, ислам илләренең күбесендә искедә дарелголум вә әл-тәдрис булган зур-зур җамигълар, мөкәммәл мәдрәсәләр бар иде. Ләкин инде боларның эчендә гаять низамсыз, мәкъсадсыз вә файдасыз нәрсәләр тәгълим ителә вә талибел-галимләр шул нәрсәләр белән миләрен исертеб, чын гыйлем белән коралланган кеше кебек мәгърур булыб йөриләр иде. Вакыйган, соң гасырларда мөселман мәдрәсәләренә истиля иткән[5] схоластика сөреме ничә-ничә мең фәрдләрнең бергенә түгел, берничә мөселман кадимләренең әварә (йорт-җиреннән аерылып, читтә сугылып йөрүче) булыб ятуларына сәбәб булды, дисәк, артык мөбаләгә иткән[6] булмамыз.

Бервакытлар безнең татарлар тәхсиле голүм вә кәмалят нияте белән Бохарага йөрделәр. Ләкин бу чакда Бохарада чын голүм урынына әллә нинди дибаҗә тәдкыйклары[7], шәрех вә хашия тәхкыйклары вә гомер ашаучы схоластика тәгълим ителә иде. Ул вакытларда «гыйлем бишеге» диб аталган «Бохараи шәриф»дә нә голүме гарәбия вә диния, нә дә голүме гаклия вә фәлсәфия асла[8] адәм рәтле укылмый иде. Мәга мә фиһ[9] безнең

[1] Кәшфият – яңа барлыкка китерелгән гыйльми яңалыклар.

[2] Ихтираг – уйлап чыгару.

[3] Гаҗиб – искитәрлек.

[4] Сәмәрә – җимеш.

[5] Истиля иткән – җәелгән.

[6] Мөбаләгә иткән – арттырган.

[7] Дибаҗә тәдкыйклары – аңлатмалар.

[8] Асла – һич.

[9] Мәга мә фиһ – шуның белән бергә.

Идел вә Урал буе мөселманларының гыйлем таләбләре, дөбә[1] кәрванлары белән ничә мең чакрым ком далаларын кичеб, гәрвә-гәрвә Бохара тарафларына сәфәр кылалар иде. Безнең вакыт илә иң киң шөһрәт алган мәдрәсәләремезнең мәдрәсәләре Бохарадан укыб кайткан яки Бохарада укыган кешенең хилкаи тәдрисендә истифадә иткән[2] затлар була иде. Безнең Бохарада тәхсил иткән затларымызның андан нинди багаж илә кайтканлыклары Бохара мәдрәсәләре хакында югарыда әйтелгән сүзләрдән бик ачык мәгълүм: бу затлар безнең мәдрәсәләремезгә дә Бохарадан алган «гыйлемләр»ен китереб аудардылар. Бездә дә дибаҗә, хашия, шәрех вә мөнһүәт (?) тәдкыйк ителде[3]. Бездә дә моназарә[4], горур вә дәгъва... базары кызды. Мин бервакыт Мисырда чыга торган «Әл-Мөәййид»[5] гәзитәсендә яздыгым мәкаләдә: «Бохарада укыб кайткан татар голямасы бездә исламиятнең саклануына, безнең аерым бер милләт булыб торуымызга – ассимиляциядән котылуымызга хидмәт итделәр», – диб язган идем. Әхвале тарихиямызны дәхи дә яхшырак белүче Ризаэддин хәзрәт «Шура»да минем ошбу мөляхәзәмне рәд итеп[6], тегеләрнең ул хидмәтләрен дә сәлеб итде[7] вә: «Татарларда ислам диненең сакланыб, аларның йотылудан котылуларына Бохарадан кайткан кешеләр түгел, Русия дәүләтенең сәясәтсезлеге сәбәб булды», – диде. Бу хальдә ул затларның татар милләтенә китергән вөҗүде[8] файдалары нидән генә гыйбарәт була соң инде?

Буны казыб чыгаруны мөәррихләремезгә[9] калдырыб, мин үз тарафымдан шуны гына әйтәмен ки: «Бохаралылар аркасында мәсҗед вә мәдрәсәләр күбәеб, дин өйрәтү бездә яхшы ук көчәйсә дә, алар бездә гомуми хәрәкәте фикерия кузгатуга, халыкка аң

[1] Дөбә – дөя.
[2] Истифадә иткән – файдаланган.
[3] Тәдкыйк ителде – игътибарга алынды.
[4] Моназарә – сүз көрәштерү, бәхәсләшү.
[5] Әл-Мөәййид – куәт бирүче.
[6] Мөляхәзәмне рәд итеп – фикер йөртүемә каршы килеп.
[7] Сәлеб итде – инкяр итте.
[8] Вөҗүде – бар булу.
[9] Мөәррихләремез – тарихчы.

вә милли тойгы кертүгә, иҗтимагый инкыйлаб[1] вә исляхлар[2] ясалуга тел вә әдәбиятымызның эшләнү вә төзәлүенә катгыя хидмәт итмәдекләре хальдә, рус мәктәбләрендән, Яурупа мәдәниятендән йырак торуымызга – гаребдәге хәрәкәте фикерия вә мәдәниядән хәбәрсез калуымызга күб хидмәт итделәр.

Дини инкыйлаб вә исляхлар иҗтимагый инкыйлабларга, мәдәни хәрәкәтләргә сәбәб булганлыгы тарихдан мәгълүм. Муса әфәнде Бигиев ислам дөньясында Лютер булмаган, исламияткә «Лютер» кирәкми диб дәгъва итсә дә, без генә Лютерне яд итми китә алмыймыз. Лютер вә Кальвинләрнең дини исляхатләре – Яурупадагы мәдәни исляхларга гаять зур ярдәмче булганлыгы көн кеби ачык бер хакыйкать. «Исламиятдә «мөҗәддидләр[3] булып торыр» дигән сүз бик мәгъруф[4] сүз бит.

Бер буын яд итдекемез Мәрҗани хәзрәтләрендә бер дини мослих[5] вә мөҗәддид күрәмез, ул Бохарада укыса да, анда бәгъзе бер аңлы галимләрнең юл күрсәтүе аркасында, тәхсилдә җөмһүр юлы белән йөрмичә, үз алдына голүме хәкыйкыя эзләү сәдәдендә[6] булган. Бохара мәдрәсәләренә тәнкыйд күзе илә карый алган. Бу мәдрәсәләрдәге бер такым коры вә рухсыз дәрес китаблары белән генә иктифа итмичә[7], ничә гасырлардан бирле китабханәләрдә тузан-тупрак, пәрәвез эчендә кузгатылмыйча яткан надир[8] әсәрләрне тикшереб истифадә иткән[9]. Шунлыкдан ул Бохара мәдрәсәләрен вә анда укучыларны ачы тәнкыйд итә вә алар хакында «сөммә йәрҗәгүн әли бәляд һәм бигмаим кялҗәбаль вә догави васигати кялбәхар» (соңра алар тау кебек биек чалмаларын (урап) диңгез кебек киң таләпләре белән үз шәһәрләренә кайтырлар) диб тәхәккем кылды[10].

---

[1] Инкыйлаб – күтәрелеш.

[2] Исләх – реформа.

[3] Мөҗәддид – яңалык кертүче.

[4] Мәгъруф – танылган.

[5] Мослих – реформатор.

[6] Сәдәдендә – максатында.

[7] Иктифа итмичә – канәгатьләнмичә.

[8] Надир – сирәк.

[9] Истифадә иткән – файдаланган.

[10] Тәхәккем кылды – хөкем сөрде.

Бохара хәдле Бохараны тәнкыйд итәргә батырлык кылган Мәрҗани, безнең бондагы мәдрәсәләр вә мәдрәсәләрне дә тәнкыйд итде, әлбәттә.

Китаб тасниф итү[1] иске заман галимләренә махсус булган диб игътикад ителгән[2] бер заманда Мәрҗани кулына каләм алыб, бөтен ислам галәмен укыту нияте белән гарәбчә китаблар яза башлады, тәкълид вә җәмүд[3] ислам диненә һич дә килешмәгәнлеген исбат итеб мәйданга атылды. Соңра берничә гыйбадәт рәвешләрен, дин исемендән эшләнгән мәгънәсез бидгатьләрне[4] кәмаль җәсарәт илә[5] илә нәзиф итде. Мәрҗанинең бик күб мәсаиле фикъһия вә осулия[6] хакында соңгылар кашында иң шәб авторитет (сокһә)[7] саналган кешеләрнең фикерләрен җәрех итеп[8], үзенең аеруча бер төрле нәзарларын[9] ифадә иткәнлеге[10] дә мәгълүм.

Шул рәвешчә, күб авторитетларны көрсиләрендән төшереб, күб гакыйдә (ышану) вә дини нәзарларны какшатыб, күб бидгать сәйеәләрне[11] сарсылдырыб, Мәрҗани хәзрәтләре бездә фикернең кузгалуына вә тәнкыйд кувәсенең[12] уянуына хезмәт итде. Икенче якдан, ул, тарих вә мазыемызны[13] тикшереб, миллиятемезне билгеләргә вә тарихи бер милләт икәнлегебезне исбат итәргә, милләт гомеренең гаять озын булганлыгын күрсәтеб, гомум милләт мәнфәгате өчен хезмәт кылырга дәрдләрне уятырга тырышды вә үзен үзе танымаган татарларга:

---

[1] Тасниф итү – язу.

[2] Игътикад ителгән – ышанылган.

[3] Җәмүд – сукырларча иярү.

[4] Бидгатьләрне – элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш.

[5] Җәсарәт илә – кыюлык белән.

[6] Мәсаиле фикъһия вә осулия – ислам гыйлеме һәм нигезе мәсьәләләре.

[7] Сокһә – ышанычлы кеше.

[8] Җәрех итеп – ялганга чыгарып.

[9] Нәзарларын – карашларын.

[10] Ифадә иткәнлеге – аңлатканлыгы.

[11] Сәйеәләрне – бозыклыкларны.

[12] Кувәсенең – көченең.

[13] Мазыемызны – үткәнебезне.

«Әй мескин, билфараз,[1] синең мөселмандан гайре бер исемеңне дошман дин вә милләтең белмәсә, әлбәттә, сине мөселман дию тәсмия идәр[2] иде. Татар улмасаң, гарәб, таҗик, ногай вә хытай вә рус вә әфрәнҗ,[3] дәхи дәгел, имде кем булырсың? ... А! Хәмиятьсез,[4] гафил[5]! Ул тәкъдирдә үзеңне чирмеш йә мукшы санаб йөрер идеңме?» – диб кычкырды.

Өченче якдан, Мәрҗани безне рус мәдәнияте илә танышдырырга вә дәүләтнең канун вә сәясәтендән хәбәрдар булыб торырга дәгъвәт итде. Аның төрле вакытда рәсемен алдыруы, рус голямасы илә мөнәсәбәт дә бездә һәр каюсы яңа эш булыб, Яурупалашуга юл ачу диб тәлкыйн ителергә[6] тиешдер.

Мин бу кыска гәзитә мәкаләсендә, әлбәттә, Мәрҗанинең бөек мәгънә вә кыйммәтене күрсәтеб бетерә алмыймын. Тиздән ошбу олугымыз хакында мөкәммәл бер мәҗмуга нәшер ителәчәк. Бу мәҗмугада аның кыйммәте хәкыйкыясе[7] ляикынча танытылса кирәк.

Киләсе елның гыйнварында Мәрҗанинең вәлядәтенә 100 ел тула. Ул чакда бу мәүзугъга[8], гомер вафа итсә[9], дәхи кайтырмыз. Әлегә вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәтилә олуг галим вә остазымызның намын искә төшереб, яшь нәселләремез гыйльми вә мәдәни хедмәтләрдә муаффәкыятькә[10] наил булсын өчен, аның рухындан мәдәд[11] эстимен.

*Г. Баттал*

[1] Билфараз – һичшиксез.

[2] Тәсмия идәр – исем бирер, атар.

[3] Әфрәнҗ – европалы.

[4] Хәмиятьсез – башкаларның зарар китерүеннән саклаусыз.

[5] Гафил – сизми калучы.

[6] Тәлкыйн – аңлату.

[7] Хәкыйкыясе – чын кыйммәте.

[8] Мәүзугъга – темага.

[9] Вафа итсә – мөмкинлек бирсә.

[10] Муаффәкыятькә – уңышка.

[11] Мәдәд – ярдәм.

*Мәкалә Г. Баттал (1880–1969) тарафыннан язылып, 1914 елда «Йолдыз» газетасының 18 апрель санында (117 нче сан) дөнья күрә.*

*Текстны басма өчен Венер Усманов әзерләде*

## Мәрҗани хәзрәтләре кем иде?

Бу көн Мәрҗани хәзрәтләренең дарелбәкага рихләт итүенә егерме биш ел тулды.

Бу көн татарларны тәрәккый, тәгалигә[1] өндәүче заты мөхтәрәмнең видаг итүенә[2] егерме биш ел булды. Мәрҗани хәзрәтләре безнең күземезне ачуда һәм аңымызны артдыруда, фикеремезне кузгатуда зур хезмәт күрсәткән иде. Петр Великий җәнабләренең Русия дәүләтенең тәрәккый итдерүен тасвир урынында Пушкин: «Ул Йаурупага тәрәзә тишде», – дисә, без Мәрҗани хәзрәтләре хакында: «Ул татарлар өстендән миңрәүлек пәрдәсен күтәрде», – диячәкмез.

Без бу урында – Мәрҗани хәзрәтләренең мәдәниятемез тарихындагы әһәмиятен күрсәтү өчен бундан кырык-илле йәки тагын да бераз элекге чакларда үземезнең гыйлем һәм мәдәниятдәге сәйамезне һәм шул чакдагы даирәи фикрийәмезне караб, тикшереб узуны тиешле диб беләмез.

Бунның аркасында безгә Мәрҗани хәзрәтләренең яшәгән вәсатый[3], мохите һәм хезмәт иткән дәресханәсе, аудиториясе мәгълүм булачакдыр. Мәрҗани хәзрәтләренең мәдәният тарихымызда әһәмияте дә күренәчәкдер. Ул чакларда, бундан кырык-илле ел мөкаддәм мәдрәсәләремездә голүме диниягә әһәмият бирелми иде. Фөнүне җәдидә укылу түгел, аның нәрсә икәнлеген дә белүче юк иде. Һәрбер фән лөзүменчә[4], бөтен көенчә укытылмый иде.

---

[1] Тәгалигә – югарыга.

[2] Видаг итүенә – озатуга, саубуллашу, үлеменә.

[3] Вәсатый – уртача.

[4] Лөзүменчә – кирәгенчә

Һәр фәннең мәдхәле[1], кайбер кагыйдәләре генә укытыла иде. Мөкаддимә, дибаҗә уку һәм алардагы кайбер бәхәсләргә тәгаллекъ итү һәрбер шәкерднең гаяи әмәле[2] иде.

Шуның белән бәрабәр, дибаҗә[3] бәхәсләренә оста, үзләренең тәгъбиренчә, аларда үрдәкдәй йөзә алырлык «фазыйльләр»дә дибаҗә гыйбарәсен укый алырлык гарбият булмый иде.

Һәрбер китабның дибаҗә гыйбарәсен укый алырлык гарбият булмый иде.

Һәрбер китабның дибаҗәсендән берничә бәхәсләрне үтеб, Коръән Кәримдән бер ике аять тәфсирен күргән, өч-дүрт хәдис шәриф белгән кеше иң галим, иң фазыл адәмләрдән хисаб ителә иде. Шул дәрәҗәгә йитүне һәрбер шәкерд үзенә гая әмәл итеб тота иде.

Ул «фазыйльләр»нең нә дөньядан, нә дә ахирәтдән хәбәре бар иде. Алар диндән гадәтне, сөннәтдән бидгатьне аера алмыйлар иде. Аларда төбле, әсаслы[4] рәвешдә бер нәрсә дә йук иде. Шуның өчен дә ул чакда шәкердләр, хәлфәләр, муллалар тәмам бушлык, фараз эчендә иделәр. Ул заман гафләт заманы түгел иде; бәлки инхитатка[5], бетүгә, югалуга таба заманы түгел иде; бәлки түбәнгә караб бару заманы иде. Бу заман ифсад[6] заманы түгел иде; бәлки бозылган, ватылган әсаска йаңлыш рәвешдә бина ясауга маташу заманы иде.

Менә шул чакларны искә төшереб, хәзерге чакдагы халемезгә игътибар күзе белән карасак, күңелгә чиксез күб шадлык киләдер. Дөрест, тарихи бер милләт булмаган булсак иде, кырык-илле ел элек булган гафләт, торгынлыкка караганда, хәзерге тәрәккыятемез безне шатландырмас иде. Башда тарихи бер милләт булмаганларга бу дәрәҗәдәге тәрәккыят күб түгел, бәлки бик аз, бик җөзьи[7], аңа шадланырга ярамый; бәлки анең

[1] Мәдхәле – кереше, башлангычы.

[2] Гаяи әмәле – төп теләге.

[3] Дибаҗә – кереш сүз (дини китапларның кереш өлеше).

[4] Әсаслы – нигезле.

[5] Инхитатка – түбән төшү.

[6] Ифсад – җимерү.

[7] Җөзьи – бик аз.

өчен кайгырырга кирәк. Ләкин без тарихый бер милләт булганлыгымыздан хәзерге муаффәкыятемезгә[1] шадланамыз; шадланырга хакымыз да бар, чөнки мәдәният тарихының күрсәтүе һәм катгый дәрәҗәсенә хисаб ителгән бер канун буенча хәрәкәт итмәкдәмез. Башымыздан кичкән хальләрне тикшерә башласак, аларның һәммәсен тарихи каумләрнең һәрберендә күрәмез.

Гыйлеме, фәне, хикмәте, сәясәте, игътикады[2], мәдәнияте, әдәбияты белән бөтен дөньяга диярлек мәшһүр булган Рума, Мисыр, Финикә, Бабил һәм Өммия вә Габбасия дәүләтләренең мөнкариз[3] булулары табигый иделәр; чөнки ул милләтләр барлык көчләрен, куәтләрен сарыф итеб бетергәч, сөкүнәт[4], торгынлык халенә биззарур[5] килергә мәҗбүрләр иде, диләр. Без иҗтимагый бер канун хөкемене алырга якынлашкан бу канунны игътибар итсәк, югарыда әйтелгәнчә, хәзергә тәрәккыятемезгә шадланырга хаклымыз, чөнки элекдә бөтен галәмне дер селкетеб дә, торгынлык дәверенә, тагын андан да түбән төшдекдән соңра, ул дәверне уздыруымыз һәм тәрәккыйгә аяк басуымыз бабаларымызның «ирдән иман котылмый» дигән мәкаленә мисдак[6] була алган кебек, милләтемезнең югалмаячак һәм тәрәккый итәчәген катгый рәвешдә күрсәтәдер.

Тарихи милләт тәдәннигә[7] йөз тотды дию, ул милләт көч-куәт җыю өчен тукталыб тора, истирахәт итә[8] дию беләбездер. Ләкин бунда куркынычлы бер дәвер бар: истирахәткә йөз тоткан тарихи милләт кайчакда башка милләтләр тарафындан йотылыб-югалыб да китәдер.

Без исә, әлхәмдүлилләһ, бу һәлакәт дәверендән котылдык, тәрәккый, мәдәният юлында аяк басдык. Безнең бу кидешемез табигый һәм тәдриҗи[9] иде. Безнең фикеремезчә, тәрәккый

[1] Муаффәкыятемезгә – уңышлы эшләребезгә.

[2] Игътикады – ышанулары.

[3] Мөнкариз – сүнгән, юкка чыккан.

[4] Сөкүнәт – тукталу.

[5] Биззарур – ирексездән, мәҗбүри рәвештә.

[6] Мисдак – бер нәрсәнең дөреслегенә дәлил.

[7] Тәдәннигә – артта калуга.

[8] Истирахәт итә – ял итә.

[9] Тәдриҗи – акрын-акрын алга бару.

мәдәният тарафына йөз тотуымызга Мәрҗани хәзрәтләренең күб хезмәте булмышдыр.

Мәрҗани хәзрәтләре мәсьәләне кирәкле йирендән башлауда, шөбһәсез, исабәт итмешдер[1]. Руслар тәгъбиренчә[2], Мәрҗани хәзрәтләре «үгезне мөгезендән» тотмышдыр.

Без Мәрҗани хәзрәтләренә хидмәтләрендә гаять әһәмиятле, җидди әсаслы[3] ике җәһәтне күрәмез.

Бере Мәрҗани хәзрәтләре, тәрәкъкый, тәгали[4] өчен даирәи фикериянең киңәюе, фикердә коллыкдан котылуның заруры икәнлеген белеб, шул юлда бөтен ижтиһадын сарыф итде дияргә ярыйдыр. Мәрҗани хәзрәтләре заманында һәркемнең авызында «ижтиһад мөнкариз, тәкълид[5] фарыз» дигән сүз тәсби, зикер урынында сөйләнә, күңелләре белән игътикад[6] ителә иде.

«Ижтиһад мөнкариз, тәкълид фарыз» фәлсәфәсәнең шаигъ булуы[7] истикъбалемез[8] өчен гаять хатирле[9] иде.

«Ижтиһад мөнкариз» димәк, үзенчә уйларга, үз теләгәненчә йөрергә, үзенең күңеле карар кылганча игътикад итәргә, кыскасы гына Җәнабе Хак тарафындан бирелгән гакыл нигъмәтендән истифадә[10] хәрам дию белән бердер. «Ижтиһад мөнкариз...» димәк, хәят, ихтыяр, гакыл нигъмәтләрендән мәхрүм итеб, һәркемне бер калыбка кую лязим димәкдер; кеше кешелекдән чыксын да, курчак халендә әверелсен димәкдер.

Менә шундаен фикернең хөкем сөрүе шәхси тормышны бөтенләй бетергән кебек фикерләрне тупасландыруга күб хезмәт итде. Һәлакәт, инкыйразымызда баш сәбәбдә шушы фикер иде.

Мәрҗани хәзрәтләре мәсьәләнең бу җәһәтенә төшенеб, «ижтиһад мөнкариз, тәкълид фарыз» фикеренең хата, төбсез,

[1] Исабәт итмешдер – дөреслеккә ирешә.

[2] Тәгъбиренчә – аңлатуынча.

[3] Әсаслы – нигезле.

[4] Тәгали – үсү.

[5] Тәкълид – башкалар эшләгәнне эшләү, иярү.

[6] Игътикад – ышану.

[7] Шаигъ булуы – һәркемгә билгеле булуы.

[8] Истикъбалемез – киләчәк өчен.

[9] Хатирле – хәтерле.

[10] Истифадә – файдалану.

әсассыз икәнлеген исбат итүгә кыям итде[1]. Иҗтиһад, тәкълид мәсьәләләренә гаид[2] сүзләрне күб әсәрләрендә күрү мөмкин булса да, ул тугрыда «Назурәтел-хак» китабында гаять күб сөйләмешдер. Иҗтиһадының мөнкариз түгеллеген, тәкълиднең ярамаганлыгын бик ачык рәвешдә исбат итмешдер; бу тугрыда бик күб аяте кәримә, әхадисе шәрифәләр, мөҗтәһидләрнең[3] үз сүзләрен нәкыль иткән кебек, мөҗтәһидләрнең үз араларында булган мөгамәләләрен дә нәкыль итмешдер[4].

«Иҗтиһад мөнкариз, тәкълид фарыз» дигән фикернең хаталыгын катгый рәвешдә исбат итмешдер; бу юлда байтак кешеләрне дә икънаг итмешдер[5]. Бу исә – гаять бөек хезмәтдер. Бу һич бер мөбаләгасез,[6] тәрәккъый, мәдәнияткә ишек ачудыр. Икенче төрле әйткәндә, Мәрҗани хәзрәтләре гакыл нигъмәте үзеренә салынган хәбесне[7] күтәрде, аны коллыкдан азад итде, табигать мәктәбендән истифадә итү[8] өчен ирек бирде.

Мәрҗани хәзрәтләренең бу тугрыдагы хезмәте һичбер вакытда искерми, һичбер онытылмаслык һәм мәңге бер хезмәтдер.

Мәрҗани хәзрәтләренең бу юлдагы хезмәте өчен аңа һәр кеше бурычлы. Мәрҗани хәзрәтләренең хезмәтләрендә гаять әһәмиятле икенче җәһәт бундан гыйбарәтдер:

Мәрҗани хәзрәтләре заманында дин белән гадәтне, сөннәт белән бидгатьне, дөрест белән яңлышны, кыеш белән тугрыны аера алмыйлар гына түгел, аларны бутаб, бере урынына ахырыны йөртәләр иде.

Бераз гына мөбаләга белән әйткәндә, Мәрҗани хәзрәтләре һәрбер мәсьәләдә халыкның яңлышканын күрә иде.

[1] Кыям итде – күтәрелде.

[2] Гаид – кайту.

[3] Мөҗтәһидләрнең – тырышлык күрсәтүче.

[4] Нәкыль итмешдер – сөйләгән.

[5] Икънаг итмешдер – канәгатьләндерә.

[6] Мөбаләга – арттыру.

[7] Хәбес – бикләп тоту.

[8] Истифадә итү – файдалану.

Мохитнең гыйбадәтләрендә, гадәтләрендә, әхләфләрендә[1], динләрендә, игътикадларында, фикерләрендә, әмәлләрендә чиксез күб хатаны күрү Мәрҗани хәзрәтләрене җилкендерә, ашкындыра иде; ул һәр нәрсәне ислях итәргә омтыла, фикерләрне уйгатуга тырыша, сөннәтләрне ихьяи итәргә рәгъбәт итә[2] иде: «Хотбәләреңезне яңылыш укыйсыз; хәмәдне тәкрар итмәңез, шәһадәтне җәмгъ сыйгасында укымаңыз, чәһарьярларны берничә хотбәдә зекер итеңез! Җәнабе Хакның сыйфаты хакында «Гыйнел-зат» диб дә, «Гайрел-зат» диб дә бәхәс итмәңез; Җәнабе Хакны тикшерү сезнең эшеңез түгел, гыйбадәтләреңезне шәригатьдә бәян ителгәнчә үтәңез дә гыйбадәтләреңезә бидгать рәвеше бирүдән сакланыңыз», – ди иде; «Җәнабе Хак тарафыннан фарыз кылынган намазларны юньләб укымаганыңыз хәлдә, гыйбадәт диб әллә нәрсәләрне кеше өстенә йөкләмәңез», – ди иде; «Сез татар баласы татар булганлыгыңызны онытмаңыз; телеңезне, гадәтеңезне, хәтта киемеңезне ташламаңыз, хөкүмәтнең телен, язуын, законын белү лязим», – ди иде; «Галим булу өчен күфәле йә басри булу гына лязим түгел, тырышсак, без дә алар чаклы галим була алачыз», – ди иде.

Сүзнең кыскасы гына, Мәрҗани хәзрәтләре һәрбер яңылышны төзәтү, һәрбер хатаны ислях итү, адашканны юлга салу кебек иң агыр, иң зәхмәтле хезмәтләр белән бөтен гомерен үткәрде. Мәрҗани хәзрәтләре, гыйлем тарихны истисна иткәндә[3], аңа чикле голямаи кирам[4] тарафыннан ясалган юлларны әрчү, аларның фикерләрен дәлилләр белән исбат итү белән шөгыльләнде; ләкин шуның белән барәбәр дини мәсьәләләрдә үзенең хосусый фикерен дә сөйли иде. Без Мәрҗани хәзрәтләрене, голямаи кирам тәгъбиренчә, мөҗтәһид дә димимез; мөҗәддид[5] дә димимез, чөнки Мәрҗани хәзрәтләренең гасыры буңа мосагыйд[6] түгел иде.

[1]Әхләфләрендә – калачак яңа буын.

[2] Ихьяи итәргә рәгъбәт итә – тергезергә омтыла.

[3] Истисна иткәндә – исәпләмәгәндә.

[4] Кирам – хөрмәтле.

[5] Мөҗәддид – яңартылган.

[6] Мөсагыйд – ирек бирүче.

Инһидамга[1] йөз тоткан заманда халыкны бетү, югалу һәлякатендән коткаручы яки аны мәдәният, тәрәккый юлына сөрүче кеше, шөбһәсез, Мәрҗани хәзрәтләре иде. Соңыннан киләчәк мөҗтәһид, мөҗәддидләргә юл әрчүче, зәмин[2] хазирләүче зат Мәрҗани хәзрәтләре иде.

Мәрҗани хәзрәтләре милләтемезнең хәл җыю дәверендә иң соңгы гонсыр[3] булган кебек мәдәният, тәрәккыйгә сәвекъ итүчеләрнең[4] иң башы, иң зур «ут агасы»дыр.

Менә шунлыктан Мәрҗани хәзрәтләре – безнең мәдәният тарихымызда үзенә аерым бер дәвер иясе булуга мөстәхикъ[5] затдыр. Мәрҗани хәзрәтләренең тәрҗемә хәле, хезмәтләре хакында юбилей мәҗмугасында мөфассал[6] сурәтдә язылганлыкдан, бу урында шушы кадәр белән генә иктифа итәмез[7].

Мәрҗани хәзрәтләре хакында мөфассал мәгълүмат аласы килгән кешеләр «Мәрҗани» мәҗмугына мөрәҗәгать итсенләр.

*Мәкалә Габдулла Төхфәтулла улы Гыйсмәти (1883–1938) тарафыннан язылып, 1914 елны «Йолдыз» газетасының 117 нче санында дөнья күрә.*

*Текстны басма өчен Венер Усманов әзерләде*

[1] Инһидамга – җимерелүгә.
[2] Зәмин – җирлек.
[3] Гонсыр – яралыш.
[4] Сәвекъ итүчеләрнең – алга этәрүчеләрнең.
[5] Мөстәхикъ – лаеклы.
[6] Мөфассал – тулы, җентекле.
[7] Иктифа итәмез – канәгатьләнәбез.

## Соңгы заман мөселманнары арасында гыйлем таралмау хакында Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең фикере[1]

«Дөньядагы һәрнәрсә өчен берәр манигъ[2] булса, гыйлем вә гыйлемнең таралуы өчен иксез-чиксез манигълар бардыр.

Соңгы заман мөселманнары арасында гыйлем-мәгърифәт таралмау: шәригать хөкеменә, вакыйгъның[3] күрсәтүенә, гакылның әйтүенә хилаф булган[4] урынсыз эшләрнең күңелләрдә оялавы, гадәтләрдә урнашуы сәбәбеннән булуы; алар да түбәндәге нәрсәләрдер.

1) «Иҗтиһад гасыры үтде; бу заманда мөҗтәһид мөнкарыйз[5]; мөстәкыйль дәлил чыгару – әүвәлдәге мөҗтәһидләргә генә хас эш; мөҗтәһидләр дәрәҗәсенә ирешү бу заман кешеләренә мөмкин түгел; һәрбер соң замандагы кеше иске заман кешеләрендән түбән дәрәҗәдә булырга тиешле дигән игътикадның[6] таралуы.

«Борын замандагы тәэлиф сахибләренең[7] һәр сүзе дөрес! Ялган, хата булу ихтималы юк!» фикерендә булынып та, аларга тел тидерү – пәйгамбәрләргә тел тидерү, бәлки артыграк кеби саналдыгы хәлдә, хәзерге заман кешеләренә бонлар кеби китап тәэлиф итү юлы тәмам бикләнеп, тәэлифкә җөрьәт итүче булса, аның китабы хакында: «Батыйль, ялган! Дөрест булу ихтималы юк!» фикерендә булынудыр.

2) Бөтен голүме хөкмия һәм аның җәмигы әрбабына мөхалиф булу[8].

3) Төрлечә фикер йөртергә мөмкин булган кечкенә генә бер нәрсә өчен дә үз фикерләренә мөхалиф булган мөселманнарны «тәкфир» итү[9].

---

[1] «Вафиятел-әсляф» мөкатдимәсеннән алынды.

[2] Манигъ – киртә (тоткарлык).

[3] Вакыйгъның – чынбарлыкның.

[4] Хилаф булган – туры килмәгән, кире булган.

[5] Мөнкарыйз – беткән.

[6] Игътикадның – ышануның.

[7] Тәэлиф сахибләренең – (китап) төзү (язу) белән шөгыльләнүчеләрнең.

[8] Бөтен хикмәт гыйлемнәренә һәм аның барлык әһелләренә каршы килү.

[9] Тәкфир итү – дәһри санау.

Мондан килгән зарарларның җөмләдән берсе: шушы тәкфир сәбәпле, тәфсир «әл-Кәшшаф»[1], «әл-Әнвәр»[2], «әл-Фәссус», «әл-Әшарәт», «әл-Шифа», «әл-Нәҗат» исемле китапларны укудан; Имам Газали[3], Ибн әл-Һәмам[4] кеби зур галимләрнең тәэлифләрен моталәга кыйлудан[5] тыелган вә шул сәбәпле бу китаплар эчендә булган әллә никадәр файда, мәгърифәт вә хакыйкатьдән мөселманларны мәхрүм ителгән.

4) Кыямәт якынлашып, бөтен дөнья, йир йөзендәге һәммә кешеләрнең тиздән һәлак булуын көтү. Һич шөбһә юк, кыямәт булачак. Һәм тиздән булачак.

Ләкин никадәр тиз дип әйтелсә дә, аның ничек вә ничә елдан булачагы – тизлеге, буш хыяллар, ялган вәһемләр[6] уйлаганча булмаенча, Аллаһы Тәгалә теләгән вә кодрәти мөтагалликъ[7] булган, үзенә генә мәгълүм тизлектән гыйбарәтдер. Чөнки Аллаһы Тәгалә бу хакда: «يَسْأَلُونَكَ كَأَنَّكَ حَفِيٌّ عَنْهَا قُلْ إِنَّمَا عِلْمُهَا عِنْدَ رى لا يجليها لو قتها الا هو»[8], – ди.

Кыямәт хакында югарыдагы фикердә булу сиздерми генә нәфеснең алдавындан вә вәсвәсәсендән башка нәрсә түгелдер. Чөнки кешенең нәфесе табган[9] фәзаил[10] һәм аның әһленә рәгъ-

[1] Бу тәфсир (Коръән сүзләренә аңлатма) мәгълүм мөтәзәллит фәлсәфәче Мәхмүд әз-Замахшари (1075–1144) тарафыннан язылган.

[2] Габдулла әл Байдавиның «Әнвар әт-Тәнзил вә Әсрар әт-тәэвил» исеме күз алдында тотыла булса кирәк.

[3] Имам Газали (1058–1111) – ислам дини галиме, философ, суфичылыкны нигезләүчеләрнең берсе.

[4] Ибн әл-Һәмам (728 елда үлгән) беренчеләрдән булып хәдисләр җыентыгын төзегән.

[5] Моталәга кыйлудан – укудан, өйрәнүдән.

[6] Вәһемләр – буш уй, ялгыш.

[7] Кодрәти мөтагалликъ – кодрәтенә бәйле.

[8] «Әграф» сүрәсенең 187 нче аятеннән өлешләп алынган. Ногманинең «Коръән тәфсире»ндә: «Әйт: «Кыямәтнең кайчан булачагын фәкать Аллаһ Үзе генә белә […]. Син кыямәттән хәбәрдар дип, аны синнән күп сорыйлар» дип татарчалаштырылган.

[9] Табган – табигый.

[10] Фәзаил – яхшы.

бәт итмәенчә[1] дөньяга, югары дәрәҗәгә, зур байлыкга кызыга һәм шулардан аерыласы килми. Ләкин тиздән үзенең дөньядан үтүен вә җыйган дөнья вә малларындан аерылып, ул малларның башкалар рәхәте өчен калуын уйлап саранлык күрсәтәсе килә вә кайгыра. Менә шушы кайгылардан үз-үзен юатыр өчен нәфес, кыямәт якын булу, шунлыктан калган маллардан башка кешеләрнең дә файдалана алмау фикерен тудыра ки, бунның нәтиҗәсендә гыйлем тәхсиленднән[2] тукталу вә артка калудан башка нәрсә булмыйдыр.

Кыямәт хакында бу фикердә булган бичараларга, мөселманнарның араларында голүм-мәгариф даирәсе киң, кыймммәте базарлы вакыттагы дин галимләре дә кыямәт якын булганлыгын игътикад кыйлып[3], анда бер дә шик итмәгәнлекләрен, әмма кыямәт якын дип, голүм-мәгариф тәхсилендән туктамаганлыкларын уйлау кирәк иде.

5) Нияте төзек һәм изге булган кешеләрнең изгелек берлә, галим булмаган кешеләрнең гыйлем берлә атак чыгарулары һәм шундый галимләрнең чын галимләргә йөкли алырлык зур эшләрне йөкләүләре.

Менә шундый галимләрнең эш башында булучылыклары гыйлем таралуга каршы иң зур манигъдыр. Чөнки мондый галимләр гыйлемнең даирәсен тарайталар; гыйлем хакында әтрафлы рәвешдә бәхәс итүләрне, юлының киңәюене тыялар.

Аның өстенә, таләбәнең[4] нечкә мәсьәләләргә илтифатын; әрбабе хак[5], әрбабе тәхкыйк китапларында булган дәлилләргә каравын манигъ итеп, үзләре тарафыннан чыгарылган юк-бар ялганнары берлә, әрбабе хак тарафыннан язылган китапларны таләбәгә ким күрсәтеп, алардан нәфрәтләндерәләр вә таләбәнең фикерләрен түбән нәрсәләргә баглап, күзләренә чүп, муенларына богау салалар.

---

[1] Рәгъбәт итмәенчә – *монда*: буйсынмыйча.

[2] Тәхсилендән – эстәүдән.

[3] Булганлыгын игътикад кыйлып – булганлыгына ышанып.

[4] Таләбәнең – гыйлем эстәүченең, укучының.

[5] Әрбабе хак – хаклык әһелләре.

Менә шушы манигълар, шушы богаулар булучылык таләбәне гыйлем-мәгарифдән суындырып, аларның күңелләрен башка нәрсәләргә вә башка юлларга юнәлдерә. Бинаэн галәйһи[1], араларындан һичбер гыйлемсез, төзек ниятсез, сөннәткә иярмәгән, шәригать юлына кермәгән берсе мөридләр тәрбиясе вә иршады[2] өчен «иҗарәтнамә»[3] алдым дип ишанлык дәгъва кыйла. Надан халык исә, мөддагыйның[4] сүзенә колак салып, әтрафына җыела да, мәзкүрнең исеме, халык арасына таралып, көндән-көн мәртәбәсе арта, бөтен кауменә кадере зурая, бөтен фикер, бөтен халык шуңа таба юнәлә.

Әмма хакыйкый галимләр, гыйлемләре шәриф тиешле эшләр берлә мәшгуль булганлыктан, мондый эшләргә тәнәззел итмәгәнлекләрендән[5], адәмләрдән ерагая, базарсызлана ки, бу эш болар өчен иң зур зарбәдер[6].

***

Әмма хасәте Русия мөселманлары[7] арасында гыйлем таралмауга киленсә, түбәндәге нәрсәләрдер: тәхсил вакытында укуга кызыктыра вә сәбәп була торган нәрсәләрнең булмаганы төсле, тәхсилне тәмам иткәч тә максудка ирешүдән өмид киселү.

Чөнки безнең халык арасында әһле гыйлем берлә башкалар арасында аерма булмаганлыкдан, әһле гыйлемнең хәлен төзек кыйлырлык кәфаләтләре[8], эшләрен тәртипкә салырлык фикерләре юк.

Андан соң гыйлем аркасында дөньяңны киңәйтерлек малга, зур-зур дәрәҗәләргә дә ирешелмәенчә, бары имамлык һәм матди җәһәтдән һичбер файдасы булмаган мөдәррислек

[1] Бинаэн галәйһи – шуңа күрә.
[2] Иршады – туры юлга кертү, юл күрсәтеп җибәрү.
[3] Иҗарәтнамә – рөхсәт язуы (диплом).
[4] Мөддагый – дәгъва итүче.
[5] Тәнәззел итмәгәнлекләрендән – түбәнәймәгәнлекләреннән.
[6] Зарбәдер – бәхетсезлектер, удар.
[7] Хасәте Русия мөселманлары – *монда*: Россиядә яшәүче мөселманнар.
[8] Кәфаләтләре – җаваплылыклары.

дәрәҗәләренә генә ирешелә, бу дәрәҗәләргә ирешүдә галәбә[1] мирас тарикынча[2] күчеп килә.

Гыйлем әһелләренең дәрәҗәләре байларга, тәҗарәт[3] ияләренә күрә түбән; йорт-йирләре, җиккән атлары вә мондан башка мәгыйшәт әсбаблары начар булудыр.

Менә әһле гыйлемнең шул хәлләре адәмләрне гыйлемгә кызыгудан тыя вә бик азын гына истисна кыйлынса[4], балаларын гыйлем юлына кертмәенчә, тиҗарәт, кәсеб юлларына кертергә юл ачадыр».

*Гали Хәбибрахман*

*Мәкалә Гали Хәбибрахман тарафыннан язылып, «әд-Дин вәл-Әдәб» журналында 1914 елның 11 нче санында басылып чыккан.*

*Текстны басма өчен Зөфәр Рәмиев әзерләде*

## «Мәшһүр адәмнәр вә олуг затлар» сериясеннән

## Мәрҗани

7 нче фасыл. Иптәшләребез арасында: «Шиһабеддин дамелла үзе шундый һичбер хәтер сакламый торган тугры сүзле кеше булган, әмма аның шәкертләре ни өчен бу дәрәҗәдә койрыксызлар, һәммәсенең эчендә Шиһаб хәзрәт мәсләгене юньләп тәгъкыйб итүче[5] берәүне дә күрә алмыйбыз», – дип сөйләшер идек. Арамыздан беремез: «Шиһаб хәзрәт үзе дә шундый булган, үзе китабында Бохара дәресләрен яманлый, әмма үзе һәмишә дә Бохара тәртибе илә укытып дәвам иткән. Хакыйкый гыйлемнәр дип санаган нәрсәләренең берсен дә шәкертләренә укытмаган. Инде үзе шундый булса, дамелла илә мелла арасында аерма булмаска туры килә», – диде. Чынлап та, бу нинди эш? Бу

[1] Галәбә – өстенлек.

[2] Тарикынча – юлы белән.

[3] Тәҗарәт – сәүдә.

[4] Истисна кылынса – чыгарма ясалса.

[5] Тәгъкыйб итүче – күзәтүче; биредә: «дәвам итүче» мәгънәсендә.

бер хакыйкать! Бу рәвештә сүз сөйли, теге рәвештә эш йөртә. Шиһаб дамелланың шәкертләре – шул ук Кышкар шәкертләре, араларында аерма юк?

Моңа җавап урынында ошбу нәрсә хәтергә килә: «Шиһаб хәзрәт үз вакытында үзенең дошманнарына үз кораллары илә коралланмакны муафыйк күрмеш вә шулар тарызында[1] дәрес укытмыш» бер зат иде. Соңра әстерханлы Габдрахман әфәнде әл-Гомәридән ишетдекемез бер хикәят моны тәәйед кылды[2].

Мәзкүр Габдрахман әфәнде: «Дамелланың бәгъзе шәкертләре бер вакытта үз күңеле риза булган рәвеш илә дәрес укырга сорамышлар, дамелла аларга төрле нәрсәләр, мәсәлән, тарих, җәгърафия, тәфсир, хәдис вә гайре фәннәрдән сабак бирә башламыш... Әмма Казанда мәгъруф[3] булган мантыйк вә кәлям китапларының фәкать мәтеннәрен[4] генә укытыр, шәрех вә хашияләр арага кермәмеш. Шәкертләр бу шәйләрдән ләззәт тапмый, укуны ташламышлар», – диде. Зан итәмез[5] бу хакта «Асар»да мөляхәзә[6] бардыр. Әгәр дә булмаса, моны язарга тиешле.

Шиһаб хәзрәтне русча белмәгән, диләр. Мин дә белгәндер димим. Шиһабеддин хәзрәт үзенең тарихыны төрки, фарсы әсәрләрдән генә җыйган, русчадан алмаган, диләр (хәтта үзенең углы Борһан хәзрәт тә шулай ди).

Ләкин мин русчадан, (хәтта бик әгъла[7] сурәттә сайлый белеп) алган димен. Хаҗиморат әфәнде «Тәлфикыль-әхбар» исемле китабында күп урында Шиһаб хәзрәткә һөҗүм итә, хәтта күп урында: «Бу сүз тарихта юк, бәлки Мәрҗани үзе чыгарган», – дип үк әйтә. Без үз күземез илә күреп беләмез, Мәрҗани Шиһаб хәзрәтнең шул Хаҗиморат тарафыннан рәд ителгән[8] сүзләре рус китапларында вә каигънамә (летопись)ләрдә бар.

[1] Тарызында – үрнәгендә.
[2] Тәәйед кылды – куәтләде, ныгытты.
[3] Мәгъруф – билгеле.
[4] Мәтеннәрен – төп текстларын.
[5] Зан итәмез – уйлыйбыз, уйлавыбызча.
[6] Мөляхәзә – фикер (йөртү).
[7] Әгъла – гүзәл; игътибарлы.
[8] Рәд ителгән – кире кагылган.

Аның тарихында асаре гатика[1] җәмгыятьләре мәҗмугаларыннан хәтта вак тарихи брошюралардан, мәсәлән, Фукс[2] вә Френ[3] кебиләрнең әсәрләреннән сүзләр бар. Дамелланың русча китап укымаганы сабит[4] булса, аның китабы русча укыган морзалардан гына түгел, хакыйкый сурәттә тарихка вә асаре гатикага интисаб иткән[5] голямалардан тугрыдан-тугры файдаланганына шәһадәт бирер.[6] Мәсәлән, Тимер Котлык илә Туктамыш ханнарның ярлыклары иң югары сыйныф голямалар арасында гына йөргән иң надир[7] әсәрләрдер. Туктамыш хан һәм Тимер Котлык ярлыклары мөстәшрикъ[8] Березинның[9] «Ханские ярлыки» дигән әсәрендә дәрҗ ителгән[10] һәм Тимер Котлыкныкы ялгыз хәлендә немецчә «Funduruben dez Orientz» журналының 1818 нче елгы 17 нче җилддә 61–69 нчы битләрендә дәрҗ ителгән.

Мәрҗани русча нинди әсәрләрдән истифадә иткәнлеге[11] хакында профессор Шпилевский[12] үзенең Казанда 1877 елда «Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии» дигән олуг әсәрендә, 139 нчы битендә

---

[1] Асаре гатика – археология.

[2] Карл Федорович Фукс (1776–1846), тарихчы, этнограф, Казан университеты профессоры.

[3] Френ – Христиан Мартин Френ (1782–1851), академик, Казан университеты профессоры, Россиядә Көнчыгыш нумизматикасын беренчеләрдән булып өйрәнүче һәм Казанда гарәп телен өйрәнүнең нигезен салучы галим.

[4] Сабит – ачык билгеле, шиксез.

[5] Интисаб иткән – мөнәсәбәте булган.

[6] Шәһадәт бирер – күрсәтер.

[7] Надир – сирәк очрый торган.

[8] Мөстәшрикъ – шәркыят галиме.

[9] Березин – Березин Илья Николаевич (1818–1896), шәркыятьче галим, тюрколог, Казан университеты профессоры, 1855 елдан Санкт-Петербург университетында эшли. Хезмәтләре Көнчыгыш телләре текстологиясенә, иранлылар, монгол һәм төрки халыклар филологиясе һәм тарихына карый.

[10] Дәрҗ ителгән – урын алган, теркәлгән.

[11] Истифадә иткәнлеге – файдаланганлыгы.

[12] Шпилевский – Шпилевский Сергей Михайлович (1833–1907), Казан университеты профессоры (1870–1889 елларда), 1877 елда чыккан «Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии» исемле китабы «Император Фәннәр академиясе» премиясенә лаек була.

зикер итә[1]. Ничек тә Мәрҗани русча әсәрләрдән файдаланган. Моның өстенә Шиһаб хәзрәт Казан ханнарының тарихын русча чыганаклардан алмый, башка җирдән алып яза да алмаган, чөнки башка мәхазләр[2] тәкърибан юктыр.[3] «Мөстәфадел-әхбар»ның беренче җилдендә «Фасыл фи әд-дәүләтел-мөстәҗәддид би Казан» дигән бабында Фуксның «Краткая история города Казани» исемле китабыннан[4] алган сүзләр (каю сүзләрне Морад әфәнде рәҗман[5] рәд итә[6]) ап-ачык күренеп тора.

Мелла Хөсәен әфәнде Фәезхани[7] кебек тарихка бик киң сурәттә ашна[8] улган шәкертләре Шиһаб хәзрәттән рус әдәбиятындагы тарихи мәгълүматны дәрих итмәгәннәрдер[9]. Моның өстенә Казан университетындагы Тарих җәмгыятендә һәм Казанда 1877 елда Яурупаның һәр тарафыннан җыелган тарих галимнәренең зур мәҗлесендә әгъза булуы мөнәсәбәте илә мәнбәгъләрдән[10], һәрхәлдә, файдаланмый калмаган. Тарих вә этнографиянең олуг галимнәреннән профессор Гольдвальд[11] илә таныш вә якын дус булган. Ул исә Мәрҗанине Аурупадан килгән һәммә олуг затлар илә (миссионер профессор Маловның

[1] Зикер итә – телгә ала.

[2] Мәхазләр – чыганаклар.

[3] Тәкърибан юктыр – юк диярлек.

[4] Фукс – Бу китап башта «Казанские известия» журналының 1818 нче елгы 77, 78, 80 нче саннарында дәрҗ ителгән. Соңыннан «Общество археологии, этнографии, Истории при Казанского университета» журналының 1905 елгы XXI җилдендә рисалә хәлендә табгы ителгән.

[5] Рәҗман – бик үк ышанып бетмичә.

[6] Рәд итә – кире кага.

[7] Хөсәен әфәнде Фәезхани – Фәезханов Хөсәен (1828–1866), тарихчы, филолог һәм педагог. Ш. Мәрҗанинең талантлы шәкерте. Мәрҗани белән даими хат алышып, фәнни ачышлары белән уртаклашып торган.

[8] Тарихка бик киң сурәттә ашна улган – тарихтан күп мәгълүматлы, тарихны яхшы белгән.

[9] Дәрих итмәгәннәрдер – кызганмаганнардыр.

[10] Мәнбәгъләрдән – чыганаклардан.

[11] Профессор Гольдвальд – Готвальд Иосиф Федорович (1813–1897), шәркыятьче галим, 1849–1897 елларда Казан университеты профессоры. Хезмәтләре шәрык филологиясе һәм тарихына карый.

нәкыленчә[1]) таныштыра торган булган. Ничек тә бу эшләрнең Мәрҗани мәрхүмгә күп файдалары булган һәм әсәрләренә дә яхшы тәэсир итә алганнар.

*Әхмәтзәки Вәлиди*

*Мәкалә сәясәт эшлеклесе, тарихчы, тюрколог, публицист Әхмәтзәки Вәлиди (Вәлидов Әхмәтзәки Әхмәтша улы) (1890–1970) тарафыннан язылып, «Шура» журналының 1914 елгы 9 нчы санында басылып чыккан.*

*Текстны басма өчен Гөлназ Алиева әзерләде*

## Мәрҗани юбилее мөнәсәбәте илә

Милләтнең бөек адәмнәренең озак гомер итүләре, озак хезмәт итүләре, туган көннәре мөнәсәбәтләре илә бөек бәйрәмнәр ясауның халыкта милли аңны тәрәккъый иттерү вә милли хисне үстерү юлындагы файдалары булдыкыны, уйлыймын ки, озын-озак исбат итеп торуга да хаҗәт юк. Буны халкымызның шаять, бөек бер кыйсеме[2] аңлый торгандыр. Шуңа күрә мондый вакыйгалар мөнәсәбәте илә булган форсатларны ганимәт[3] белеп, мондый вакыйгалардан киңрәк рәвештә файдаланып калырга тырышырга кирәк. Чөнки бу милләт эчендә, хосусан бездә, мондый вакыйгалар бик еш булмыйлар. Әллә ничә елга, хәтта унар-унбишәр елга бер генә киләләр. Шул сәбәпле мондый бәйрәмнәремезнең кадерен белеп, алданрак хәзерләнәбрәк, бу кебек бөек бәйрәмнәрне милләтнең иң караңгы кыйсемнәре тарафыннан бөйлә иҗабәт иттерерлек[4] рәвештә ясарга, мәзкүр[5] рәвештә, киң иттереп файдаланырга кирәк.

---

[1] Миссионер, профессор Малов – Малов Ефимий Александрович (1835–1918), православие динен тотучы тюрколог-миссионер, язучы. Казан Духовный академиясенең шәрәфле профессоры. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы.

[2] Кыйсеме – өлеше, төркеме.

[3] Ганимәт – уңыш, бәхет.

[4] Иҗабәт иттерерлек – кабул иттерерлек.

[5] Мәзкүр – югарыда искә алынган.

Менә мондый киң рәвештә файдаланыр өчен Мәрҗани хәзрәтләренең туган көннәре – янә йөз ел тулу мөнәсәбәте илә ясалачак бәйрәмемез, минемчә, иң муафикъ бәйрәмдер. Чөнки Мәрҗани руханиларымыздан улдыкыннан, хәзерге көндә ул руханиларымызның һәммәсенә диярлек рәвештә мәгълүм һәм руханиларымыз тарафыннан бөек ихтирам илә файдаланадыр. Мәрҗанинең шундый мәүкыйгда[1] булучылыгы, аның бәйрәмен халык бәйрәме иттерер өчен иң беренче юл була алыр иде. Мәрҗани бәйрәменә без мәсҗедләремезне дә (мәктәпләремез, табигый, катнашачак) катнаштырыр вә мәсҗедләремез аркылы бәйрәмне халык бәйрәменә әйләндерә алыр идек.

Мәрҗани хәзрәтләре безнең татар-төрк дөньясын әйләндереп алган җәһаләт крепостенә беренче мәртәбә туп атучыларымыздан, татар әфкяре гаммәсендә[2] бөек перелом ясаучы Гаспринский кебек бөек даһиларымызга мәдәният вә мәгариф орлыгын чәчәр өчен почва – әсас хәзерләп калдыручыларымыздандыр. Шул сәбәпле ул мөхтәрәмнең туганына йөз ел тулу сәбәпле ясалачак бәйрәмемез камил халык бәйрәме булырга чын-чыннан лаеклы бәйрәм була алса кирәк.

Мәрҗани хәзрәтләренең туганына һиҗри хисап илә 1333 нче елның 7 нче рабигыль-әүвәлендә (1915 елның 10 гыйнварларына тугры киләдер) йөз ел туладыр. Димәк ки, хәзер бу юбилей көненә 4 айлар чамасы вакыт калган. Әгәр бу бәйрәмне зур халык бәйрәме итәргә теләгән вакытта, бәйрәмгә әзерләнер өчен, вакыт бик күп калмаган инде, хәзер бәйрәм әзерлекләрен күрә башларга вакыт бик җиткән.

Мәрҗанинең туганына 1915 елда йөз ел тулуы һиҗри илә булдыкыннан, милади хисап белән хисаплаганда, тагын 3 елга сабыр итәргә дә юл бар әле. Ләкин Мәрҗани хәзрәтләре олуг бер дин галиме булдыкыннан, үзе исә әсәрләрендә һәрвакыт һиҗри хисабыны алда йөртәрәк аңар ихтирам күрсәтдекеннән, аның исеменә ясалачак бу бөек бәйрәмнең дә, хәзрәтнең үзенә ихтирамән һиҗри хисап илә ясалуы һәр җәһәттән артыграк булачактыр. Шуңар күрә бу олуг бәйрәмнең кичектерелмичә

[1] Мәүкыйгда – урында.

[2] Әфкяре гаммәсендә – фикерләр дөньясында, массасында.

киләсе елның гыйнварында ясалуы мәгъкуль[1] күреләә.

Әгәр без, бу бәйрәмне кичектермичә, вакытында ясарга теләсәк, ул вакытта, югарыда әйтдекемчә, бу көндә аның хәзерлегенә керешү тиеш; бу хәзерлекне күрә башлау вазифасы да, шөбһәсез, Казан өстенә төшәдер.

Табигый, мондый зур бер эшкә рәсми рөхсәт илә, рәсми организация аркылы тотыну тиеш булачак. Мин уйлыймын ки, бу безнең саф вә милли, хәтта кыйсмән[2] дини булган бер эшемезгә хөкүмәтемез тарафыннан, шаять, манигъләр[3] күрелмәс. Шул сәбәпле Казанда хәзерге көннән Мәрҗани юбилеен ясау өчен Казанның зыялыларыннан, җәмәгать хадимнәреннән вә руханиларыннан тәшкил иткән бер комитет тәэсис итәргә[4] рөхсәт алырга вә шул комитет аркылы һәммә юбилей хаҗәтләрен күрә башларга бик вакыт.

Әгәр без хәзерлекне хәзерге көннән күрә башламасак, юбилей вакытына кадәр күп эш күрә алмаячакмыздыр ки, ул вакытта безнең юбилеемезнең исеме генә булып, үзе хакыйкатьтә булмый калачактыр.

Менә шундый өметсезлек картинасын алга китерәрәк, без бу көннән Казанның могтәбәранын[5] үзара фикерләшергә һәм комитетка кешеләр билгеләп, юбилейнең программасын төзеп тасдыйк иттерергә[6] бирергә вә рөхсәт алган көннән эшкә тотынырга дәгъват итәмез[7]. Уйлыймын ки, Казан зыялы вә руханилары һәм җәмәгать хадимнәре тиздән үзара бу тугрыда киңәшеп, шаять, эшкә тотынырлар, Казаннан чыккан бөек бер галимнең шундый зур бәйрәмен кеше төсле иттереп ясарга кулдан килгән кадәр тырышырлар.

Ходай бирсен дә, шулай булсын иде.

*И. Бикколов*

---

[1] Мәгъкуль – аңлаешлы, акылга сыя торган.

[2] Кыйсмән – өлешчә.

[3] Манигъләр – киртәләр, тыюлар.

[4] Тәэсис итәргә – төзергә.

[5] Могтәбәранын – ихтирам ителә торган кешеләрен.

[6] Тасдыйк иттерергә – расларга.

[7] Дәгъват итәмез – чакырабыз.

*Мәкалә җәмәгать эшлеклесе, педагог Ибраһим Бикколов (1884–1938) тарафыннан язылып, «Кояш» газетасының 1914 елгы 18 сентябрь санында (513 нче сан) басылып чыккан.*

*Текстны басма өчен Илһам Гомәров әзерләде*

## Шиһабеддин әл-Мәрҗани

Ин әсәрунә тәдуллю галәйнә фә-нзуру бәгдәнә илә әсәр[1].

Ошбу олуг галимемезнең вафатына йегерме биш ел тулу мөнәсәбәтилә, мәрхүм остазымызны хәер илә йад идеп[2], бу кыска мәкаләне язарга тиеш улды. Шиһабеддин Һарун бине Баһаведдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре тарих һиҗри илә 1233 нче сәнә рабигыль-әүвәлдә Казан нахиясе[3] Йабынчы карьясендә[4] дөньяга килеп, «сәнәршидүкә иршәдәкә»[5]дә атасы хозурында тәхсил идеп[6], соңра 1254 нче елда Бохара тарафына сәфәр идәрәк, анда унбер ел мөддәте тәхсил кылган соң, 1266 нчы елда мәмләкәтгә кайтып, Казанга беренче мәсҗид җәмигынә имам-хатыйб, мөдәррис вә остарши[7] мөхтәсиб гонваны[8] илә указ алып, тәгъйин иделде[9]. Бу урында кырык ел мөддәте хезмәт идеп, 1306 нчы ел шәгъбан аенда вафат улды. Вафатында 74 яшендә иде, рәхималлаһу тәгалә. Ислам милләтендә гыйлемнең сүнгән гасырларында килүб йитешкән галимләрнең берсе, шөбһәсез, Шиһабеддин әл-Мәрҗани иде. Мәрҗани хәзрәтләре ислам галәменең кай тарафында улса да, гасырларында гадәдләре[10] бармак санындан үтмәгән мөстәсна[11] алымлардан икәненә

[1] «Эзләребез безгә күрсәтә, бездән соң карагыз эзләргә» – Дәмәшкъ галиме һәм язучысы Габдер-Раззак әл-Битарның (1837–1916) бер шигыреннән өзек.

[2] Йад идеп – искә алып.

[3] Нахия – өлкә.

[4] Карьясендә – авылында.

[5] «Сәнәршидүкә иршәдәкә» – «Туры юлга бастырырмын».

[6] Тәхсил идеп – белем алып.

[7] Остарши – старший.

[8] Гонван – дәрәҗә атамасы, титул.

[9] Тәгъйин иделде – билгеләнде.

[10] Гадәдләре – саны.

[11] Мөстәсна – искәрмә.

аның калдырдыгы әсәрләре иң дөрест дәлилләр вә шаһәдәләрдер. Мәрҗани хәзрәтләре гасырның мөҗәддидләрендән[1] икәненә гамәлән[2] күрсәтмешдер: дине исламда игътикад[3] вә гамәл җәһәтләрендән кергән күб бидгатьләрне[4] күрсәтеп, исламны бу бидгатьләрдән арчып, әүвәлге сафлыгына кайтаруга иҗтиһад итмешдер. Бу иҗтиһадының сәмәрәсе[5] дә тиз корылмышдыр: бу көндә голямәмез таифәсендән интибаһ[6] табкан бер кыйсеме, шиксез, мәрхүм остазның әсәрләрендән истифадә кылган[7] шәкердләредер. Мәрҗанинең гыйлем юлындагы хезмәтләрен бер-бер санап тәфсыйл кыйлурга[8] бу кыйсми мәкаләдә мөмкин түгел. Аның үз әкъляме нәшер иделәчәк мөфассал[9] тәрҗемә хәлендә бу хезмәтләре тәмаман күрсәтелмеш. Без фәкать бу урында Мәрҗанинең хезмәтләренә иҗмалән[10] ишарә кылып кына кидәчәкмез: Мәрҗани иман вә игътикад мәсьәләләрендә сөннәте халисә[11], сәләфләр юлында иде. Сәләфләр мәсләгенчә хәзун-нәгъл бин-нәгъл[12] игътикадка каләмне катышдыруга гаять мөнкир[13], халис бер сөнни иде. Гамәл бабында дәхи китабе сөннәт кулында сабит улып, бидгатьләрдән гаять сакланучы иде. Бу тугрыда бик мөһим, исемләре һәр кемгә мәгълүм күб әсәрләре вардыр.

Йәнә Мәрҗанинең тарихымызга гаять игътина идеп[14] яздыгы ике җилдле «Мөстәфадел-әхбәр» намлы тарихы безем ичүн иң газиз әсәрләрендәндер. Әхвали мәҗһүл[15] әүвәлән бер кавемнең

---

[1] Мөҗәддид – яңартучы.
[2] Гамәлән – эш белән.
[3] Игътикад – ышану.
[4] Бидгатьләрне – элекесенә каршы килә торган яңа бер эш.
[5] Сәмәрәсе – җимеш.
[6] Интибаһ табкан – уянган, күз ачылган.
[7] Истифадә кылган – кулланган.
[8] Тәфсыйл кыйлурга – җентекләп аңлатырга.
[9] Мөфассал – җентекле.
[10] Иҗмалән – кыскартып.
[11] Халисә – саф, чын.
[12] Хәзун-нәгъл бин-нәгъл – эзлекле дәвам итү.
[13] Мөнкир – инкяр итүче.
[14] Игътина идеп – игътибар итеп.
[15] Әхвали мәҗһүл – билгесез, танылмаган хәлләр.

тарихын башлап тәхкыйк[1] вә интикад[2] илә дөрест юлга куйып язарга бик зур ижтиһад вә хисабсыз һиммәт[3] хаҗәт буладыр. Безем Мәрҗани бу тугрыда гайрәт вә һиммәтене бәзел идеп[4], соңгы тарихларымызга нигез улурдай, хорафатдан арчыклаган бер дөрест тарих калдырды. Мәрҗанинең ялгыз бу хезмәте илә дә тәкъдир иделүргә тиешлеге билгеледер.

Тәгълим юлында барышымызда күб хаталарымызга тәнбиһ идүб, бу иң мөһим булган тәгълим тәгаллем[5] бабында нинди мәсләкдә[6] улурга тиешлекне бик ачык күрсәтде. Мәрҗани дин вә гыйлем юлында армый-талмый хезмәтендә дәвам вә сәбат идүб[7], бу юлда күб михнәт вә изалар чикде. Бу хәлләр исә табигый улдыгындан, боның ичүн эшендән тукталмады, кердеге юлындан чыкмады. Боны исә аңа сәләфләрдән калган бер мирас кеби каршылады. Чөнки бу юлда улганларга һәр гасырда иза вә җәфа кылучы хасидләр улган. Бу хасидләрдән нинди зур михнәтләр күргән гыйльме әсләфнең хәлләре тарих укучыларының күз алларында безем Мәрҗанигә дә шундый хасидләр, табигый, заһир улды. Бонлардан күб җәфа чикде, күб бөһтанлар[8] ишетде. Аның хезмәтләре, вакытында дийәремездә гомумнең тәкъдиренә ирешмәсә дә, үзендән соң озак да үтмәде, Мәрҗанинең сүзләрен аңлаучы, мәсләгенә аеручылар һәркайда заһир улды. Мәрҗанинең гали фикерләре дәхи берәр гасыр үтми аңлашылмаз дип торганда, бер дә көтелмәгән рәвешдә бу аңлашу заһир улды, бу исә интибаһ заманының тәэсире улырга кирәк. Мәрҗанинең үз вафатында да хезмәтләренә тәкъдир идүчеләр дийәремездә дә, әлбәттә, юк дәгел иде. Гыйлеменең киңлегенә, башкалардан айырам бер галим улмагына телләре илә икърар итмәгәнләр дә күңелләре илә, әлбәттә, игътираф иделү иде. Чит мәмләкәтләрдә исә Габделхәй әл-Ләкнәви, Рәхмәтулла

[1] Тәхкыйк – хакыйкатькә чыгару.

[2] Интикад – тәнкыйть.

[3] Һиммәт – кайгырту.

[4] Бәзел идеп – мул итеп бирү.

[5] Тәгаллем – өйрәнү.

[6] Мәсләкдә – дөньяга караш.

[7] Сәбат идүб – нык торып.

[8] Бөһтанлар – ялалар.

әл-Хинди, Садыйк Хәсән әл-Кануҗи, Мөхәммәд Бәйрәм әт-Туниси кеби гасырының дийәренең мөстәсна галимләре Мәрҗанинең кем икәнен аңладылар, тиешенчә тәкъдир вә мәдех кылдылар. Габделхәй әл-Ләкнәви «Ән-нәфиг әл-кәбир»дә, Кануҗи «Лүктату-л-гаҗлән»дә, Мөхәммәд Бәйрәм әт-Туниси «Сөкүтел-игътибар»да Мәрҗани әсәрләрендән байтак сүзләр нәкыль идеп[1], аңа мәдех вә сәна кылмышлар, бондый гасырда бу кеби галимләрнең зоһуры Аллаһ Тәгаләнең бөек бер фадле вә мәрхәмәте дийә шөкранә итмешләр. Рәхимәһүм Аллаһу Тәгалә әҗмәгыйн[2].

*Мәкалә 1914 елны «әд-Дин вәл-Әдәб» журналының 11 нче санында басылып чыга. Текст шуннан алынды.*

*Текстны басма өчен Чулпан Хәмидова әзерләде*

## Бу көн Мәрҗани туды

Бу көн – Русиядәге мөселманнарның, бигрәк тә эчке Русиядәге татарларның бик зур милли вә тарихи бәйрәмнәре. Чөнки бу көн безнең иң зур исламчы дин галимебез, иң олы милли мөәррихемез Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре дөньяга килде. Ул туганда без үлек идек. Аның фикер вә әсәрләре мәйданга чыкмыйча без шәригать вә динне фәкать схоластикадан гыйбарәт дип кенә аңладык. Хәдис, Коръән вә бик кыйммәтле иске ислам әсәрләре белән мөнәсәбәтемез бер дә юк яки бик аз иде. Без Коръәнемезне мәҗлесләрдә, кабер өсләрендә генә укып торган бер заманда Мәрҗани хәзрәтләре: «Мөселманнар! Сезгә Тәңре Коръәнен аның белән гамәл итеп, хак вә тугры юлга күнү өчен иңдерде. Сез Коръәнне вә хәдисне ташлаганлыгыгыз сәбәпле хур вә рисвай булдыгыз!» дип, безнең өстебезгә кычкырынды. Без башта бу тавышның мәгънәсен аңлый алмыйча хәйран вә дәһшәт[3] эчендә калсак та, бара торгач, әкренләп, бу мөкаддәс тавышның мәгънәсен аңлый башладык. Мәрҗанинең

[1] Нәкыль идеп – күчереп.

[2] Барчасына Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре ирешсен.

[3] Дәһшәт – курку.

колагыбызга ят тоелган шул тавышы тәэсире белән байтагыбыз Коръәнгә кулымызны суздык.

Без Мәрҗани дәверенә кадәрле татар исеменнән кача һәм аңардан нәфрәт итә идек. Мәрҗани: «Ата-бабайларын танымаганнар, милли гадәтләрен белмәгәннәр дөньяда яши алмыйлар, дөньяда торырга теләсәгез, бабаларыгызны исегезгә алыгыз, мазыйыгызга[1] әйләнеп карагыз!» – дип тавышланды.

Һатифтан[2] килгән төсле ишетелгән бу аваз Исраил суры кебек безгә тәэсир итте. Без каберләрдән кубарылган кешеләр кебек, курка-курка гына башларыбызны әйләндереп, тирә-якка вә күршеләребезгә карый башладык. Артыбызга таба чынлабрак карасак, зур каһарман вә батыр йөрәкле бабаларыбыз киң сахра вә яланнарымыз мазыйның бик матур вә бик шәрәфле берсенә икенчесе тоташып, тезелеп торалар. Ямьле туган тел, шәрәфле тарих борынгы бабайларның гали хаклары, күркәм табигатьләре, хан Урда да Болгар вә Казаннар Мәрҗани саясендә[3] безнең исебезгә төште дә, «татар» дигән сүздән хурлану урынына аның белән ифтихар итә[4] башлады.

Менә бу көн шул дини вә милли юлбашчыбыз Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре торды. Без аны мәсҗед вә мәдрәсәләребездә яд итәмез[5], сагынабыз. Коръәннәр хәтем кыйлып[6], аның рухына багышлыйбыз, тәрҗемәи хәлен вә эшләрен тикшереп чыгабыз. Берничә еллар элек дини вә милли хезмәтләренә каршы аңар ләгънәт укылган, изге бабайларның явыз угыллары тарафыннан җәфа вә газаплар белән каршы алынган Мәрҗани бу көн «дини вә милли ислахчы» исеме белән яд ителә, мәктәп вә мәдрәсәләремездәге яшь угыллары аны сагыналар, аның туган көнен бәйрәм итәләр. Милләтебезнең һәр сыйныфы, мәсҗед вә башка урыннарга җыелып, юлбашчы бабалары Мәрҗани тууы белән бер-берсен котлашалар.

---

[1] Мазыйыгызга – үткәнегезгә.

[2] Һатифтан – гаиптән.

[3] Саясендә – аркасында, ярдәме белән.

[4] Ифтихар итә – горурлана.

[5] Яд итәмез – искә алабыз.

[6] Хәтем кыйлып – укып.

Ләкин бу хатирәләр, бу тәбрик итешүләр барысы да Мәрҗани исемен безнең арабызда мәңгегә яшәтә алмый. Мәрҗани безне дөньяда мәңге яшәргә хәзерләүче олуг бер даһи булдыгыннан, безгә дә аның исемен мәңгегә яшәтү олуг бер бурыч булып төшә. Әгәр без шул бурычны өстебездән төшерә алмасак, безнең сагынуларыбыз барысы да рия[1], барысы да тышкы күренештән гыйбарәт булып калачак.

Милләт олуг даһисы Мәрҗани туган көнне тагы да хөрмәтләп, шатланып каршы алачак вә Казанда зур юбилей бәйрәме ясаячак иде. Ләкин ватан башына килгән зур вакыйгалар милләтнең бу теләгенә манигъ[2] булды, милләт Мәрҗанигә каршы булган тиешле ихтирамын йиренә йиткерә алмады.

Мәрҗанигә каршы күрсәтеләчәк вә эшләнәчәк бу ихтирамны сугыштан соң да мәйданга чыгару мөмкин булдыгыннан, бу бурыч сугыш сәбәпле генә милләтнең өстеннән төшми, һәрхәлдә милләт аны сугыштан соң да ихтирам итәргә бурычлы булып кала.

Мәрҗанине сагынуыбыз, аны тәбрикләшүебез рия вә тышкы күренештән генә булмавын ватан тынычланганнан соң гамәли итеп ни рәвештә вә нинди изгелегебез белән күрсәтәчәкбез? Бу турыда без үз тарафыбыздан, сугыштан соң эшкә керешү шарты белән, башлап ике җәмгыять төзүне муафыйк күрәмез. Бу җәмгыятьнең берсе «Шиһабеддин әл-Мәрҗанине тану җәмгыяте» исемендә булып, аның эше Мәрҗанине әсәр вә эшләре васитасы берлән таныштыру булыр. Татарча язылган әсәрләрен шул көенчә, гарәпчәләрен татарчага тәрҗемә итеп бастырыр. Икенчесе «Мәрҗанигә ядкәр калдыру җәмгыяте» аталып, Мәрҗани исемен мәңге яшәтер өчен берәр хатирәлек мәйданга китерер. Мәрҗани дин галиме булдыгыннан, без үз тарафымыздан аның исеменә эшләнәчәк ядкәрнең голүме исламия[3] мөкәммәл укылуы өстенә фән вә рус теле дә укылачак чын

---

[1] Рия – икейөзлелек, ясалмалылык.

[2] Манигъ – киртә.

[3] Голүме исламия – ислам дине белемнәре.

мәгънәсе белән «мәдрәсәи галияи диния» булуын мөнасиб,[1] хәтта тиешле итеп табабыз.

Мәрҗани дин галиме булып, хөкүмәтебез белән гүзәл мөнәсәбәттә булдыгыннан, аның исеменә эшләнәчәк эшләрне рәсмиләштерү, шаять, читен булмас.

Мәрҗани –19 нчы гасырның гына түгел, бәлки ничә гасырлар өчен дә ислам дөньясында йитешкән олугларның берсе. Ул вакыйгда бик олуг, 19 нчы гасырның бер дә көтелмәгәндә безгә бүләк ителгән бер даһисы иде. Дөнья вә аның әһлендә олуг ирләр вә даһиларга каршы хөрмәтсезлек күрсәтү, алар белән тартышу бер гадәт булдыгыннан, Мәрҗаниебез дә бу гадәттән котыла алмады. Бик күп газап вә җәфалар күреп дөньядан үтте.

Рухың шат, урының җәннәттә булсын! Әй олуг Мәрҗани!...

## *Мәрҗани хәзрәтләре*

Шиһабеддин бине Баһаведдин бине Сөбхан әл-Мәрҗани хәзрәтләре 1233 хижри 7 нче рабигыль–әүвәл (милади 1818 дә, гыйнвар 3 ендә) Казаннан 50 чакрым ераклыктагы Ябынчы авылында дөньяга килде. 1306 һиҗри елында шәгъбән 29 ында (1889 нчы ел апрель 18 ендә) 74 яшендә вафат булып, Казан мокабәрәсендә[2] дәфен ителде[3].

6 нчы бабасы Габделкоддус Мәрҗан авылы урынына башлап килеп утырганлык сәбәпле, бу нәсәб[4] Мәрҗани дип шөһрәт тапты. Мәрҗан Казаннан 50 чакрым чамасындагы бер авыл.

Мәрҗанинең ата вә анасы ягыннан булган нәселе заманасында гыйлем, кәмаләт[5] берлән шөһрәт чыгарды. Мәрҗани үз нәселеннән булган затларның 20 дән артык авылда имам булганлыкларын бәйан итә.

[1] Мөнасиб – яраклы.

[2] Мокабәрәсендә – зиратында, каберлегендә.

[3] Дәфен ителде – җирләнде.

[4] Нәсәб – нәсел, ыру

[5] Кәмаләт – камиллек.

### *Мәрҗани сабый чакта*

Мәрҗани анасыннан 5 яшьтә ятим калды. Анасы Бибихөбәйбә гакыллы, күркәм мөгамәләле, гыйбадәтчән бер хатын булып, 29 яшендә 1823 елда вафат итте. Анасы дөрест вә гүзәл язу яза белүче хатыннардан булып, аның каләме берлән язылган матур догалыкларны Шиһаб үзе саклаганлыгын бәйан итә.

Мәрҗанинең атасы ягыннан булган бабалары арасында мелла Габденнасыйр ––бине Сәйфелмөлек кебек бөтен гомерен гыйлем хезмәтендә гыйбадәт белән үткәргән затлар бар. Бу зат Сембер вилаятендәге Чокалы авылыннан булып, Ашыт авылында имам вә мөдәррис иде. Мәдрәсәсеннән байтак имамнар йитеште. Бу зат Коръән вә хәдискә тәмәссек итә[1], тугры сөйли, һичкемнән курыкмый, гыйбадәттә төрле мәзһәбләрне җыеп гамәл кыйла иде. Мәрҗани хәзрәтләре бу бабасы янында байтак вакытлар калды.

Мәрҗанинең атасы Баһаведдин Бохарага барып, укучыларның иң могтәбәрләреннән[2] саналып, Бохара әмире Әмир Хәйдәр бине Мәгъсумнең[3] гыйлем мәҗлесләренә хазыйр булып[4], әмирнең зур илтифатларына наил булды[5]. Хәтта авылына кайткач та, әмирнең һәдияләре аңар килеп торды.

Баһаведдин Бохарада вә Руссия мөселманнары эчендә яшәгән галимнәрнең тәрҗемәи хәлләрен яхшы белүчеләрдән булып, Мәрҗани хәзрәтләре атасыннан бик күп файдаланды. «Вафиятел-әсляф» һәм «Мөстәфадел-әхбар» исемле әсәрләрендә Мәрҗани атасыннан күп нәрсәләр риваять итә. Мәрҗанинең бабасы Сөбхан яшьлегеннән гыйлемгә ихласлы булып,

---

[1] Тәмәссек итә – таяна.

[2] Могтәбәрләреннән – хөрмәтлеләреннән.

[3] Әмир Хәйдәр бине Мәгъсум 1242 һиҗри (1826 милади) елда вафат булган. Бохара әмирләренең гыйлемгә ихласлыракларыннан булып, кайвакыт сараенда гыйльми мәҗлесләр ясап, үзе дә дәрес укыткан. Коръән Кәримне ятлау белән дә мәшһүр булганга, Бохара халкы үзен «Әмир Сәгыйд» дип искә ала торган булган.

[4] Хазыйр булып – катнашып.

[5] Илтифатларына наил булды – хөрмәтенә иреште.

шәкертлек вакытында гарәпчә, фарсыча алтмыш кадәрле китаплар күчереп чыгаруын Шиһаб хәзрәт үзе риваять кыла. Бу зат тарих вә төрле вакыйгалардан, борынгы заман хәлләреннән хәбәрдар иде. Мәрҗани хәзрәтләре бу бабасы сөйләгән тарихи вакыйгаларны бик яратып вә ләззәтләнеп тыңлады һәм бик күп истифадә дә кыйлды[1].

Менә ике ягы да диянәтле[2], гыйлемгә мәхәббәтле, заманасында татарның иң югары сыйныфыннан саналган бу гаилә безнең иң зур исламчыбыз Шиһаб хәзрәтне тәрбияләп безгә бүләк итте.

Мәрҗани бала вакытында үзлегеннән һәртөрле уеннар да уйлап чыгара иде.

Мәрҗанинең бала вакытында битенә кәгазь капчыклар куеп, бала-чага вә карчыкларны куркытып йөрүе дә бик мәшһүр.

Мәрҗани яшьлегеннән үк йөрәкле вә батыр табигатьле булып, куркынычлы эшләргә керешә торган булган. Мәрҗанинең әдәбе, батырлыгы өстенә, тәне дә таза булган.

Көрәшеп, әтрафындагы мәшһүр батырларны еккан. Садреддин хәзрәт риваятенә күрә: «Мәрҗани һәр җәһәттән башкалардан өстен булуны сөя, көрәшергә бик ярата, Ташкичү вә аның тирәсендә «Көрәшче Шиһаб» исеме белән шөһрәт чыгарды. 19 яшендә чагында Казан артында атаклы «Ибрай батыр»ны да җиңгән.

Мәрҗани бала вакытыннан ук диянәтле булып, бер дә намаз калдырмаган. Балигъ булмастан элек, тир хәстәлеге белән авырганда калган намазларын да каза кыйлган[3]. Атасы кыска көннәрдә ястү фарыз булмый фикерендә булганга, ул да атасына ияреп ястү намазларын калдырган булган. Иҗтиһад дәрәҗәсенә ирешкәннән соң, каза кыйлып, өстеннән бурычын төшергән. Яшьлегендә үк Мәрҗанинең киләчәктә зур бер адәм булачагын күрсәтәчәк хәлләр булып үткән. Ул биш яшендә чагында анасы авыру вакыттагы хәлләрне хәтерли. Мәче баласы белән су буенда уйнап йөргән җиреннән анасы аны чакыртып кай-

[1] Истифадә кыйлды – файдаланды.

[2] Диянәтле – диндар (динле).

[3] Каза кыйлган – вакытында үтәлмәгән эшне (бу очракта намазны) үтәгән.

тарткач, яшьле вә кайгылы күзләрен тегеп: «Балам! Миннән соң анаң кем булыр? Кемгә әнкәй дип әйтерсең? Өст-башыңны кем карар?» – дигәнен хәтерли.

Шиһаб хәзрәт 3–4 яшендә чагындагы бер-ике вакыйганы да исендә тота: «Ябынчы[1] авылыннан Ташкичүгә[2] күчкәндә мине кабык кимәгә,[3] сыерыбызны чанага салып китерделәр, шул вакыт мин, таңга калып, сыер да атка утыра икән, дип уйлаган идем», – ди.

Мәрҗанинең яшьлек вә егетлек вакытындагы хәлләре тугрысында энесе Садреддин хәзрәт: «Ул бала вакытында әтәч, каз, тавык, күркә, эт вә мәче кебек хайваннар берлән уйнауны сөя, аларны бер-берсе белән сугыштыра, бәгъзе бер нәрсәләр тугрысында үзеннән яңа фикерләр чыгарып, шуны вөҗүдкә чыгарырга тырыша иде», – ди.

## *Авылда укуы*

Мәрҗани вакытында укулар тәртипсез булганлыктан, ул иске ысул белән, иске китаплардан укыган. Бик аз вакыт эчендә «Бидан», «Шәрхе Габдулла», «Кыйвагыйд», «Гавамил», «Әнмүзәҗ», «Кафийә» китапларын укып чыккан.

Мәрҗани яшьлегеннән дәресләренә иҗтиһадлы булып, дикъкать вә мөхакәмә белән[4] укыган. Хәлфәләреннән берсе яшь Мәрҗанинең тикшерү куәсенә таңга калып: «Никадәр күп шәкерт укыттым, ләкин Шиһабеддин кадәрле зиһенле вә аңлысын күрмәдем... 12–13 яшьлек баланың шул кадәрле белүенә гаҗәпләнәм, хәзрәтнең бу баласы сәламәт булса, зур галим булыр», – дия торган булган.

Мәрҗани, сарыф, нәхү дәресләрен хәлфәләреннән укып тәмам иткәннән соң, атасыннан укырга керешеп, заманасында укыла торган китапларны укып хәтме кәтеп иткәндә[5], 17 яшендә иде.

---

[1] Ябынчы – Казаннан 50 чакрымда.

[2] Ташкичү – Казаннан 70 чакрымда.

[3] Кимә – өсте бөркәүле арба (кибитка)

[4] Мөхакәмә белән – хөкем чыгарып, нәтиҗә ясап.

[5] Хәтме кәтеп иткәндә – укып тәмамлаганда.

*Мәрҗанидә тикшерү вә һәм мөхакәмә куәсе үсүе*

Мәрҗани бу мәгълүм китапларны уку белән генә канәгатьләнмәде. Аның истигъдады[1] моннан югары булганга, һәр нәрсәне нечкәләп тикшерүне сөядер иде. Әткәсенең өстәлендәге мәктүб вә язуларны нечкәләп укый, китапларын моталәга итә[2] иде. Бездә бүгенгә кадәрле гарәп дәресләре бер юлга салынмадыгыннан, шәкертләр төрле фикъһе вә Кәлям[3] китапларын укып моталәга дәрәҗәсенә ирешәләр. Табигый, Мәрҗани дә моталәгасын шул юл белән чыгарган. Башта бер китапны моталәга итәргә кулына алса, 3–4 мәртәбә укымыйча мөәллифнең[4] максудын аңламаган.

Мәрҗани күп китаплар моталәга итеп, мәгълүматын киңәйтүе өстенә, шөбһәле мәсьәләләрне ата вә бабасыннан сорый, һәр нәрсәне дәлил вә хикмәтләре белән төбеннән аңларга тырыша, шәригать мәсьәләләренең хикмәтләрен тикшерә торган булган. Кайбер вакытта ата-бабаларының җавапларына канәгать итми, араларында низагъ вә моназарәләр[5] булып, үзенең үткен зиһене, тикшерү вә тәнкыйтькә булган истигъдады саясендә[6] бик нечкә мәсьәләләрне уйлый торган булган.

Мәрҗани һәр укыган китабын тәнкыйть күзе белән карап моталәга итә. Китаплар, мөәллифләр арасында тәнкыйть вә мөхакәмәләр йөретә иде. Ул үзендә булган истигъдад саясендә үзенең шәрикләре вә хәлфәләре арасында игътибар казанып, галим исемен алган һәм 17 яшендә чагында атасы мәдрәсәсендә дәрес укытырга тотынган.

Ул хәлфә булгач ук, укытачак дәресләрен уйлап, тәнкыйть мөхакәмә итеп, укыту ысулларындагы кимчелекләрне дикъкатькә ала башлаган. Бәгъзе дәресләрне укыту рәвешен үзгәртүне тиешле күреп, әткәсенә дә гарзы кыйлган[7]. Табигый, әткәсе дә

[1] Истигъдады – сәләте; зирәклеге.

[2] Моталәга итә – укып хөкем йөртә, фикерли.

[3] Фикъһе вә Кәлям – ислам дине мәсьәләләре (хокук) һәм Коръән.

[4] Мөәллифнең – китап язучының (авторның).

[5] Моназарәләр – бәхәсләр.

[6] Истигъдады саясендә – сәләте аркасында.

[7] Гарзы кыйлган – аңлаткан, сөйләгән.

аның бу фикеренә каршы килмәгән. Ул бу ислахын гарәп сарфы вә нәхүсеннән башлаган. Иске китапларны яратмыйча, шәкертләренә бу фәннәрне яздырып укытырга тотынган. Балаларга укытыла торган игътикад[1] вә гыйбадәт китапларын муафыйк күрмәстән, бу китапларның ансат вә файдалы рәвештә языларга тиешлегенә ышанган һәм Бохарага киткәнче бу эшкә керешкән дә. Ташкичүнең бәгъзе карчыкларына гамәл вә гыйбадәтләр хакында кечкенә бер рисалә язып биргән. 12–13 яшьләрендә чагында намаз хакында дәхи бер кечкенә китап язган.

### *Бохара сәфәре вә юл хатирәләре*

Мәрҗани 3–4 ел дәрес укытып, китапханәләрендә булган байтак китапларны моталәгә кыйлып, тирә-якта галим исемен алган иде. Ул моның белән генә канәгатьләнмәде. Бер якка китеп, гыйлемен арттыру фикеренә төште. Әткәсенең Бохара вә аның голямасын мактап сөйләве сәбәпле, аның Бохарага мәхәббәте артты. 21 яшендә (1254 һиҗри 4 нче рабигыль-әүвәл/1838 нче елны майның 17 сендә) Бохара сәфәренә хәзерләнде. Ул заманда татарларның Мавәраэннәһер белән булган сәүдәләре бик зур булып, Казан белән Бохара арасында кәрваннар йөреп тора, Бохарага барып, укучылар шулар белән бергә сәфәр итәләр, шәкертләргә йибәрелгән әманәтләр дәхи шул сәүдәгәрләр аркылы йөри иде. Мәрҗанигә дә шундый сәүдәгәрләрдән Мәңгәр бае Мохтар бине Мөхәррәмнең Бохарага йибәреләчәк йөкләре белән сәфәргә чыгарга туры килде. Ул Бохара сәфәрендә ишеткән вә күргәннәрен язар өчен кулланган кәгазенә шулай язган:

«Бохарага сәфәремдә улан мәназил вә мобсыйрат вә мәсмугатьнең бәгъзесе[2] монда язылыр...».

Мәрҗани бу кәгазьләренә Бохара юлында очраган 15 тән артык шәһәр, авыл вә мәнзилләрне[3] язган. Мәрҗанинең авылыннан чыгып Троицкига йиткәнче әһәмиятле бер хатирәсе булуы

[1] Игътикад – ышану, инану.

[2] Мәназил вә мобсыйрат вә мәсмугатьнең бәгъзесе – тукталган урыннар вә күрелгән һәм ишетелгәннәрнең кайберләре.

[3] Мәнзилләрне – тукталган урыннарын.

мәгълүм түгел. Бохарага баручы кәрван тугры килмәдектән, ул Троицкида берничә ай калган[1]. Голямасы берлән танышып, гыйльми мозакәрәләренә катнашып сөйләшкән. Анда Әбен-насыйр әл-Курсави хәзрәтләренең китапларын моталәга итүче бер галим мөәзингә очрап, игътикад мәсьәләләреннән сүз кузгалткач, мәзкүр мөәзин Курсавины мактаган. Мәрҗани мөәзингә каршы төшеп: «Фәлән урыннарда Курсави әһле сөннәт вәл-җәмәгатькә каршы килгән. Аның шәригатькә хилаф сүзләре күп булдыгыннан, Бохара әмире Әмир Хәйдәр аны үлтерергә касд кыйлганнан соң, ул качып кына котылган», – дигән. Мәрҗани соңыннан үз фикеренең хата, мөәззин фикере дөрест булганын сөйләп, бу мөәззин сүзе үзенең нәзар дикъкатен[2] Курсавига җәлеп иткәнен сөйли торган булган.

Мәрҗани Бохара сәфәрендә дөя өстендә китап моталәга итеп барган. Юлда «Гакаиде Нәсәфи» китабын ятлап чыккан.

## *Мәрҗани Бохарада*

Бохара мәдрәсәләренең хөҗрәләре[3] вакыфларның шартларына хилаф уларак сатыла. Шул сәбәпле шәкертләр мәдрәсә хөҗрәләрен төрле кешеләрдән сатып алалар.

Мәрҗани, акчасы аз булганлык сәбәпле, хөҗрәсе арзан, килере аз булган «Ишан хәлифә Ниязколый» мәдрәсәсеннән хөҗрә сатып алып урнашкан. Ул барган елларда Бохара гадәте белән шәрех[4] вә хашийәләрне[5] яхшы моталәга итеп, дәресләрен иҗтиһад берлән укыган шәкертләре шәрех вә хашийәләрдәге сүзләрне сөйләгәндә, Мәрҗани яңа бер фикер уйлап, яңа бер сүз сөйли торган булган. Ләкин бераз вакыттан соң, ул үзендә Бохарадагы дәрес тәртипләреннән мәмнүниятсезлек[6] сизгән. Дәхи мәдрәсәләрдә тәфсир, хәдис вә гарәп әдәбияты укыл-

[1] Бу турыда «Мөстәфадел-әхбар»да яза. 2 җилд, 357 б.

[2] Нәзар дикъкатен – игътибарын.

[3] Хөҗрә – мәдрәсәдә бер кеше генә торырлык бүлмә.

[4] Шәрех – берәр китапның авыр урыннарын ачыклап аңлату.

[5] Хашийә – берәр китапның эчтәлеген ачыклаучы икенче бер китап.

[6] Мәмнүниятсезлек – канәгатьсезлек.

мавына эче поша башлаган. Мәрҗани «Вафиятел-әсляф»нең мөкаддимәсендә: «Русия мөселманнары Бохараны үрнәк итеп, аны олугласалар да, Бохараның халкы вә хөкүмәте мәгарифтән бәһрәсез[1], идарәләре бозык, уку-укытулары гаять тәртипсезләр», – ди.

Мәрҗани, дәресханә дәресләреннән мәмнүн булмаганлыгыннан, вакытының күбрәген Бохара китапханәләрендәге иске вә кадерле китапларны моталәга белән уздырган. Мәрҗани, Бохара вә аның голямасы хакында вә андагы эшләрне тәнкыйть кылып, «Игъләмү әбнәәэд-дәһри биәһвали әһли Мавәраэннәһри» исемле бер китап та язган. Ләкин ул, башына киләчәк бәла вә фетнәләр кузгалуыннан куркып булса кирәк, бу китабын үзе Бохарада чагында таратмаган. Бәлки иптәшләреннән берсенә калдырып, үзе киткәннән соң таратуын үтенгән.

## *Мәрҗани Сәмәркандта*

Мәрҗани Бохарада 5 ел торганнан соң, Төркстанда Бохарадан кала гыйльми мәркәз саналган Сәмәркандка «Ширдар» мәдрәсәсенә урнашкан. Сәмәркандның ике зур вә фикерле галимнәреннән булган казый Әбү Сәгыйд хәзрәтләре белән танышкан. Мәзкүр казыйның бик кыйммәтле, галим вә хәкимнәр әсәрләре белән танышкан. Китапханәсеннән истифадә итәргә[2] тырышкан. Бохарада схоластика укып фикере вә игътикады[3] бозылган Мәрҗани шул китапханәдәге иске галим вә хәкимнәрнең әсәрләрен моталәга кыйлганнан соң, игътикадын төзәтергә муафыйк булган. Мәрҗани остазы казый Әбү Сәгыйдтән бик күп нәрсәләр истифадә иткән. Казый хәзрәтләре ислам галимнәренең бик күп әсәрләрен моталәга кыйлган, тарих, хисап, җәбер[4], һәндәсә[5], һәйәт[6], җәгърафия вә болардан

[1] Бәһрәсез – өлешсез, ерак.

[2] Истифадә итәргә – файдаланырга.

[3] Игътикады – иман мәсьәләләре, инануы.

[4] Җәбер – алгебра.

[5] Һәндәсә – геометрия.

[6] Һәйәт – астрономия.

башка, дини вә гакълый гыйлем вә фәннәрне укыган зур бер галим иде. Бу затның тәэсире белән Мәрҗанинең фикере һәм мәгълүматы бик киңәйгән, һичбер мәзһәб әһлен аермыйча, кешесенә күрә остазының ихтирам итүе безнең Мәрҗаниебездә яңа вә гали бер хөсне[1] тудырган. Аның тарих вә тарихи әсәрләр белән шөгыльләнүенә казый Әбү Сәгыйднең зур тәэсире булуында шөбһә юк.

Мәрҗани казыйның китапханәсеннән бик кыйммәтдар гыйльми вә тарихи байтак китапларны күчереп, үзе белән Русиягә дә алып кайткан. Мәрҗани рәсме мәсахиф[2] мәсьәләсенә дә әһәмият биргән. Ул вакытта Сәмәркандта да саклаган «Мосхәфе Госмани» (хәзрәти Госман Коръәне) дип мәшһүр булган Коръәннең язуларына да дикъкать итеп тикшергән. Мәрҗани моны, хәзрәти Госман Коръәне түгел, ди.

Мәрҗани Сәмәркандта чагында үзенә бер мәсләк, гайийә[3] хәзерләде. Сәмәркандта күчерелгән бер китабының башына язып куйган: «Мәзһәби фил-гаклиятел-хөҗҗәт вәл-борһан, вә фин-нәкълият әс-сөннәт вәл Коръән» («Гакыл вә фикер белән беленә торган мәсьәләләрдә минем мәзһәбем дәлил һәм факт булса, дини мәсьәләләрдә хәдис вә Коръәндер») сүзе аның Сәмәркандта үзе өчен билгеләгән мәсләгедер.

Мәрҗани Русиядәге чагында фикере белән тартышкан Әбеннасыйр әл-Курсави хәзрәтләрен таныргa да шул Сәмәркандта муафыйк булган. Ләкин Курсави хәзрәтләре әсәрләре Сәмәркандта табылмаганлык сәбәпле, Бохарага кайткач кына, аларны моталәга иткән. Соңыннан ул Курсави хакында «Тәнбиһ әбнәил-гасри галә тәнзиһ әбнәи Әбүннаср» исемле бер әсәр язып Әбеннасыйр әл-Курсави өстенә ыргытылган төһмәт вә ифтиралардан[4] аны яклаган да.

---

[1] Гали бер хөсне – кыйммәтле бер күркәм сыйфат.

[2] Рәсме мәсахиф – Коръәнне бизәп язу һәм бастыру.

[3] Гайийә – идеал.

[4] Төһмәт вә ифтиралардан – яла ягу һәм ялган гаеп ташлаулардан.

## *Мәрҗани икенче мәртәбә Бохарада*

Сәмәркандтан кайтып, Мәрҗани Бохарада дәхи биш ел торды. Байтак шәкертләр тәрбияләде. Бохараның олуг мөдәррисләре белән мәҗлестәш булды. Һәйәт вә һәндәсә фәннәрен укыды. Ул шул кадәрле моталәгә вә китапка бирелгән иде ки, вакыты заегъ булуыннан куркып, иптәшләре янына барып утырышудан, башка адәмнәрнең хөҗрәләренә барудан тартына, урамнарда туктап сөйләшеп торуны гомер әрәм итү дип хисаплый, урамнарга чыкканда кеше танып, туктатып гомерен заегъ итмәсен өчен, чапанын башына бөркәнеп йөри иде.

Мәрҗани сәламәтлегенә зарарлы булган бер нәрсә дә истигъмаль итмәгән[1]. Әфьюн, нас, күкнар кебек зыянлы агулардан сакланган.

Мәрҗанинең авылда чагында ук китаплар тәэлиф итә[2] башлаганлыгын, Бохарада чагында «Игъләмү әбнәәд-дәһри биәһвали әһли Мавәраэннәһри» китабын язганын бәян кылып үткән идек. Ул, яңадан Бохарага кайткач, тәэлиф белән шөгыльләнә башлаган.

«Горфәтел-хаувафин лигыйрфәтил-хавакыйн», «Әт-тәрикатүл-мүслә вәл-гакыйдәтел-хүснә», «Шәрхе мөкаддимә әр-рисаләтиш-шәмсийә» рисаләләрен Бохарада язган.

Төрки-татар тарихына Бохарада әһәмият бирә башлаган. Төрки-татар тарихына Бохара вә Хива ханнарына гаид булган материалларны шунда җыя башлаган. «Гакаиде Нәсәфи», «Мелла Җәлял» шәрхе вә хашийәләрен язарга да Бохарада хәзерләнгән.

## *Казанга кайтуы*

Мәрҗани, унбер ел Бохарада торганнан соң, туган иле Ташкичүгә кайтырга хәзерләнеп (1262 һижри 10 нчы рәҗәптә / 1849 ел, майның 18 ендә), иптәшләре белән юлга чыкты. Имән

[1] Истигъмаль итмәгән – кулланмаган.

[2] Тәэлиф итә – яза.

Кальга, Орск вә Оренбург шәһәрләренә бераз тукталып, 13 нче рамазанда Ташкичүгә кайтып керде.

Юлдашларын үзенең киң мәгълүматы, иске хәл вә вакыйгаларны күп белүе белән таңга калдырды.

Сәфәрдәшләре Мәрҗанине Казанда бик күтәрделәр, бик мактадылар. Шуларның дәляләте буенча Казанның 1нче мәсҗеденә имам вә мөдәррис итеп куяр өчен, шул мәхәлләнең башлыгы вә заманасында Казанның иң нөфүзле[1] бае Ибраһим Гобәйдулла улы Юнысовка тәкъдим ителде. Байның дәгъвате белән Мәрҗанине имтихан кылыр өчен Казан вә әтрафының могтәбәр галимнәреннән гыйбарәт имтихан һәйәте[2] тәртип кыйлынды. Имтихан мәҗлесендә Мәрҗани схоластикадан имтихан кылган. Ул «Мөстәфадел-әхбар»нең икенче кыйсемендә имтихан сурәтен тәфсил белән[3] яза. Мәҗлестә хазир булган голяма вә имамнардан Мәрҗанине имам итәргә күбрәк тырышучы Гали ишан булган. Ниһаять, Мәрҗани 1850 ел мартның 30 ында Беренче мәсҗедкә имам вә мөдәррислек указын алган.

## *Мәрҗани мәдрәсәсе*

Мәрҗани, указ алгач ук, дәрес укытырга тотынды. Ачык йөзе белән үзен каршылаган шәкертләренә 1266 һиҗри / 1850 ел 26 мөхәррәмдә дәрес башлатты. Шәкертләре: «Нинди фәннән дәрес башлыйк?» – дип сорагач, ул: «Каю фәннән башласагыз да ихтыярыгыз, иң элек тәфсир дәресе башлау мөнасиб[4] булыр», – дип тәфсир укытты. Бишәр ел кадәрле бик рухлы вә җитди рәвештә дәрес укып, тугры фикерле, гыйлемгә ихласлы байтак затлар йитештерде. Ләкин бу муаффәкыять[5] бик озак дәвам итмәде. Мәрҗанинең игътикады, фикъһе мәсьәләләре хакындагы фикерләрен, тугры тәнкыйть вә мөхакәмәләрен

[1] Нөфүзле – абруйлы, сүзе үтә торган.

[2] Һәйәте – комиссиясе.

[3] Тәфсил белән – җентекләп.

[4] Мөнасиб – яраклы, дөрес мәгънәсендә.

[5] Муаффәкыять – уңыш.

Казанның байтак имамнары яратмадылар. Ибраһим бай белән дә аралары бик бозылды. Шул байның тәэсире белән Мәрҗанинең ике мәртәбә указы алынып, башлаган эшләренең юлда калуы һәм Казан голямасының хөсете сәбәпле, бервакыт Мәрҗанидә рух төшенкелеге хис ителде. Шул тәэсир белән ислам йортына – Багдад тарафларына күчү фикере килде. Указы кайтарылып, мәдрәсәсен кулына алуы аны бу фикереннән дүндерде[1]. Әмма икенче төрле манигъляр килеп чыкты. Мәдрәсәсе ватылып төшәрлек хәлгә килсә дә, Ибраһим бай аны төзәттермәде вә башкаларга да төзәтергә юл куймады. Шулай булса да Мәрҗани, яңа мәдрәсә бина ителгәнче[2] 22 ел зур мәшәкатьләр күреп, дәрес укытуында дәвам итте. Русиядәге башка дини мәдрәсәләргә үрнәк булып, Русия мөселманнары арасында ислах вә тәрәкъкый фикеренә хезмәт итәчәк бер мәдрәсә матди вә мәгънәви яктан төрле манигъларга очраганлыктан, тиешле вазифасын үти алмады. Шул 22 ел эчендә Мәрҗани мәдрәсәсенең барышы рухсыз булса да, галиҗанәб Мәрҗани өмидсезлеккә төшеп, вакытын бушка үткәрмәде.

Заманында зур тавышлар күтәргән «Назурәтел-хак», «Хикмәтел-бәлига», «Мелла Җәлял хашийәләре» шул вакытта язылды. Зур куәтләр сарыф итеп, бик нык тикшерү вә моталәга нәтиҗәсендә милли тарихымызның нигезен корды. Бу турыда беренче мәртәбә уларак «Гыйляләтез-заман фи тарихи Болгар вә Казан» исемле китабын язды. Бу китап асаре гатика[3] җәмгыятенең зур җыенында мәшһүр шәркыять галиме Радлов тарафыннан русчага тәрҗемә кыйлынып укылды. Мәрҗани үзе хазир булган[4] мөстәшрикъләр[5] җәмгыятендә аның хезмәте тәкъдир кылынды. Шуннан соң «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле әсәрен язды. Урта Азия тарихы өчен бик мөһим булган «Горфәтел-хаувафин лигыйрфәтил-хавакыйн» исемле

[1] Фикереннән дүндерде – фикереннән кире кайтарды.
[2] Бина ителгәнче – төзелгәнче.
[3] Асаре гатика – археология.
[4] Хазир булган – катнашкан.
[5] Мөстәшрикъләр – шәрыкны өйрәнүчеләр, шәркыять белгечләре.

әсәрен тәэлиф итеп, табгы иттерде.[1] Җиде җилдле «Вафият-тел-әсляф вә тәхиятел-әхлак» дигән олуг әсәренең күбрәге шул чакта язылды. Коръән тасхик итәргә[2] алынып, беренче мәртәбә сәхабәләр рәсменә чагыштырып[3], Коръән бастырды вә бу хакта «Фаваиде мөһиммә» исемле рисаләсен тәэлиф итте.[4]

Соңга таба Мәрҗанинең дәрәҗәсе үсә башлады. Голяма вә халык каршында нөфүзе[5] артты. Ибраһим байның нөфүзе азаеп, мәдрәсәне төзәттермәве сәбәпле, мәхәллә халкы үз араларыннан акча җыеп, хәзерге мәдрәсә урынын йортлары белән сатып алгач, шәкертләр шул йортка күчтеләр.

Мәдрәсә хосусый адәм кулында булган чакта, Мәрҗани, күп мәшәкатьләр күргәнлеге сәбәпле, мәсҗед, мәдрәсә һәм вакыфларны карар өчен мөтәвәллиләр[6] сайлап, Духовное собраниедән[7] тасдыйк иттереп[8] алды. Шулай итеп, рәсми мөтәвәллиләр сайлау эше Мәрҗани тарафыннан башланды.

Яңа мәдрәсәгә күчкәннән соң, Казан имамнары Мәрҗани өстеннән: «Рузәга бер көн элек керде», – дип, Собраниегә шикаять иттеләр. Шул шикаять буенча, Мәрҗанинең алты ай кадәрле указы алынып торды. Соңыннан тикшерелеп, Истанбул, Мәккә, Мәдинә, Шам вә Бохараларда да шул көнне рузәга керүләр билгеле булгач, указы кайтарылып бирелде. Тыштан бик мөкәммәл итеп, халык акчасы белән яңа мәдрәсә бина кылдырды вә шуңа низамнамә[9] төзеде. Мәрҗани мәдрәсәсе дәрес җәдвәленең[10] башка иске мәдрәсәләр программаларыннан аермасы юк яки бик аз иде. Шул сәбәпле, Мәрҗани үзе

---

[1] Тәэлиф итеп, табгы иттерде – язып, бастырып чыгарды.

[2] Тасхик итәргә – төзәтергә, дөресләргә.

[3] Сәхабәләр рәсменә чагыштырып – борынгы Коръән язуы белән чагыштырып, шундагыча төзәтеп.

[4] Тәэлиф итте – иҗат итте, язды.

[5] Нөфүзе – абруе, дәрәҗәсе.

[6] Мөтәвәлли – мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кеше.

[7] Духовное собрание – Диния нәзарәте.

[8] Тасдыйк иттереп – раслатып.

[9] Низамнамә – кагыйдәләр, устав.

[10] Җәдвәл – расписание, дәресләр тәртибе.

мослих,[1] вә мөҗәддид[2] була торып, мәдрәсәсендә схоластика гына укытып, сәләфләр[3] әсәрен, Коръән вә хәдисне укытмау белән төһмәт кылына.[4] Ләкин бу төһмәтнең әсассызлыгы[5] аның тәрҗемәи хәленнән мәгълүм. Анын байтак шәкертләре Мәрҗанинең шәкертләрне Коръән, хәдис гыйлемнәренә, әдәбият, тарих вә башка фәннәрне укырга кызыктыруын, дәресләрдән соң бу турыда күп сүзләр сөйләп, нәсыйхәт иткәнлеген риваять итәләр. Ул заман шәкертләре арасында мәдрәсәдән мәдрәсәгә йөреп, схоластика моназарәләре белән баш ватуны артыклык санаганлыктан, алар Мәрҗанинең бу максудына койма булганнар, анын сәләф дәресләрен укытырга теләве аларга тәэсир итмәгән. Мәрҗани дә вәгазь вә нәсыйхәтләре тәэсир итмәгәнлеген тәҗрибә итеп күргәч, фикерен халыкка әсәрләре аркылы тарату фикеренә төшкән вә шул максат белән китаплар тәэлиф кылырга керешкән.

Мәрҗани хөкүмәт әһленә, рус голямасына да бик мәгълүм кеше иде. Казан губернаторынын үтенүе буенча, ул Алланың мәхлукларына шәфкать итү тиешлеге хакында бер китап – «Әннәсаих»[6] язды. Анын бу китабы хөкүмәт хисабына табгы кыйлынды. Шәһәр вә авыл имамнарына һәм мәдрәсәләренә таратылды. Губернатор Шиһаб Мәрҗанигә тәшәккер итеп мәктүб язды һәм анын бу китабы, русчага тәрҗемә кыйлынып, Казанда чыга торган русча газетада табгы кыйлынды. Ул 1293 һиҗри елда / милади 1976 елда Казан университетында ачылган гыйльми җәмгыятькә әгъза итеп кабул ителде.

Мәрҗани гарәп, фарсы вә төрек телләрендә язылган әсәрләрдән генә истифадә итеп әсәрләрен тәэлиф иттеме яки русча язылган әсәрләрдән дә файдаландымы? Бу хакта яшь мөаррихе-

[1] Мослих – үзгәртүче, реформатор.
[2] Мөҗәддид – яңалык кертүче, новатор.
[3] Сәләфләр – борынгылар.
[4] Төһмәт кылына – гаепләнә.
[5] Әсассызлыгы – нигезсезлеге.
[6] Мәрҗани Ш. «Китабен-нәсаих». Казан, 1985.

мез[1] Зәки Вәлиди[2] әфәнде җәнабләренең үткән елгы «Шура»ның 9 санында бер мөляхазәсе[3] басылып чыкты. Зәки әфәнде бу мәкаләсендә төрле дәлилләр күрсәтеп, мелла Хөсәен Фәезхани кебек русча белгән шәкертләре аркылы рус телендә язылган әсәрләрне дә Мәрҗанинең файдаланганлыгын әсаслы рәвештә язып үтә.

Мәрҗани рус вә башка милләт галимнәреннән дә дуслары булган. Профессор Готвальд Аурупадан килгән зур галимнәр белән Мәрҗанине таныштырып торган. Тарих җәмгыятендә әгъза, рус вә башка милләт галимнәре белән танышып, гыйльми җәмгыятьләргә катнашкан Мәрҗани, әлбәттә, аз булса да, русча да белгәндер. Шәкертләре васитасы[4] иләме, яки үзенең тырышлыгы беләнме, һәрхәлдә, Мәрҗани, тарихларын язганда, русча язылган китаплардан файдаланды. Шундый тәэсирләр сәбәпле рус телен белү тиешлегенә канәгать хасыйл итте.

### *Мәрҗанинең мәҗмугаи асаре*

«Мөстәфадел-әхбар» китабының икенче кыйсменең 52–53нче битләрендә Мәрҗани үзенең мәҗмугаи асарен түбәндәгечә күрсәтә:

1. «Әл-хикмәтүл-бәлига».
2. «Әл-газбүл-фират» Мелла Җәлял шәрхе (Мисыр вә Истанбулда табгы ителде).
3. «Әт-тарикател-мүслә вәл-гакыйдәтел-хүснә».
4. «Әлмәсәл-әл-әгълә».
5. «Тәзкирәтел-мөниб».
6. «Назурәтел-хак» Казанда матбуг.

[1] Мөәррихемез – тарихчыбыз.

[2] Зәки Вәлиди – Вәлиди Әхмәтзәки (1890–1970), тарихчы, тюрколог. Фәлсәфә докторы, Истанбул университеты профессоры. Төрки халыкларның тормышына, мәдәниятенә, теленә һәм тарихына багышланган күпсанлы хезмәтләр авторы. Аның Мәрҗани хакындагы язмасы «Шура» журналының 1914 елгы 9 нчы санында 207–209 нчы битләрендә басылган.

[3] Мөляхазәсе – искәрмәсе

[4] Васитасы – арадашлыгы; биредә: ярдәме, булышлыгы.

7. «Горфәтел-хаувафин лигыйрфәтин хавакыйн» (Казанда матбуг).

8. «Гыйлялəтез-заман фи тарихи Болгар вә Казан».

9. «Мүнтәхабүл-вафияти» (Казанда матбуг).

10. «Вафийәтел-әсляф вә тәхийәтел-әхляф».

11. «Тәнбиһ әбнәил-гасри галә тәнзиһ әнбәи Әбиннаср».

12. «Хаккуль-мәгърифәти вә хүснүл-идраки бимә йәлзимү фи вүҗүбил-фитри вәл имсәк» (Казанда матбуг).

13. «Бәркул-вамид фир-радди галәл-бәгыйдил-мусаммә бин-нәкыйд» (Казанда табгы).

14. «Шәрхе мөкатдимә әр-рисаләтиш-шәмсийә».

15. «Тәхарире мөфрадә» (аерым әсәрләр).

16. «Җәвамигыль-хикәм вә зәраиген-нигам».

17. «Китабен-нәсаих» (Казанда хөкүмәт мәсрафы белән матбуг).

18. «Мөхтасарун ән-нуҗүмиз-заһра фи әхвали Мисыр вәл-Каһирә».

19. «Хаккуль-бәйан вәт-тасвир фи мәсьәләти хүдүси галәмил-әмри вәт-тәкъдир».

20. «Әл-хаккуль-мүбин...».

21. «Игъләмү әбнәәәд-дәһри биәхвәли әһли Мавәраэннәһри».

22. «Кәшфел-гатаи ганил-әбсар биәгъләтый таварихи Болгар»

23. «Рисаләтү фи мәсәилин-нәхү».

24. «Мәнәсикүл-хаҗ». Төрек телендә.

25. Төрекчә икенче бер рисалә «Рихләт».

26. «Әл-фаваид әл-мүһиммә» (Казанда матбуг).

27. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Ике кыйсемдә. (Болар икесе дә Казанда матбуг).

28. «Хәзәмәтил-хәваши». Фикъһе ысуллары фәненең аңлатмалы өстәмәсе. (Казанда һәм Мисырда табгы).

29. «Мәшәригыль-усуль» (Казанда табгы).

Моннан башка аның үзе тәэлиф иткән җомга вә никах хотбәләре дә бар.

*Мәрҗани мәйданга куйган мәсьәләләр:*

1) Мәрҗани дәверендә бөтен ислам дөньясы вә шул җөмләдән Русия мөселманнары, Коръән вә хәдистән йөз чөереп хикәят, кыйсса вә схоластикадан гыйбарәт Кәлям китапларына түнеп калганнар иде. Мәдрәсәләрдә тәртип юк иде. Мәрҗани үзенең олуг истигъдады сәбәпле, мөселманнарны, Коръән вә хәдискә кайту, сәләфләр әсәрләрен моталәгә итү тиеш дигән фикерне алга куйды. Шул фикерен башлап шәкертләренә аңлатырга тырышса да, миләре схоластика белән зәһәрләнгәнгә, алар моны аңлый алмадылар. Шәкертләреннән өмид өзгән Мәрҗани төрле китап вә рисаләләре илә мәйданга куя башлады. Әсәрләрендә вә сүзләрендә галим кәлам әһленә бик нык кагылды. Аларны Коръән вә хәдискә мохаләфәт итүчеләр[1], хәтта игътикади[2] мәсьәләләрдә Коръән рухына башка булган ялгыш юлларга кереп адашучылар, дип шелтәләде. Аның бу фикере Казан вә тирә-яктагы башка шәһәр вә авыллардагы хәзрәтләргә ошамады. Үзләре мөкаддәс санаган Кәлям китапларына мохаләфәт иткәне өчен, Мәрҗанине хәтта кяфер исеме белән исемләүчеләр дә булды.

2) Бөтен Русия мөселманнары кыска төннәрдә вакыт керми вә шул сәбәпле ястү намазы фарыз түгел дип бөтенләй укымыйлар иде. Мәрҗани Русия мөселманнарының бу эшләрен дә хилаф итеп күрсәтте. Мәшһүр «Назурәтел-хак» әсәрен язып, бу фикерен мәйданга чыгарды.

3) Мөселманнар арасында рузага керүдә, чыгуда вә башка бәйрәмнәр хакында төрле низагълар хәзер дә булып тора. Мәрҗани, Коръән, хәдис вә сәләфләр әсәрләреннән төрле дәлилләр китереп, хисапның дәлил булуы мәсьәләсен уртага куйды. Рузага керү һ.б. дини бәйрәмнәрне хисап белән йөртү тиешле булуын әйтте. Шул фикере белән гамәл кылганлыктан, аның указын да алдылар.

4) Мөселманнарның ничә гасырлардан бирле махсус китапларга, билгеле галимнәрнең фикере вә сүзләренә генә таянып, Коръән вә хәдистән хөкемнәр чыгару иске галимнәргә махсус

[1] Мохаләфәт итүчеләр – каршы килүчеләр.

[2] Игътикади – ышану, инануга караган.

бер эш, бу заманда иҗтиһад[1] дәрәҗәсенә ирешкән (Коръән вә хәдистән хөкем чыгарырлык) галимнәр йитешүе мөмкин түгел, дигән фикер мөселманнар башында бик нык йирләшкән иде. Мәрҗани бу мәсьәләгә дә кагылды. Иҗтиһад Тәңренең рәхмәте булып, берничә гасыр әһленә генә аны билгеләү шәригать вә гакылга хилаф булдыгын төрле дәлилләр белән уртага куйды.

5) Русиядә Мәрҗани дәверенә кадәрле басылган Коръән Кәрим нөсхәләре сәхабәләр вакытында язылган нөсхәләр рәсем (язу) җәһәтеннән тугры килеп бетми иде. Мәрҗани башлап (Мосхаф Госмани) хәзрәти Госман Коръәненә муафыйк итеп Коръән бастырды.

6) Мәрҗани заманында русча уку һәм музыка куллану хәрам саналып, халык русча укучыларга һәм музыка уйнаучыларга нәфрәт күзе белән карый иде. Мәрҗани халык нәфрәтләнгән бу ике эшкә дә яхшы күз белән карады. Хәтта русча укуны ваҗиб[2] дәрәҗәсендә күрде.

7) Бездә бу көнгә кадәрле дәрес тәртипләре, укыту ысуллары тәртипкә салынмаган, һичбер тәртипле мәдрәсәдә тәрбия күрмәгән олуг Мәрҗани безнең бу хасталыгыбызны да күрде. Башлап бу мәсьәләләрне безнең Мәрҗаниебез мәйданга куйды. Хәтта авылында укыган чагында ук моны кәшеф итте.[3] Бохарада вакытында ул моны бик ныклап тәнкыйть итәргә кереште.

8) Мәрҗани иске дәреслекне, хәтта авылында вакытында ук «Гыйльме хәл» вә «Гакаид» китапларын яратмады. Шуны күздә тотып, «Әлхикмәтүл бәлига»сен, гакыйдә вә намаз хакындагы ике рисаләсен тәэлиф итте.

9) Шиһаб хәзрәт заманасына кадәрле без «татар» сүзеннән җирәнә вә бу сүзгә мәсхәрә, мыскыл итү дип карый идек. Шиһаб хәзрәт бу сүзнең шәрәфле вә ифтихар ителәчәк бер сүз икәнен аңлатты. «Мөстәфадел-әхбар»ларын вә башка тарихи әсәрләрен язып, безгә үзебезне танытты. Мәрҗанинең бу хезмәте һәр эшеннән олуг вә мөкаддәстер.

---

[1] Иҗтиһад – мөстәкыйль хөкем чыгару.

[2] Ваҗиб – тиешле, бик кирәкле.

[3] Кәшеф итте – ачты, мәйданга чыгарды.

10) Мәрҗани мөселман мәдрәсәләрендә укыган шәкертләрнең киләчәкләрен кайгырту вә аларны эшкә кертү мәсьәләсен сөйләп караса да, ул бу эшен гамәлгә куеп җиткерә алмады.

Менә Мәрҗани гамәлгә куйган мәсьәләләрнең әсасы[1] шуннан гыйбарәт. Гали вә тәртипле мәдрәсәдә тәрбия күрмәгән Мәрҗанидә никадәр истигъдад[2] вә никадәр даһилык барлыгын укучылар үзләре шуннан аңласалар кирәк.

Бу Мәрҗани хакында шуны гына әйтә алабыз: ул гасырлар буенча бик сирәк йитешә торган ирләрнең берсе, олуг гаять хыяллы (фикерле) вә заманасының даһисы иде.

Без Мәрҗанине мәңге сагыначакбыз, ул безнең күңелләребездә милләт яшәдекчә яшәячәктер. Гали рухың шад булсын, әй Мәрҗани!..

*Закир Кадыйри*

*Мәкалә «Тормыш» газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар (162 нче сан); 11 гыйнвар (163 нче сан) саннарында басылган. Текст басмага газетадан алынды.*

*Тестны басма өчен Әнисә Алиева әзерләде*

## Мәрҗани юбилейсы

9 нчы гыйнварда җомга көн кич беренче мәсҗедтә мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләренең рухына дога кылу мәҗлесе булды. Ватан тынычсыз вакытта милли бәйрәмнәрне тантаналы ясау килешеп бетмәгәнгә, уфалылар Мәрҗани хәзрәтнең юбилейсын бик юаш кына ясадылар. Мәсҗедтә иң элек Шиһабеддин хәзрәтнең рухына Коръән хәтем ителде[3].

Моннан соң Җиһангир хәзрәт бер мокра[4] укыгач, аяк өстенә торып, бу кичәнең Мәрҗани хәзрәтләренә багышланганлыгы,

[1] Әсасы – нигезе.

[2] Истигъдад – сәламәтлек, зирәклек.

[3] Хәтем ителде – укылды.

[4] Мокра – «Ясин» сүрәсенең бер өлеше, Коръәннең утыздан бер өлешен тәшкил итә

андый бөекләрне зурлауның әһәмияте хакында нотык сөйләдек. Соңра гәзитәмезнең баш мөхәррире Закир әл-Кадыйри әфәнде, торып, Шиһаб хәзрәтнең Бохарадан Русиягә кайтканчы булган тәрҗемәи хәле белән халыкны таныштырды. Закир әфәнде Мәрҗанине Мәрҗани итеп дөньяга чыгарган сәбәпләрне бик нечкәләп, гыйльми сурәттә мөхакәмә итте[1]. Мондый даһиларның начар гаиләләрдән чыкмаганын, даһи йитештерү өчен дә тәрбиянең бик зур тәэсире барлыгын ачык итеп аңлатты. Шиһаб хәзрәтнең әткәсе вә әнкәсе, вә бабалары хакында һәм мәгълүмат бирде. Башта гыйлем чишмәсе булып та, Шиһаб хәзрәт баруга тәмам хәрәбә хәленә килгән, эштән чыккан Бохара вә Сәмәрканд мәдрәсәләреннән аның ни сурәттә гыйлем эзләгәнен, шул йирләрдә галим булып йитешкәннән соң үзенә нинди мәсләк[2] вә мәзһәб[3] билгеләгәнен сөйләде.

Русиягә кайтканнан соң чыгарган мөһим мәсьәләләреннән берничәсенең әһәмиятен бәйан итте. Бөтен мөселманнар схоластиканы үзләренә юлбашчы итеп тотканнары хәлдә, аның Коръән вә хәдис күтәреп мәйданга чыкканын, «Безнең юлбашчыбыз шушы ике нәрсә булырга тиеш» дип кычкырганын сөйләп, сүзен тәмам итте.

Хәсәнгата хәзрәт Мәрҗанинең Русиягә кайтканнан соңгы хәлен, ул вакыттагы голяманың Мәрҗанигә нинди күз белән караганын, аның мелла булганнан соң күргән мәшәкатьләрен сөйләде. Шулчаклы һөҗүмнәр арасында, һичнәрсәдән курыкмыйча, үз мәсләгендә армый-талмый хезмәт иткәнен бәйан итеп, сүзен тәмам итте. Мәрҗанинең әсәрләре вә чыгарган мәсләкләре хакында 10 нчы гыйнварда дүртенче мәсҗедтә җәмгыяте хәйрия тарафыннан ясала торган мәүлид[4] вә дога мәҗлесендә сөйләргә вәгъдә итте.

---

[1] Мөхакәмә итте – хөкем чыгарды, аңлатып бирде.

[2] Мәсләк – принцип.

[3] Мәзһәб – диндә, гыйлемдә, дөньяга карашта тоткан юл, юнәлеш.

[4] Мәүлид – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне бәйрәме (мөселманнарда Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көнен мәчетләрдә җыелып Коръән укып, пәйгамбәрләр тарихын, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы белән бәйле кыйссалар сөйләп, догалар кылып бәйрәм итү йоласы).

Җыелган халык хәзрәттән бик мәмнүн булдылар. Аңа рәхмәт укыдылар. Ахырда Җиһангир хәзрәт башта хәтем кыйлган Кәлям шәрифнең савабын багышлап мәҗлесне тәмам итте.

*«Мөхбир»*

*Мәкалә «Тормыш» газетасының 1915 елгы 11 гыйнвар (163 нче сан) санында басылган.*

*Тестны басма өчен Әнисә Алиева әзерләде*

## Мәүлид һәм Шиһаб хәзрәт кичәсе

10 нчы гыйнварда Җәмгыяте хәйрия идарәсе губернаторның рөхсәте белән 4 нче мәхәллә мәсҗедендә Мәүлид һәм Шиһаб хәзрәт кичәсе ясады. Кичәгә халык бик күп җыелган иде. Кирәк голяма вә зыялылардан, кирәк сәүдәгәрләр вә һөнәрчеләрдән килүче бик күп иде. Кичә гаять күңелле тәртип ителгән[1] иде. Хәтемнән соң[2] Сабир хәзрәт бик озын итеп рәсүлулланың тәрҗемәи хәлен сөйләде. Хәзрәти Һаҗәрнең җария булуы, рәсүлулланың хәзрәти Хәдичәгә яллануы хакындагы иске хикәятләрнең ялганлыгы турысында сөйләгән сүзләре халыкка ошады. Хәзрәт сүзгә оста һәм бик матур итеп сөйли. Фәкать хәзрәти рәсүлне тәкъдир итәрлек, аның эшләре белән халыкны якыннан таныштырып, халык алдында мәүлид шәрифнең кадерен күтәрерлек мөһим маддәләр хакында бер сүз дә булмады. Рәсүлулланың тәрҗемәи хәлен хикәя тарызында[3] гына сөйләп чыкты.

Салават шәриф вә гарәпчә мәүлид укылганнан соң, шәкертләр тарафыннан мәүлид вә бәйрәмгә гаид[4] күңелле шигырьләр укылды. Кичәнең бу кыйсеме гаять күңелле чыкты.

Хәсәнгата хәзрәт Мәрҗани җәнабләренең тәрҗемәи хәлен, эшләгән эшләрен һәм уртага куйган мәсьәләләрен бик кыска-

[1] Тәртип ителгән – төзелгән, оештырылган.

[2] Хәтемнән соң – Коръән укылганнан соң.

[3] Тарызында – рәвешендә.

[4] Гаид – караган, туры килә торган.

лык белән сөйләде. Вакыт азлык сәбәпле, казый хәзрәтнең хотбәсе[1] йомшаграк чыкты. Шиһаб хәзрәт кебек олуг бер даһиның тәрҗемәи хәле турында сөйләгән сүзләр аны тиешле кадәрле тәкъдир иттерерлек булып чыга алмады. Ахун Җиһангир хәзрәт хәтем кыйлынган Коръәнне Мәрҗани рухына багышлады. Хаҗиәхмәт хәзрәт бер нотык сөйләде. Һади хәзрәт, падишаһе әгъзам хәзрәтләренә дога кылып, мәҗлесне тәмам итте.

Халык кичәдән гаять мәмнүн[2] калды. Бүгенгә кадәр Уфада күрелмәгән бу эшне эшләве өчен, Җәмгыять идарәсенә күп рәхмәтләр укыдылар. Мәҗлес тәмам булганда, халыкның һәммәсе шат, бер-берсен көләч йөз белән тәбрик итәләр иде. Халыкның кичәдән ничаклы мәмнүн булганын күрсәтү өчен, мәҗлеснең сузылуына карамыйча, тәмам булганнан соң да мәҗлестән чыгасы килмичә, өелеп-өелеп, кичәне мактауларын әйтеп үтү йитсә кирәк.

*«Мөхбир»*

*Мәкалә «Тормыш» газетасының 1915 елгы 13 гыйнвар (164 нче сан) санында басылган.*

*Тесктны басма өчен Әнисә Алиева әзерләде*

## Шиһаб хәзрәт

Шиһаб хәзрәт зур бер дин галиме иде, заманасына күрә күп хезмәт күрсәткән мөәррих иде. Дин вә шәригать бабында бик күп яңа фикерләр сөйләгән вә язган бер «мөҗәддид»[3] иде. Шуның өстенә дә, милләт вә сәясәт мәсьәләләрендә иң могтәдил, хөкүмәт кашында бик ышанычлы бер кеше иде.

Менә шундый бер кешенең бу көннәрдә йөзьеллык юбилее булды. 9 нчы гыйнварда аның туганына һиҗри хисап берлә йөз ел тулган иде. Шул мөнәсәбәт берлә һәм матбугат, һәм аңлы голямамыз аны тәкъдир итәргә, хәтергә төшерергә күбдән хәзерләнәләр иде. Хосусан, Шиһаб хәзрәтнең туган, үскән,

---

[1] Хотбәсе – нотыгы, вәгазе.

[2] Мәмнүн – канәгать.

[3] Мөҗәддид – яңалык кертүче.

торган вә үлгән йире Казан иле булганлыкдан, Казан бу көнне каршы алырга үзенчә бигрәк дә хәзерләнә иде. Шиһаб хәзрәтне гаммәгә этрафлы рәвешдә танытыр өчен, аның тәрҗемәи хәле вә әсәрләре хакында йөзьеллык юбилеена тугры китереп зур бер мәҗмуга чыгару фикере мондан өч ел элек мәйданга чыкган иде. Шул фикерне фәгыйлэткә чыгарыр өчен, мәрхүмнең мөхлисләрендән һәм голямамездән бу хезмәтне башлаганлар иде. Бу мөхтәрәм затлар өч елдан артык бер мөддәт[1] буенча тырышдылар, эшләделәр, мәрхүмнең әсәрләрен күздән үткәрделәр, тәхкыйк кылдылар[2], тәрҗемәи хәленә гаид[3] кирәкле мәгълүматны җыйдылар.

Бездә фәнни җәмгыятьләр, иҗтимагый мөәссәсәләр[4] булмаганлыкдан, милли бер юбилее кебек бер тантаналы көнне хәзерләр вә ясар өчен махсус мәүкыйт[5] бер мөәссәсәкомиссия булмаганда башкача моны вөҗүдкә чыгару мөмкин түгел. Шиһаб хәзрәт юбилее өчен махсус комиссия ясалмады, моның артындан йөрүче, кирәкле рөхсәтен алып, шуның эшен күзәтүче нә бер шәхес, вә нә дә бер түгәрәк булмады. Көнләр үтде, юбилей көне якынлашкандан-якынлаша барды. Теге юбилей мәҗмугасын хәзерләүче мөхтәрәм затларның биззат[6] вазыйфалары шул «мәҗмуга»ны тәркиб итү кеби агыр хезмәт кенә булса да, аларның юбилей көненә вә аны ясау мәсьәләсенә һичбер төрле мөнәсәбәтләре булмаса да, алар нә рәсми җәһәтдән вә нә дә билфигыль[7] (фактически)[8] бер комиссия кеби нәрсә тәшкил итмәгән булсалар да, халык алардан бер нәрсә көтә, юбилей көненә лаек булган тантана вә лязем эшләрне алар бер тәртибкә салырлар, алар күрсәтерләр дип уйлый һәм агыздан агызга шулай сөйләнә иде.

---

[1] Мөддәт – вакыт.

[2] Тәхкыйк кылдылар – тикшерделәр.

[3] Гаид – кагылышлы, караган.

[4] Мөәссәсәләр – оешмалар.

[5] Мәүкыйт – срок, вакыт.

[6] Биззат – үз.

[7] Билфигыль – чынлыкта.

[8] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Юбилей җитәр алдыннан, хәлләр үзгәреп китте. Бөтен мәмләкәт, шул җөмләдән бөтен татар галәме эше, тормышы вә фикере берлә сугыш эшләре, аның чыгарган мәшәкатьләренә чумып китде. Шулай да булса, Шиһаб хәзрәт көнен бераз аерым-чарак үткәрү уе ташланмады. Халык Шиһаб хәзрәт көнен көтде.

Күп кешеләрнең фикеренчә, бу көндә әллә нинди бер тантана ясамаса да, мәсҗедләрдә дога кылу, каберенә җыелып барып коръән уку, аның шәрәфенә бер мәҗлес ясап, шунда аны искә төшерү лязем иде. Хосусан, әлеге мәҗмуга бу көнгә өлгертелеп сатыла башларга кирәк иде.

Бәгъзе кешеләр шул көнне мәрхүмнең үзе утыз-кырык ел намаз укыган мәсҗеденә җыелып, шунда җәмәгате кәбир булып намаз укырга һәм рухына дога кылырга дигән фикерне тәклиф иткәнләр иде. Әгәр бу фикер була калса, юбилее җомга көнгә тугры килгәнлекдән, мәсҗеддә халык гаять күп булачак, мәрхүмнең рухына кылынган дога да ничә вә ничә мең мөселман иштиракь итәчәк вә, шулай итеп, мәрхүмнең рухы никадәр мәсгуд булачак вә бөтен Казан халкына бу көн аерым бер көн булып танылып калачак иде. Шулай ук «мәҗмуга» өлгертелеп китап базарына чыгарылса, шул мөнәсәбәт берлә никадәр кеше бу китапны алачак вә никадәр гади халык Шиһаб хәзрәтне танып калачак иде. Әһле булган кешеләр аз гына мәтанәт[1] вә тәвәккәллек күрсәтеп, тиешле рөхсәтен алып, бер рәсми мәҗлес ясасалар, ничаклы матур бер нәрсә булачак иде. Бу мәҗлесдә Шиһаб хәзрәт һәм дини галим, һәм мөәррих булуы җәһәтендән ачык танылып калачак иде.

Ләкин, мәгаттәәссеф[2], боларның берсе дә булмады. Каберенә җыелып барып дога кылудан голямаларымыз имтинаг итделәр[3], әллә нинди бер шик-шөбһә чыгып китмәсен дип курыкдылар. Шуның өчен кабер зиярәте һичбер тантанасыз үтде, әрәм-сәрәм берничә кеше барып Коръән укыдылар, шуның берлә тәмам булды. Үзенең мәсҗеденә җыелып дога кылу мәрасиме дә бул-

---

[1] Мәтанәт – ныклылык.

[2] Мәгаттәәссеф – кызганычка каршы.

[3] Имтинаг итделәр – баш тарттылар.

мады, чөнки мәрхүмнең кияве Сафый хәзрәт[1] моңар каршы килде, полициядән рөхсәтсез мин булдыра алмыйм, диде. Мәсҗеддә җыелып намаз укырга, дога кылырга рөхсәт кирәк имеш! Монда сүзне Казан мөселманлары дөнья яратылганлы бирле ишеткәнләре юк иде. Шиһаб хәзрәт хөрмәтенә мөхтәрәм Сафый мулладан ишетделәр!

Рәсми кечерәк кенә гыйльми бер мәҗлес ясар өчен дә рөхсәт сорарга җөрьәт итүче булмады. Һәркем «Йә шәхси!» диде, үз күләгәсендән үзе курыкды.

Мәҗмугане дә юбилее көненә өлгертә алмадылар, өч ел тырышкан, эшләгән мөхтәрәм затлар – шул 9 нчы гыйнвар көненә өч ел хәзерләнгән әфәнделәр, ни сәбәбдәндер, иң кирәкле бер вакытка соңга калдылар. Мәҗмуга бер айдан соң өлгерәчәк, имеш; соң, аз гына артыграк һиммәт вә иҗтиһад сарыф итеп, бер ай элек өлгертергә мөмкин түгел идемени?! Бу кичектерү аңлашылмаслык вә үзенә күрә кызганыч бер җәбинлек[2] кенә диелмәсә, башкача бер төрле сәбәб табып булмый.

Шулай инде, «кара сакалың кайда барсаң да калмай» диләр. Безгә кеше төсле, адәм рәтле итдереп бер эш кылырга, милли вә иҗтимагый барлыгымызны күрсәтергә насыйп түгел, күрәсең!

Казанда Шиһаб хәзрәт көненең тәәссефле[3] тарафлары булган кеби, күңелле нокталары да булды. Казанның күп мәсҗедләрендә җомгадан соң мәрхүмнең рухы шадлыгына догалар кылынды. (Кышкарый муллалар бу доганы кылдырмаганлар, имеш. Үзләренә күрә Шиһаб хәзрәткә мөхалиф[4] партиядәге кешеләр, имеш!). Казан газеталары Мәрҗани хакында язылган мәкаләләр вә Мәрҗанинең рәсемләре берлә тулып чыкдылар.

Шиһаб хәзрәтнең мәхдүме Борһан хәзрәт шул көн кич үз ханәсендә Казанның гыйльман вә могтабәрәнен чакырып, хәтем мәҗлесе ясады. Мәҗлесдә мәрхүмнең рухына Коръән хәтем итеп дога кылынгандан соң, аш янында һәр табында

[1] Сафый хәзрәт – Сафиулла Абдуллин (1849–1927), Ш. Мәрҗанинең кияве.

[2] Җәбинлек – куркаклык.

[3] Тәәссефле – кызганыч.

[4] Мөхалиф – каршы.

Мәрҗани хакында махсус мөкяләмәләр[1] булды. Көндезен мәрхүмнең зиярәтенә барырга курыкган, голяма мәсҗедендә җәмәгате кәбир булып дога кылдырырга җөрьәт итә (!)[2] алмаган Сафый мулла кебек кешеләр дә бар иде. Бу «мөхтәрәм» затлар зиярәт итәргә, мәсҗеддә дога кылырга курыксалар да, аш ашарга килгәнләр, аңар җөрьәтлелекләре җиткән иде. Бу мәҗлеснең иң шаян игътибар булган бер ноктасы – Мәрҗанинең «Вафиятел-әсляф»ын басдырырга карар бирелүдер. Бу тарихи әсәр әлегә кадәр нашир табылмаганлыкдан басылмый тора иде. Мәҗлесдәге халыкның бәгъзеләре, бу юбилей көне, гәрчә кирәгенчә үткәрелә алмаса да, шул вакытны форсат белеп, Мәрҗанинең иң зур вә иң кадерле бер әсәрен матбугат галәменә чыгарып калдырасы иде, диеп үзара сөйләшкәндән соң, бу фикерне фигълияткә чыгаруны мәрхүмнең варислары Борһан хәзрәт[3] вә Габдулла хәзрәтләрдән[4] үтенделәр, боларга әсәрне тәнкыйд вә нәшер мәсьәләләрендә ярдәм итешер өчен Галимҗан хәзрәткә мөрәҗәгать итделәр. Китап берничә җилдле булып, байтак кыйммәткә төшүе өстенә, гарәб телендә булганлыкдан таралуы да күп булмас төсле булганга, нәшер хөраҗәте сатылган нөсхәләре берлә генә кайтарылып бетүе агырракдыр. Затән[5], бу китапка әлегә кадәр нашир табыла алмавы да шул сәбәпдән иде. Мәҗлесдәге бәгъзе кешеләр бу ноктаны игътибарга алып, нәшер өчен мадди ярдәм кылырга вәгъдә итделәр.

Димәк, «Вафиятел-әсляф» берничә вакытдан соң матбугатка чыгачак вә гаммәнең моталәгасенә куелачакдыр.

Менә бу эш өчен мәрхүмнең рухы никадәр шадлангандыр инде. Затән, Шиһаб хәзрәт көненең иң матур, иң файдалы ноктасы да шул «Вафиятел-әсляф» нәшеренә карар бирелүдер.

Кем белә, бәлки бу карар карар көенчә генә калыр, безнең әлегә кадәр дә бик күп карарларымыз булды бит инде. Алар

---

[1] Мөкяләмәләр – сөйләшүләр.

[2] (!) мәкаләдә бирелә.

[3] Борһан хәзрәт – Ш. Мәрҗанинең улы.

[4] Габдулла хәзрәт – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, нашир Габдулла Апанаев (1862–1919).

[5] Затән – нигездә.

һәммәсе әлегә кадәр шул «карар» дәверендән чыга алмыйлар бит әле.

Һәр нә исә, шул кадәресенә генә дә шадланырга кирәк инде. Гыйльми вә тарихи кыйммәте булган бер әсәрне өч-дүрт мең сум гына расход тотып нәшер итәрлек бер җәмгыяте-гыйльмиясе, бер һиммәтле бае булмаган бичара милләт, куан, шадлан, йөз еллык бер юбилей мөнәсәбәте берлә синең файдаңа өч-дүрт мең сум акча сарыф кылырга «карар» бирелде!

Газиз төнләреңне йокламыйча үткәреп, ничә еллар күз нурларыңны түгеп, милләткә зур бер әсәр язган бичара Шиһаб хәзрәт! Шадлан, куан. Егерме биш елдан бирле кабереңдә көтеп яткан бер теләгең мәйданга чыгарга якынлашды, бу көн милләт синең зарыңны, тавышыңны ишетде.

Бичара милләт, бәхетсез Шиһаб хәзрәт!

*Мәхмүдфуад*

*Мәкалә сәяси эшлекле, публицист Мәхмүдфуад Туктаров (1880–1938) тарафыннан язылып, 1915 елның 14 гыйнварында «Ил» газетасында басылып чыга.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

## Шиһаб хәзрәт юбилее

Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең йөзьеллык юбилеен аның бөек рухына муафикъ ясау хәтерләргә килсә дә, бердән, үземезнең хәзерлегемез сыйдырмаганга, икенчедән, хәзергә гадәтдән тыш хәлләр йөрәкләремезне башка мәсьәләләр белән дулкынландырганга күрә, юбилей кичелдерелергә булды.

Юбилейның кичелдерелүендә иттифак ителгән кебек булса да, Казан гәзитләре Шиһаб хәзрәткә багышлап махсус номер чыгардылар, мәсҗедләрдә Шиһаб хәзрәтнең рухына догалар кылынды, мәдрәсәләрдә Коръән тутырылды, кайбер урынларда аның тәрҗемәи хәленә даир лекцияләр укылды.

Мөфтиемез тарафыннан бу хосусда имамларга берәр ихтар[1] булмаса да, Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан вә башка шәһәр-

[1] Ихтар – искә төшерү, искәртү.

ләрнең кадер белгән затлары мәсҗедләрдә Шиһаб хәзрәтне искә төшерделәр.

Себердә, Төркестанда да шул рәвешдә искә төшерелгәндер дип ышанамыз.

Бөек затларымызны берәр мөнәсәбәт белән шулай яд итә тормак истикъбалемез өчен зур хәзерлекдер. Киләчәкдә шундый зур адәмләр йитешдерү өчен тиешле эшдер.

Без дә 2 нче гыйнвар нөсхәмездә Шиһаб хәзрәтнең рухына бер мәкалә багышлап, аны искә төшергән идек.

Былтыр Шиһаб хәзрәтнең вафатына егерме биш ел тулу мөнәсәбәте белән кузгатылган юбилей мәсьәләсендә Казан гәзитәләре Мәрҗанинең йөз елын 2 нче гыйнвардә тутырачаклар иде. Быел гыйнвар 9, рабигыль-әүвәл 7 сендә тутырдылар.

Казанда гыйнварның 9ы, рабигыль-әүвәлнең 7 сенә, Оренбургда 6 сына, Уфада 5 енә, Әстерханда 4 енә туры килеп торган вакытда без, Шиһаб хәзрәтнең туган көнен туры хисаплый алмаячагымыз кебек, пәйгамбәремезнең дөньяга килүен дә билгели алмаячакмыз. Хисап вә башка риязый фәнләрдә мәгълүматлары кәсер гадидән[1] уза алмаган, бинаән галәйһи[2] осуле тәварихе-хронология[3]не аст-өст китерә торган Казан календарьчыларына караганда, һиҗри вә милади елларны саташдырып, кулланып күп тәҗрибә күргән хөрмәтле Риза хәзрәт[4] «Шура»ның 1 нче номерында Шиһаб хәзрәт тәрҗемәсенә даир язган мәкаләсендә шул рәвешдә хисап йөретә вә зарланадыр:

«Шиһаб хәзрәт туган 1233 нче һиҗри елның рабигыль-әүвәл башы 1817 ел, декабрь 27 нче җомга көнгә, Мәрҗани туган рабигыль-әүвәл 7се 2 нче гыйнвар мөсадиф булганлыкдан[5], хакыйкать хәлдә, Шиһабеддин хәзрәт 7 нче рабигыль-әүвәл 1818 ел 2 нче гыйнварда пәнҗешәмбе кичәсендә дөньяга килгән буладыр... Ләкин без үземез тарих һиҗрине күп еллар истигъмаль

[1] Кәсер гадидән – гади вакланмадан.

[2] Бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[3] Кирилл хәрефләре белән.

[4] Риза хәзрәт – мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддин (1859–1936).

[5] Мөсадиф – туры килүче.

итеп карадык. Моның берлә мөгамәлә итү вә тарихи вакыйгаларны забыт кылу[1] бик мөшкел булды, үзенең дустына: «Әгәр дә бу ел февраль 29дан килсә, мартның беренче көнендә, әгәр дә 30дан килсә, 30 нчы февральдә безнең мәҗлесемезгә тәшриф итүеңезне үтенәмез» дип язучы карт хәлифә кабилендән һәрнәрсәне «әгәр»ләр берлә истигъмаль итү яки тарих һиҗри берлә янәшә милади айларны вә елларны истигъмаль итә башладык. Христиан дөньясында моктәдир[2], дин вә милләт шәрәфне хафиз кылырлык хәмиятле руханилар заһир булдылар вә монлар үзләренең тарих вә хисабларыны дөрестләделәр. Шул кабилдән тарих һиҗри һәм бик дөрест истигъмаль кылыну – кабил бер тарихдыр. Анда гаеп юк, гаеп исә шуны истигъмаль итә белмәүче, аз гына бәһанәләр[3] берлә һәмишә бозып торучы үземездәдер. Һәрхәлдә, Мәрҗанинең дөньяга килү көне гыйнварның 2 се вә рабигыль-әүвәлнең 7 седер».

Һиҗри тарихны «әгъмале әрбәгаче»ләр кулыннан алып дөрестләү, көннең берендә пәйгамбәремезнең туган көнен ихтиляфка[4] калдырмау – Духовное собраниемезнең вазыйфасыдыр.

*Мәкалә 1915 елның 14 гыйнварында «Ил» газетасының 61 нче санында басылып чыга.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

## Бөек остаз вә углымыз Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең йөзьеллык бәйрәме

Бондан йөз ел элек татар дөньясының иң мәзлум[5] бер дәверендә караңгы төндә пәйда булган якты йолдыз кеби, бу көндә кәмаль хөрмәт вә тәгъзыйм[6] илә исемен яд итдекемез[7] Мәрҗани җәнабләре дөньяга килмешләрдер.

[1] Забыт кылу – язу.
[2] Моктәдир – көчле.
[3] Бәһанә – сәбәп, сылтау.
[4] Ихтиляфка – каршылыкка, фикер башкалыгына.
[5] Мәзлум – изелгән.
[6] Тәгъзыйм – олылау.
[7] Яд итдекемез – искә алуыбыз.

Мәрҗани җәнабләре табигатьнең татар балаларына бик сирәк ихсан иткән[1] нәмунәләрендән берседер.

Татар дөньясының ул гасырдагы наданлыгына нисбәтән, аның кәмале лаекы илә тәкъдир ителә алынмаячагы бер заманда, бөйлә ул гакыл вә дираяте[2] илә әһле бәсыйрәтнең дикъкатен үзенә җәлеб итмешдер.

Мәрҗани җәнабләре – мөселман дөньясында унөченче гасыр һиҗринең иң бөек мөтәфәккирләрендән[3] иде.

Әүвәл башлап татар хәяте диниясенә урнашкан начар игътикадларга каршы сугыш ачды, үзенең үткен фикере кәнагатьләнмәгән һәрбер мәсьәләи динияне тәнкыйд итде, аның хакыйкать сөюче нык гакылы үзе ышанмаган һәр мәсьәләгә игътираз итде[4].

Аның, дустларындан бигрәк, дошманлары күб иде. Бу исә – аның башкалардан мөмтазлыгына вә аның голүвиятенә[5] үзе бер дәлилдер.

Мәрҗани җәнабләре дин вә хакыйкатьне һәрнәрсәдән гали күреб, шул юлда фидаи улдыгы хәлдә, динне дөрест аңлаудан гаҗиз калган гасырдашлары аны тәкфир итделәр. Ләкин ул хакыйкатьне сөйләүдән курыкмады, дошманларның шәхсиянә һөҗүмләренә әһәмият бирмәде.

Мәрҗани җәнабләре Бохарада тәхсил итде.[6] Ләкин, башка бохариларның хөррият вә тәгаҗҗебенә[7] каршы, ул андагы дәресләрдән мәмнүн булмады, дәрес түгәрәкләрендән качды, мәшһүр көтебханәләргә гизләнеб, күп вакытда ялгыз башына мәгълүмат кәсеп итәр булды.

Мәрҗани җәнабләре кырык ел кадәр имамәт вә мөдәррислек итмешдер.

Күб мөдәррисләр гакыл вә фикерләрен истигъмаль итә бармадыкларындан, китабларына бәйләнеп калып, зур хезмәтләр күрсәтә алмадыклары хәлдә, Мәрҗани хәзрәтләре һәм дәрес

[1] Ихсан иткән – ярдәм иткән.

[2] Дираяте – зирәклеге.

[3] Мөтәфәккирләрендән – фикер ияләреннән.

[4] Игътираз итде – каршы килде.

[5] Голүвиятенә – олылыгына.

[6] Тәхсил итде – гыйлем алды.

[7] Тәгаҗҗебенә – гаҗәпләнүенә.

әйтде, һәм дә унбиш җилд кадәр төрки вә гарәби әл-гыйбарә әсәрләр тәэлиф итде[1], ки болардан «Мөстәфадел-әхбар» исемле төркичә тарих китабы бөтен тарихи, милли язучыларымызга бер нигез булмышдыр. Бәгъзе бер гарәб әсәрләре хәтта урду теленә тәрҗемә кылынып, заманасында шактый җулан (?) әфкяргә сәбәб булмышдыр.

Шулкадәр гайрәт вә икъдам сахибе[2] булган Мәрҗани хәзрәтләре үзенең дәрәҗәи зиһен вә кувәи гаклиясенә[3] мөнасиб монтазам[4] бер тәхсил күрмеш ула иделәр, шөбһәсез, ислам галәмендә генә түгел, бәлки Яурупа галәмендә дә иң беренче галимләрдән, пантеонләрдә генә мәдфүн булырга истихкаклы[5] даһиләрдән мәгъдүд[6] булырлар иде.

И пир мөхтәрәм! Татар милләте сиңа интисабы[7] илә никадәр ифтихар итсә[8], никадәр мәдхияләр язса да, кинә аздыр.

Җәнабе хак ул мөбарәк мәркадеңне[9] нурларга, чәчәкләргә гарикъ әйләсен[10]!

*Мәкалә «Аң» газетасының 1915 елгы 1 нче санында басылып чыккан.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

---

[1] Тәэлиф итде – язды.
[2] Икъдам сахибе – тырышлык куючы.
[3] Кувәи гаклиясенә – акыл көченә.
[4] Монтазам – рәтле.
[5] Истихкаклы – лаек.
[6] Мәгъдүд – саналучы.
[7] Интисабы – мөнәсәбәте, бәйләнеше.
[8] Ифтихар итсә – горурланса.
[9] Мәркадеңне – гүреңне.
[10] Гарикъ әйләсен – күмсен.

## Шиһабеддин әл-Мәрҗани

Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗанинең бабалары Казан якынында Мәрҗан[1] исемле карьядәндер.

Атасы Баһаведдин хәзрәт шул якда Ябынчы исемле карьягә һиҗри 1232 елда имам булган вә шул ел Ашыт карьясенең имамы Габденнасыйр хәзрәтнең Хәбибә исемле кызына никахланган. Бер елдан соңра һиҗри 1233 нче ел 7 нче рабигыль-әүвәлдә (милади 1818, гыйнвар 3дә) безнең Мәрҗани туган. Мәрҗани дүртенче яшендә вакытда Баһаведдин хәзрәтне Ташкичү[2] карьясенә мөдәррислекгә чакырдыкларыннан, шул карьягә күчкәннәр.

Безнең яшь Мәрҗаниемез бу вакытларыны азрак хәтерендә тота икән. Ул бервакыт: «Без Ташкичүгә күчеп барганда, мине кабыклы көймәгә ултыртканлар, сыерны бер чанага салып барганлар иде. Мин шул вакыт, сыер да атка ултыра икән, дип гаҗәпләнеп барганым хәтеремдә калган», – дип сөйләгән.

Алар Ташкичүгә күчеп бер ел торгач (1238–1822 сәнәдә), Мәрҗанинең анасы вафат булган. Мәрҗани анасы хакында улан хатирәсе турында ошбу сүзләрне яза: «Мин, бервакыт су янында йөргәндә, мәче баласы берлә уйнап йөри идем. Шулвакыт, әнкәң чакыра дип, мине өйгә алып кайтдылар. Ул вакытда әнкәм авыру иде. Янына баргач, кайгылы вә мәрхәмәтле булган күзләре берлә бераз өстемә карап торды. Соңра күзләрендән яшьләрен агызып: «И балам! Миндән соңра анаң кем булыр? Кемгә әнкәй дип әйтерсең? Өст-башыңны кем карар? Кем тәрбия кылыр?» – диде. Шундан соңра озак тормай анам вафат булды. Бер шәкерд мине анамның җеназасы артыннан күтәреп барды, анам хакында шундан башка нәрсә хәтеремдә калмаган. Анам дөрест язу яза белә, яхшы хатын иде. Анам язган бәгъзе догаларны көтебханәмдә әле дә саклыйм», – ди.

Мәрҗани 6–7 яшьләрендә, атасының мәдрәсәсенә йөреп, хәлфәләрдән сабак укый башлаган. Мәрҗани мәдрәсәгә бик күңелле йөргән. Сабакларны бик яхшы укыган. Бигрәк дә яшь

---

[1] Мәрҗан – хәзерге Татарстан Республикасы Әтнә районындагы авыл.

[2] Ташкичү – хәзерге Татарстан Республикасы Арча районына кергән авыл.

ана кулында булуы йортда яшь анасының балаларын карарга, йорт эшләре эшләргә тугры килү Мәрҗанигә бер дә охшамаган. Ул, аз гына форсат табды исә, мәдрәсәгә укырга китә, күб вакыт шунда куна булган. Мәрҗанинең хәлфәләре вә шәрикләре арасында бик тиз үткенлек исеме чыгып, дәресләре бик тиз тәрәкъкый иткән. Тукыз-ун яшьләрендә гарәбчә нәхү, сарыф дәресләре, ундүрт-унбиш яшьләрендә мәдрәсәнең иң зур дәресләрен укый, үзендән түбәнләргә сабак үгрәтә башлаган. Уналты яшьләрендә мәдрәсәдә хәлфәлек дә итә башлап, шунда 4–5 ел кадәр укыткан. Һәрвакытда Мәрҗани атасының һәм бабасының көтебханәсендә булган бик күп китабларны алып укый, һәрнәрсәне төбе-асылы берлә белергә тырыша, ишеткән нәрсәләрен язып куя булган. Шунлыкдан хәлфә була башлаганда байтак китаб укыган, яхшы гына фикере ачылган, һәрнәрсәгә үз үлчәве вә интикад илә карый башлаган.

Тәрҗемәи хәлен вә рухын тәдкыйк итдекдә күренәдер ки, безем Мәрҗанидә даһиларда булырга тиешле сыйфатлардан башлап, интикад, мовазәнә[1], фикердә истикъляль куәсе күренә башлаган. Хәтта аның беренче хатирәсендә үк сыерны чанага салып баруны интикад иткәне күренә. Моның өстенә, Мәрҗанидә тәрәкъкый ичүн иң лязем булган яңа фикерләрне уйлап табу, ихтираг[2] куәсе дә булган, ул карья балалары вә шәгердләр берлә уйнаганда, ул вакытдагы уенларны яратмаенча, халык арасында булмаган үзенә бер төрле уенлар уйлап чыгарып, шуның берлә уйнауны ярата булган.

Мәрҗанидә интикад вә мовазәнә рухы аның табигатендә үк булганлыкдан, бик тиз тәрәкъкый иткән булырга охшый. Ул яше 12–13 яшьлек шәкерд вакытында һәрнәрсәне, хәтта гыйльми мәсьәләләрне үзенчә үлчәргә, үзенчә мөхакәмә итәргә тотына, бу тугрыда атасы илә байтак мөназарәләр кылыша башлый, атасындан берәр шәргый мәсьәлә ишетсә, ул ник алай дип, хикмәтләрен сораша булган. 15–16 яшьләренә йитдекдә, Мәрҗанидә булган интикад дәхи арта, ул, атасының мәдрәсәсендә укылган китабларны, дәресләрне ничек укытырга кирәклек хосусында

[1] Мовазәнә – тигез күрү.

[2] Ихтираг – уйлап табу.

үзенә күрә уйланып, үзенә бер план кора. Бер-ике ел хәлфә булып торгандан соңра, үзе уйлаган тәртиб берлә укытып карамакчы була. Шулвакытда гыйльме хәл китабларының гарәпчә булуын яратмаенча, татарча гыйльме хәл китаблары кирәксенә һәм үзе укыган гарәпчә китаблардан тәрҗемә итеп, татарча бер гыйльме хәл рисаләсе яза вә шул китабны яздырып укыта башлыйдыр. Һәм гарәб теленең сарыфын фарсы китабдан укытуны интикад итеб[1], үзе бер сарыф китабы язып, шәкердләрдән шул китабдан укыта башлаган. Мәрҗанинең мөәррих булачагы да яшь вакытында ук белүне башлаган иде дип риваять итәләр. Ул, ата вә бабасының көтебханәләрендән төрле китаблар алып укый башлагач, ата-бабаларындан һәртөрле китабларның мөәллифләре хакында сораша, бу китапны кем язган, ул ниндәен кеше булган дип тәфтиш итә булган. Бервакыт, борадәрләрен ияртеп, үзләренә якын бер зиярәтдә булган кабер ташларын укып йөргән. 19 яшьләрендә вакытында анасы кабере өстенә үзе бер таш язып куйган.

Мәрҗани 21 нче яшендә (1254 һ. –1838 м. сәнәдә) ул вакытда татарлар арасында гыйлем мәркәзе саналган Бохарага сәфәр иткән. Юлда барганда очраган һәммә карья вә шәһәрләрне, кайдан-кая барганларын, юлда ниндәен сулар аркылы йөргәнләрен – һәммәсен махсус бер кәгазьгә яза барган. Ул үзе шәгердләренә дә: «Мин җәгърафияне Бохарага барганда үгрәндем», – дип сөйли икән.

Мәрҗани Бохара юлында йиде ай кадәр вакыт үткәргән. Байтак вакытлар Троицки каласында туктап торганлар. Ул шул вакытда Троицкидан вак-төяк төрле нәрсәләр сатып алып, казакъ, кыргыз араларында сату итеп дә йөргән. Шулай итеп, бераз акча табып, Бохарага баргач, «хәлифә Ниязколый» мәдрәсәсендән үзенә бер хөжрә[2] сатып алып тора вә дәресләргә дәвам итә башлаган.

Ләкин гыйлемгә сусап, бик күп нәрсәләр уйлап барган Мәрҗанигә Бохара мәдрәсәләренең дәресләре бер дә охшамаганлар. Ул Бохара мәдрәсәләренең дәресләрендән бер дә ләз-

[1] Интикад итеп – риза булмыйча, тәнкыйть итеп.

[2] Хөжрә – бүлмә.

зәтләнмәгән. Мәдрәсәләрдә кирәксез шәрех вә хашияләр берлә гомер үткәрү аның табигатенә бер дә ошамаган. Ул шундан соң үз-үзендән укырга керешкән. Бохараның гомуми вә хосусый көтебханәләренә йөреп, тузан, пәрәвез арасында һичкемдән илтифат күрмичә яткан китабларны актарырга, шунлар аркылы гыйлем артдырырга керешкән. Шул рәвешчә көтебханәләргә йөреп, бик күп гыйлем хасил иткән, бик күп газиз вә нәфис китабларны моталәгә иткән.

Мәрҗани Бохарада торган вакытларында мәгыйшәт җәһәтендән бик күп агырлыкларга очраган. Атасы үзе дә бер төрле генә булдыгындан углына йитәрлек нәрсә йибәреп тора алмаган. Мәрҗани үзенең мәгыйшәтен үзе тәэмин итәргә мәҗбүр булган, шунлыкдан яз көнләрендә тәгтыйль[1] вакытларда төрекмән, сарт арасында мөгаллим булып акча таба, кыш көнләрендә шул акча берлә дәрес укый һәм, хосусый дәресләр укытып, шуның белә акча хасил итә булган. Бохарада фәкыйрьрәк булып мәгыйшәт итдегендән, нә кадәр гыйлем вә китабга ихласлы булса да, үзенә зарур булган китабларны җыя алмаган. Кирәк китабларны үзе күчереп алырга, кирәк нәрсәләрне махсус мәҗмугаларга язып барырга мәҗбүр булган.

Мәрҗанинең фәкыйрьлегенә бәгъзе мөдәррисләрнең дә сәбәблеге булган. «Дәресләргә дәвам итми» дип, мөстәхикъ[2] шәкердләргә бирелә торган вәкыф акчадан Мәрҗанигә бирдермәгәнләр.

Бохарада биш ел кадәр торгач, шул тарафның икенче гыйлем мәркәзе саналган Сәмәркандка сәфәр иткән, анда казый Әбү Сәгыйд исемле, тугры фикерле зур бер галимгә юлыккан. Казый, Мәрҗанидә булган истигдад, гыйлемгә мәхәббәтне күреп, аңа бик яхшы илтифат иткән. Мәрҗанине үз балаларына хосусый мөгаллимлеккә чакырган. Үзенең бик бай булган көтебханәсен Мәрҗани ихтыярына табшырган. Мәрҗани ошбу казыйның хосусый мәҗлесләрендән вә фикерләрендән бик күп истифадә иткән. Бик күп гыйлем артдырган. Мәрҗани үзе дә: «Сәмәркандда тордыкда казый Әбү Сәгыйд көтебханәсендән

[1] Тәгтыйль – ял, каникул.

[2] Мөстәхикъ – хаклы.

бик күп истифадә итдем. Бик күп нәфис вә кадерле китаблар күреп, күп нәрсә күчереп алдым. Тарих илә мәшгуль булуыма, тарих китаблары моталәга итәргә башлавыма баш сәбәб ошбу казый Әбү Сәгыйд булды», – дип яза.

Сәмәркандда ике ел кадәр тордыкдан соңра янәдән Бохарага кайткан һәм, әүвәлге мәсләгендә дәвам итеп, һичкемгә катнашмасдан бөтен вакытларын моталәга һәм язу илә үткәргән. Бохарада торучы татар шәгердләрендән бернәкадәр кешене җыеп, үзе уйлаган программа илә дәресләр укыткан. Шул вакытда Бохара халкының кешеләрен, осуле тәгълим вә дәрес җәдвәлләрен интикад итеп, «Игъляме ибна-ид-дәһр би әхвали әһли Мавәраэннәһер» исемле бер рисалә язган. Тарих, игътикад хакында тәэлиф итәргә уйлаган китаблары хакында бик күп мәгълүмат (материал) җыйган. Шул вакытда бәгъзе тәэлифләрен вөҗүдгә китергән.

Бохара вә Сәмәркандда унбер ел кадәр торгач (1265 һ. – 1849 м. сәнәдә), Казанга кайткан. Бу вакытда Казанның беренче мәхәлләсенең имамсыз вакыты булган. Мәрҗани шул мәхәлләдә кырык ел кадәр имам булып торды.

Имам булгач, мәдрәсәне ислахга ижтиһад итеп, Бохара ысулына хилаф булган үзенә бер яңа ысул берлә укыта башлаган. Әүвәлге елларда мәдрәсәсе бик яхшы тәрәкъкый иткән. Ләкин Мәрҗанинең игътикад, гыйбадәт, осуле тәгълим мәсьәләләрендә халкымызның кәйдәшләрен[1] интикад итүе, муллалар мәҗлесендә булган каты-каты сүзләре, ачы хакыйкатьләре байтак кешеләрнең кәефләрен бозды. Шундан соң зарарлы кеше итеп күрсәтә башладылар, ике мәртәбә имамәтдән газел итеп[2] тордылар, һәм мәдрәсәдә укытудан туктатдылар. Байтак вакытлар мәдрәсәсе уртача гына булып дәвам итде. Фәкать соң вакытларында гына яхшы юлга куела алды. Шул вакытларда күбрәк вакытларын төрле китаблар тәэлиф итеп үткәрде. Иң файдалы әсәрләрен ошбу вакытда язды. Аның әсәрләре татарлар арасында гына түгел, ислам мәмләкәтләренә дә таралды, һәм татарлар голямасы арасындан беренче мәртәбә танылган кеше

[1] Кәйдәшләрен – хәйләкәр, мәкерлеләрен.

[2] Газел итеп – чыгарып.

Мәрҗани хәзрәтләре булды. 1868 елда губернский ахунд вә мөхтәсиб булып тәгъйин ителде[1]. Ахунд вакытында муллалар кәйдешендә халкымызның дини эшләрендә байтак исляхлар ясарга тырышды. Духовный собраниягә берничә төрле ляихәләр хәзерләп йибәрде.

1862 елда Казанда Учительская школа ачылгач, шунда дин мөгаллимлегенә чакырылды. Вә шул хезмәтендә тукыз ел кадәр торды. Школаның әһле ислам ичүн файдалы рәвешдә юлга салынуына байтак иҗтиһад сарыф итде.

1880 елда хаҗга барып кайтды. Ислам мәмләкәте илә якындан танышды.

Ахунд вакытында Казандагы мөстәшрикъләр илә дә катнашды. Асаре гатика[2] җәмгыятьләренә әһәмият биреп, байтак мәҗлесләренә дәвам итде. Шул васита илә аның гыйльми вә тарихи хезмәтләре Аурупа галәменә дә мөнгакис булып[3], 1874 елда аның тәрҗемәи хәлләре вә әсәрләре хакында мәгълүмат сорап, Лондондагы бер ширкәт тарафындан мөрәҗәгать ителде. Аларга җавап уларак, үзе хакында гарәпчә бер кыска гына рисалә язып йибәрде.

Мәрҗани хәзрәтләре (1306 сәнә шәгъбан 28 дә – 1889, апрель 18 дә) вафат булды. Аллаһның рәхмәтендә булсын.[4]

*Ш. Шәрәф*

*Мәкалә күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәһәр Шәрәф (1879–1938) тарафыннан язылып, «Аң» журналының 1915 елгы 1 нче санында басылган.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

[1] Тәгъйин ителде – билгеләнде.

[2] Асаре гатика – борынгы әйберләр.

[3] Мөнгакис булып – *монда*: билгеле булып.

[4] Мәрҗани хәзрәтләренең хезмәтләре гаять олуг. Аның тәрҗемәи хәлендә гыйбрәт алырлык, гыйлем вә фикер артдырырлык нәрсәләр бик күбдер. Бу кыска мәкалә илә генә аның хакында йитешле булган мәгълүматны биреп булмый. Бу көндә «Мәрҗани» исемендә 640 битле зур бер мәҗмуга басылып тәмам булды. Тәфсыйлән, аңлау өчен шул мәҗмуганы укырга кирәк (Ш. Шәрәф искәрмәсе).

## Шиһаб хәзрәт

Бүген Шиһаб хәзрәтнең туганына йөз ел тулды. Аның вафат булганына да инде чирек гасыр тулып узды. Кадыйршенас[1] милләтләр үзләренең бөек затларын, иткән хезмәтләренә карап, туган вә үлгән көнләрендә искә төшерәләр, аларга мәйданларда һәйкәлләр утыртып, аларны кадерлиләр, киләчәк буынларга хезмәт үрнәге итеп басдырып куялар.

Безнең халкымыз да заманга муафикъ милләт нигезләрен кору өчен омтылганда, аның дини, иҗтимагый, әдәби инкыйлабка мохтаҗ икәнлеге беленде, бу инкыйлабларны хәзерли тору яки шул инкыйлабларны башында торыб идарә итү өчен гайрәтле шәхесләр армый-талмый эшли торган шәхсиятләр кирәклеге аңланды.

Шул мохтаҗлык, шул кирәклекне тутыру өчен мохит, бармак белән санарлык булса да, бездә дә ирләр йитешдерде. Аларның ике-өче инде үлде дә; үлгәнләренә утыз-кырык еллар, туганларына йөз вә андан артык еллар да булып узды. Милләт шул үзенә юлбашчылык иткән кешеләрен искә төшерә, төшерергә тели; артына әйләнеп карамакчы була, олугларын кадерләп яшь буынга аларның хезмәтләрен аңлатмакчы, рухларын сеңдермәкче була.

Ләкин олугларымыз ничек бармак белән санарлык әз булса, милләтнең ул олугларны кадерләргә хәзерлеге, алар хакындагы мәгълүматы андан да аздыр. Шуның өчен дә эшләргә теләгән эшләремез күңелемездәгечә булып чыкмый.

Хезмәтләрен күз алдымызга китереп өеп күрсәткән Тукай вә Исмәгыйль бәкнең вафатлары мөнәсәбәте белән эшләгән эшләремез шул үлчәүдә кечкенә чыкды.

Шиһаб хәзрәтнең хезмәтләре тагын да тар даирәдә, мохиткә хасланган булып, ул гомум кашында Тукай вә Исмәгыйль бәк кебек танылып өлгермәгәнгә, аның йөзьеллык юбилее тагын да корырак, кечкенәрәк булачагы мәгълүм иде.

*«Ил» газетасы идарәсеннән, 1915 елның 2 гыйнвар (№56) саны.*

*Тесктны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

[1] Кадыйршенас – рәхмәтле, ихтирамлы.

## Беренче мөәррихемез Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең бөек рухының тынычлыгы өчен Тәңрегә ялварамыз

Шиһаб хәзрәт хакында матбугатдагы берән-сәрән мәкаләләрне игътибарга алмаганда, әдәбиятымызда тәрҗемәи хәленә даир бер рисалә дә нәшер ителмәде, аның хакында китаб нәшер итәчәк комиссиянең хезмәте дә әле чыгып өлгермәде. Мондан башка бу юбилейның кечкенә булуының иң зур сәбәбе – үземезнең хәрәкәтемезне күрсәтү өчен вакытының туры килмәведер, бөтен дөнья милләтләре үлү-калу мәсьәләсен чишү өчен бугаз-бугазга килеп, миллионларча җанлар кыелып ятканда, милләтләр бетеп, дәүләтләр туып, дөнья аст-өстенә килеп ятканда, шул дөнья сугышына ярым миллион егетләремезне йибәреп кушылган безнең дә тамырларымыздагы канларымыз, хәзер игътидал[1] берлән кайный алмый, безнең дә, үткәнемездән бигрәк, хәзерге хәлемез, киләчәгемезнең мәсьәләләре мөһим урын алып тора.

Шиһаб хәзрәт, вакытының иң зур мөдәррисе, ислам дөньясының иң зур галиме, мөҗәддиде булып, милли ихтыяҗларымызның дини булганларын төгәлләргә тотынды, үзенең утыздан арткан игътикад, фикъһ вә осулга, тарихга гаид[2] әсәрләрен дин теле булган гарәбчә тел белән язды. Ислам фикъһәсенә, ислам тарихына гаид әсәрләренең гарәб телендә язылуы, Шиһаб хәзрәтнең күзәткән максадына, фикеренә, гаясенә хезмәт итү өчен иде. Шиһаб хәзрәт тәмам мәгънәсе белән дин вә ислам галиме булганга, милләт аның кашында икенче дәрәҗәдә иде. Шуның өчен аның хезмәтләре билгеле даирәгә хас булып, гомумгә – аңа юбилей ясарга теләгән милләтнең гомуменә аңлашылмады.

Шиһаб хәзрәтнең игътикад вә иҗтиһад бабларындагы хезмәтләре, әсәрләре гакаиддә, фикъһда күб гасырлардан бирле буылып куелган фикер агымын табигый юлына борып йибәрергә зур хезмәт итде. Шиһаб хәзрәтнең ачкан юлларын киңәйтеп эшләп алып баручы затларымыз да бар.

---

[1] Игътидал – уртак фикер.

[2] Тарихга гаид – тарихка караган.

Дини вә иҗтимагый мәсьәләләрдә мөхтәрәм Риза хәзрәт, Муса әфәнде, Габдулла Бубый, Зыя Камали әфәнделәр милли тарихда тарихымызны җентекләп фәнни юлга куярга тырышучы яшь мөәррихемез Зәки әфәнде Шиһаб хәзрәтнең ачкан юлларындан баралар, ул юлларны киңәйтәләр, сузалар, Шиһаб хәзрәтнең рухын яшәтәләр.

Бохарада өйрәнелгән гыйлемләр, игътикад фикъһдагы торгынлыклар, ноктаи назарларның тарлыгы, фикернең буылып торуы Шиһаб хәзрәтнең шул иҗтиһадларына, дини ислахларга керешүенә сәбәб булган кебек, аның милли тарихымызны эшләве, милләтемезгә әһәмият бирүе дә үзе яшәгән мохитнең тәэсире беләндер. Шиһаб хәзрәт ислам дөньясының әүвәлге рухы сүнгәнен, исламның әсасларына төрле тарафдан һөҗүм ителгәнен тәмам аңлаган иде.

Мөселманларның мөһим бер кыйсемен тәшкил иткән Русия вә Казан мөселманларының динләренә, миллиятләренә үз заманындагы миссионерларның һөҗүмләр итүен дә бик яхшы белгән иде. Шул соңгы хәл вә, моның өстенә, Шиһаб хәзрәтнең кирәкле мәсьәләләрне үткен күз белән алдан күрә белүе вә даимән хафаланып тора торган рухының сизгечлеге кушылып, ул милләтнең үткәнен уйларга, аның киләчәгенә терәк булсын өчен үткәнен казып чыгарырга керешде. Гасырымызда мәкъбүл булган ысуле тарихга таяныб, ике җилддә милли тарихымызны язды. Хәзерге әдәби телемезгә нисбәтән, искергән булса да, үз телемездә, милли телемездә язды.

Безнең соңгы биш йөз еллык тарихымызның яңа дәвергә керүендә аңа хезмәт иткән затларның сәгыйлары[1], безгә күренмәсә дә, бер-берсе белән очланыб, соңланыб, бер-беренә бәйләнешле бер дәвер тудырып килә: Курсавилар, Мәрҗаниләр вә аларның замандашлары булган аңлы, зыялы кешеләрнең хезмәтләрендә Гаспринскийның эшләгән хезмәтләре өчен хәзерлекләр бар иде.

Бу милләтнең дини мәсьәләләрен чишкән, тарихын язган Шиһаб хәзрәтнең хезмәтләре Каюм Насыйри тарафыннан милли телнең кирәклеге рәвешендә дәвам итде. Гаспринский,

[1] Сәгыйлары – тырышлары.

шул фикерләр, шул нигезләрне мөкәммәл дәстүр[1] хәленә куеп, татбикатенә керешде.

Шиһаб хәзрәт вә аның замандашлары вә аларның эшләгән эшләре, җыелып, безнең тарихымызның тикшерелергә тиешле бер дәверен тәшкил итә. Шуны һәр якдан эшләп, нәтиҗәләрен табып, иске тарихымызга бәйләргә, тарихымызны шулай бөтенләргә кирәк. Вә тарихымызның шул дәверенең каһарманларын берәм-берәм тикшереп, алар хакында әдәбият вөҗүдкә китереп, халыкга гомумга аңлатырга кирәк. Бу вазыйфа Риза хәзрәт кебек мөәррихләремез, бөекләремезнең тәрҗемәи хәлләрен язучы затларымызга гаиддер.

Вакыты берлән, иншааллаһ, бөек Шиһаб хәзрәт милләткә үзенең әсәрләре вә аның хакында язылачак рисаләләр, китаблар белән тәмам аңланыр. Шул вакыт милләт аның юбилеен газамәтле[2] рәвешдә Шиһаб хәзрәткә муафикъ сурәтдә ясар. Хәзергә Мәрҗани хәзрәтләренең бөек рухына гаҗизанә дога кыламыз.

*Нәҗип Гасрый*

*Мәкалә Нәҗип Гасрый (1886–1937) тарафыннан язылып, «Ил» газетасының 1915 елгы 2 гыйнвар санында (56 нчы сан) басылып чыккан.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

## Шималь төрекләренең каһарманы

Моннан 70–80 еллар әүвәл шималь төрекләренең әфкяре гаммәсе[3], Садр әш-шәрига[4] вә Тәфтазаниләр[5] фикере кебек бик тар

[1] Мөкәммәл дәстүр – төзек кулланма.

[2] Газамәтле – тантаналы.

[3] Әфкяре гаммә – киң массасы, җәмәгатьчелеге.

[4] Садр әш-шәрига – күренекле мөселман галиме, факыйһ Гобәйдулла бине Мәсгуд әл-Мәхбубинең (XIV гасыр) тәхәллүсе.

[5] Тәфтазани – мәшһүр мөселман философы, каләм, мантыйк, фикъһе гыйлемнәре буенча күпсанлы хезмәтләр авторы Сәгъдеддин Мәгъсүд бине Гомәр әт-Тәфтазани (1322–1390).

мәүзугъдагы[1] бик тар рамка эченә бикләнеп, үзенең әйләнәсендәге вөкугатьтән[2] хәбәрсез хәлдә ябылып торадыр иде. Бохарадан шималь төрекләренә һәдия[3] ителгән шушы караңгылык крепосте бөтен шималь төрекләрен үз эченә алып, тик шул тар даирәдә генә әйләндерә, миллият, милли хыял, тарих, тел кебек нәрсәләр урынына, берничә тәһарәт мәсьәләсе дә берничә игътикад[4] гына фикерләрдә йөреп, ул вакыттагы уйлар вә фикерләр шуннан да читкә, шуннан да киңрәк вә яктырак галәмгә чыга алмыйдыр иде. Ул вакытта Бохара шималь төрекләре кашында бердәнбер гыйлем мәнбагы[5], бердәнбер дөнья вә ахирәт өчен нәҗат[6] урынысы ителеп танылa, Бохарада шималь төрекләрен көннән-көн шушы караңгылыкта йоклатып, акрын-акрын гына бетәргә таба өстеридер иде.

Бохараның ул вакытта шималь төрекләре кашындагы игътибарын какшату, шималь төрекләре әфкяре гаммәсен үз эченә алган Садр әш-шәрига, Тәфтазани фортларыннан ясалган крепостька һөҗүм итәргә батырчылык итү имкян хариҗында[7] шикелле күренәдер иде. Хәзерге заманның крепостьларын алдырыр өчен 42 сантиметрлы туплар кирәк булган кебек, ул вакытда шималь төрекләренең бөтен фикер вә уйларын үз эченә алган шушы тәгассыб[8] вә җәһаләт[9] крепостена һөҗүм итәр өчен дә шундый бөек вә зур вакыт кирәк иде.

Шималь төрекләренең бәхетенә каршы, моннан нәкъ йөз ел әүвәл шундый бер куәт дөньяга килде. Ул вакыт шул ук Бохараның үз кораллары илә мөкәммәл[10] рәвештә коралланып кайтарак, шималь төрекләренең мәркәзе булган Казанга урнашты

[1] Мәүзугъ – тема, проблема.
[2] Вөкугат – вакыйгалар.
[3] Һәдия – бүләк.
[4] Игътикад – ышану, инану.
[5] Мәнбаг – чыганагы, башы.
[6] Нәҗат – котылу.
[7] Имкян хариҗында – мөмкин түгел.
[8] Тәгассыб – фанатизм.
[9] Җәһаләт – наданлык, караңгылык.
[10] Мөкәммәл – камил.

һәм шуннан торып, шималь төрекләренең бөтен уй-фикерләрен үз эченә алган шушы җәһаләт вә тәгассыб крепостена каршы һөҗүмнәр ясый башлады.

Шиһаб хәзрәтнең бу юлдагы хезмәтләренең иң тәкъдир ителергә[1] лаек булганының берсе дә бер дә шиксез иҗтиһад мөнкариз[2] игътикады[3] илә бер урында туңып, катып калган фикерләрне, туңган җирләреннән эретеп кузгату, аларны Садр әш-шәрига вә Тәфтазаниләрнең хариҗендәге гыйлемгә дә бер күз салырга мәҗбүр итүедер. Шиһаб хәзрәтнең Садр әш-шәригаларга вә Тәфтазаниләргә һөҗүме, аларны тәхтыйэә[4] итүгә кадәр батырчылык итүе, ул вакытта шималь төрекләренең бердәнбер зыялы сыйныф тәшкил иткән муллаларын, кырмыска оясына таяк төрткәч, кырмыскаларны хәрәкәткә китергән кебек, хәрәкәткә китерде. Бу муллалар һәммәсе урыннарыннан селкенә башладылар, ислам әсәрләренең тирәнрәк фикер вә фәлсәфәгә гаид[5] булганнарын карый башладылар. Шушы вакыттан башлап, тик вә тыныч кына яткан шималь төрекләре дөньясы хәрәкәткә килә һәм шушы хәрәкәт насыйры[6] Гаспринский, Баруди вә Бигиләргә нигез хәзерлидер.

Шиһаб хәзрәтнең икенче бер зур хезмәтләреннән берсе Бохараны шималь төрекләре күзеннән төшерү, аның гыйльми әһәмиятен киметү булды. Мәрҗанинең бу юлдагы хезмәте дә, әлбәттә, бик зур хезмәтләрдәндер. Чынлап та, Мәрҗанидән соң Бохара тәмам шималь төрекләре күзеннән төшә, шималь төрекләре инде гыйлем вә нәҗатны[7] Бохара ягыннан эзләмиләр, бәлки җәнүбтән[8] – Мисыр, Истанбул тарафларыннан һәм Рус мәдәнияте вә әдәбиятыннан эзләргә тотыналар. Мәрҗанинең Бохараны шималь төрекләре күзеннән төшерүенең нәтиҗәсе

---

[1] Тәкъдир итү – бәя бирү.

[2] Иҗтиһад мөнкариз – тырышлык юкка чыккан.

[3] Игътикад – ышану.

[4] Тәхтыйэә – хата.

[5] Гаид – бәйләнешле.

[6] Насыйр – ярдәмче, яклаучы.

[7] Нәҗат – котылу.

[8] Җәнүб – көньяк.

уларак, шималь төрекләре арасында Мисыр, Истанбул, Париж, Петроград тәрбиясе күргән гәнеҗләр[1] җитеште, шушы гәнеҗләр шималь төрекләрендә – татарларда милли аң, милли әдәбият, милли тел, милли хыялны вөҗүдкә китерделәр[2].

Мәрҗанинең бу хезмәтләрен милләтне шәрыкка таба карап торган җиреннән, гареб[3] вә җәнүбкә таба бору диеп тәгъбир итәргә ярыйдыр ки, Мәрҗанинең бу эшләре кыйсмән[4] Петр Великийның русларга иткән хезмәтләрен искә төшерәләр. Мәрҗани үзенең тәрвиҗ иттеге[5] шушы эшләрен, ягъни шималь төрекләренең фикер даирәләрен киңәйтү һәм Бохараны – Истанбул, Мисыр вә рус мәктәпләре илә алмаштыруны – шималь төрекләре арасында үзенең мәдрәсәсен васита[6] итеп тотарак, үзе кебек гайрәтле вә үзе кебек хөр фикерле шәкертләр җитештереп калдырган. Хакыйкатән[7] дә Мәрҗани мәдрәсәсе, Мәрҗанинең мәсләген тәрвиҗендә, шималь төрекләре арасына чәчеп калдырдыкы орлыкларның үсүләрендә бик күп хезмәтләр күрсәтте. Аның шәкертләре бер җирдә дә ысуле җәдидәгә вә яңа киемгә, яңа әдәбиятка каршы төшмәделәр. Каршы төшмәү генә түгел, хәтта бик күп ярдәм итештеләр. Хасыйле шималь төрекләре арасындагы һәрбер фикри вә заһири инкыйлаб Мәрҗани шәкертләре тарафыннан кабул ителеп, хуш күрелә бардылар.

Иштә Мәрҗанинең шималь төрекләренә иткән иҗтимагый вә фикри хезмәтләре шушылар булып, кыскача әйткәндә, ул шималь төрекләре арасындагы фикри вә иҗтимагый инкыйлабны башлап калдыручы кешеләрдәндер.

Бу көн бөтен шималь төрекләре ихтирам иткән Мәрҗанинең мөхтәрәмлеге бу хезмәтләр илә генә булмыйча, аның иң бөек хезмәте дә – татар тарихына иткән хезмәтедер. Мәрҗанинең ул хезмәте хакында язуны әһелләренә калдырып, мин сүз ахырында

---

[1] Гәнеҗләр – яшьләр.

[2] Вөҗүдкә китерделәр – барлыкка китерделәр.

[3] Гареб – көнбатыш.

[4] Кыйсмән – өлешчә.

[5] Тәрвиҗ иттеге– алга җибәргән.

[6] Васита – чара.

[7] Хакыйкатән – хакыйкатьтә, чынлыкта.

шушы бөек адәмебезнең туганына йөз ел тулган көненең шундый уңайсыз вакытка туры килеп, кирәгенчә олуглана алмавына соң дәрәҗәдә тәэссеф иттегемне[1] әйтеп үтәмен. Моны шундый бөек адәмнәре булган бәхетле милләтнең иң бөек бәхетсезлеге дип тәгъбир итсәк, чын урынлы тәгъбир булачакдыр.

*Ибраһим Бикколов*

*Мәкалә И. Бикколов (1884–1938) тарафыннан язылып, 1915 елда «Кояш» газетасының 9 гыйнвар (601 нче сан) санында басылып чыга.*

*Текстны басма өчен Илһам Гомәров әзерләде*

## Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре

Без кечкенә вакытда Казанда Шиһаб хәзрәт дигән бер мәшһүр хәзрәт бар дип ишетә идек. Казандан кайткан кешеләрнең «менә Казанда бер шәп галим хәзрәт бар икән, аның кеби инде бер галим дә юк икән» диб сөйләүләре әлеге кеби хәтеремдә калган.

Без, шәкерт булып укыганда, аны китаплары аркылы инде яхшук кына таный да башлаган идек. Чөнки безнең укыган остазларыбыз Шиһаб хәзрәткә мөхлис[2] булдыкларыннан, мәдрәсәдә шәкертләр арасына аның китапларыны тараталар, аны безгә зур кеше итеп танытырга тырышалар иде. Менә шул көндән башлап мөхтәрәм Мәрҗани хәзрәтләре безнең кальбемезгә зур кеше булып кереп утырган. Шул көндән бирле аны зур кеше итеп таный башлаганмыз. Менә шул зур дип таныдыгымыз мөхтәрәм Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең тууына гыйнварның 9 ында (рабигыль-әүвәлнең 7 се буладыр) йөз ел тулды. Тууына йөз ел тулган көнендә аның хезмәтләрене искә төшереп, аңлы, зыялы кыйсем юбилейсене ясамакчы булдылар, шул мөнәсәбәт белән Казанның һәр мәхәлләсендә җомгадан соң Коръән хәтем кылынып, рухына дога кылынды. Ул көнне

[1] Тәэссеф иттегемне – борчылуымны.

[2]Мохлис – дустанә, ихлас мөгамәләдә.

чыкган гәзитәләр Мәрҗани хәзрәтләренә тәхсыйс кылынып[1], рәсемләре, тәрҗемәи хәле, иткән хезмәтләрене күрсәтү, санау белән чыктылар. Мәрҗани хәзрәтләренең юбилейсене һәркем бик тантана белән уздырырга көтеп торса да, ләкин мәмләкәтнең тынычсыз вакытына тугры килү сәбәбле, тынычрак кына үткәрергә тиешле күрелде.

Без дә, Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләрене искә төшерү, укучыларымызга аны таныту өчен, журналымызның бу номерыны Мәрҗани хәзрәтләренә тәхсыйс кылып чыгардык.

*Кыскача гына тәрҗемәи хәле*

Мәрҗани хәзрәтләре «1223 ел 7 нче рабигыль-әүвәл, 1818 ел 3 нче гыйнварда» кич ястү вакытында Казандан 50 чакрым булган Ябынчы[2] дигән карьядә дөньяга килмеш. «1306 ел, 29 шәгъбан, 1889, апрель 18»дә 74 яшендә вафат итеп, Казан зиярәтенә дәфен ителмештер[3].

Мәрҗанинең атасы Баһаведдин, анасы Бибихөбәйбә исемледер. Мәрҗани ата-анасының беренче балалары иде. Мәрҗани туганда, атасы 32, анасы 24 яшендә булган. Мәрҗанинең анасы Мәрҗани биш яшендә вакытда вафат булып, ул ана тәрбиясендән мәхрүм калмыштыр. Мәрҗани хәзрәтләре биш кенә яшендә булса да, анасының авыр-хаста вакытында күзләрендән яшене агызып: «И балам! Миндән соң анаң кем булыр? Кемгә әнкәй дип әйтерсең? Өст-башыңны кем карар? Кем тәрбия кылыр?» – дип әйткәнен нәфел итәдер.

*Мәрҗанинең баш тәхсиле[4]*

Мәрҗани, алтынчы яшенә йиткәч тә, атасының мәдрәсәсенә йөреп, авыл балалары белән бергә борынгы тәртип белән укый

---

[1]Тәхсыйс кылынып – билгеләп.

[2]Ябынчы авылы – Татарстан Республикасының Әтнә районындагы авыл.

[3]Дөресе: Мәрҗанинең туган көне – 13 гыйнвар, вафат булган көне – 15 апрель.

[4]Тәхсиле – гыйлем алуы.

башлаган, ана телене шул вакытда мөстәгъмәл[1] булган китаплардан укыган. Мәрҗанинең зәкявәте[2], зирәклеге шул вакытда ук беленә башлаганга, ул укыганда ихлас, дәрт һәм укыган нәрсәсене дикъкать вә мөхакәмә белән укый торган булган.

Мәрҗани бик яшьдән гарәпчә укырга керешеп, нәхү[3], сарыфтан[4], «Бәдан», «Шәрхе Габдулла»[5], кавагыйд[6], гавамил[7], «Әнмүзәҗ»[8], «Кафия»[9]китаплары укыган.

Мәрҗани гарәпчә сарыф укырга башлаганда тугыз-ун яшендән дә артык булмамыштыр.

Мәрҗанигә авыл мәдрәсәсендә дәрт белән тырышып укыган вакытында байтак уңайсызлыклар, дәрсендән манигъ[10] булган эшләр дә чыгып торгалаган. Чөнки Мәрҗани йортда балаларның иң зурысы булу сәбәпле, аңа байтак кына йорт эшләре эшләргә тугры килгән. Күп вакытда Мәрҗани көндез йорт эше эшләп, кич кенә мәдрәсәгә барып укый торган булган. Әлбәттә, боңа үги ананың да тәэсире булгандыр. Мәрҗани

---

[1] Мөстәгъмәл – кулланылган.

[2] Зәкявәте – акылы, зирәклеге.

[3] Нәхү – синтаксис.

[4] Сарыфтан – морфологиядән.

[5] «Шәрхе Габдулла» – мәдрәсәләрдә киң таралган дәреслек. Гыйззәтеддин Зәнҗанигә (?–1257) нисбәт ителгән, «Әл-Мугыйзза» исемле гарәп грамматикасының икенче бүлегенә (сарыфына) фарсы телендә шәрех биргән дәреслек. Иранлы-таҗик балалары өчен Бохарада язылып, кульязма хәлендә йөргән, анда укыган татарлар алып кайтып, Казанда берничә кат нәшер ителгән, 1894 елда дүртенче басмасы чыккан.

[6] Кавагыйд – грамматик кагыйдәләр.

[7] Гавамил – сүз төрләнеше.

[8] «Әнмүзәҗ» – Җәмалетдин Мөхәммәд бине Садр әл-хаҗи Шәмсетдин Габделгафи әл-Әрдәбилинең «Шәрхел-Әнмүзәҗ фи-н-нәхү» («Синтаксис үрнәгенә аңлатма») китабы. Гарәп теле синтаксисыннан дәреслек.

[9] «Кафия» – тулы исеме: «Әл-кафия фин-нәхү» («Синтаксис буенча трактаты, яисә Әл-кафия» («Җитәрлек»). Гарәп теле синтаксисы. Авторы: Җамалетдин Әбү Гаяр Госман бине Гомәр бине Әбү Бәкер бине әл-Хаҗиб (1248 елда үлгән).

[10] Манигъ – киртә.

атасы мәдрәсәсендә сарыфтан башлап «Тәүзыйхка»[1] кадәр, икенче төрле әйтсәк, шул заманның ысулына күрә хәтме көтеб[2] кылганчы укымыштыр. Ләкин Мәрҗани хәзрәтләре башка шәкертләр шикелле мәдрәсәдә укылган дәресләр белән генә канәгатьләнмәде. Ул китап укуда, китап моталәга кылуда[3] комсыз иде. Шуның өчен атасының, бабасының китапханәсендә булган гарәпчә китапларны аңларга тырышып моталәга кыладыр иде. Мәрҗани шул вакытта ук тарихка һәвәс[4] куя башлаган. Тарихдан яки тәваҗим әхвальдән китап тапса, аны белергә ныграк тырышкан. Аны сөя-сөя моталәга итә торган булган.

Мәрҗани хәзрәтләре, 17 яшендә атасы мәдрәсәсендә хәтме көтеб кылгандан соң, шул ук мәдрәсәдә үзе шәкертләргә дәрес әйтә башламыштыр.

Мәрҗани хәзрәтләре дәрес укыта башлагач та, укыта торган дәресләр хакында уйларга, аларны тәнкыйть вә мохакәмә итәргә, укыту ысулларының кимчелекләрене сизеп, бәгъзе дәресләрнең укыту рәвешләрен ислах итәргә лязим[5] күрә башлаган. Атасы тарафындан бер дә манигъ булмагач, бәгъзе дәресләрне үзе теләгәнчә укыта да башлаган.

Беренче үк аның дикъкатене җәлеп иткән нәрсә «Шәрхе Габдулла» китабы булган. Ул татар баласына гарәпчә сарыф кагыйдәләрне фарсыча укытуны яратмый, «Шәрхе Габдулла» урынына үзе язып укыта башлаган. Шулвакытда балалар өчен бер «Гыйльме хәл» китабы язганын да риваять итәләр.

Бондан соң Мәрҗанинең гыйлемгә һәвәсе тагы да арта төшеп, ул кайда булса да читкә китеп гыйлем тәхсил итәргә

---

[1] «Тәүзыйх» («Ачык аңлату»). Тулы исеме: «Тәүзыйх фи халл гавамиз әт-тәнкых». Ислам хокукларына кереш буенча язылган «Тәнкых әл-усуль» китабына шәрех. Казанда бу хезмәт берничә тапкыр басылган, мәдрәсәләр программасына кергән.

[2] Хәтме көтеб – укып бетерү.

[3] Моталәга – өйрәнү, уку.

[4] Һәвәс – теләк.

[5] Лязим – тиеш.

кирәксенә башлый. Ул вакытда Бохара – мәнбәгы гыйлем[1], гыйлем чишмәсе дип мәшһүр булганлыктан, аталары вә башка якыннары да Бохараны, Бохараның голямаларыны бик мактап сөйләгәннәрендән, аның Бохарага бару дәрте кузгала. Һәм Бохарага барырга карар да бирә.

*Бохарага сәфәре*

Мәрҗани хәзрәтләре 1838 сәнә 17 нче майда (ул вакытда 21 яшьдә була) Бохарага барырга хәзерләнә, үзенә кирәк юл әсбабыны, киемләрне һәм атасы тарафыннан бирелмеш берникадәр китапларны алып, Мәңгәр карьясенең сәүдәгәре Мохтар бине Мөхәррәмнең Бохарага бара торган йөкләре белән сәфәргә чыгып китәдер. Чөнки ул вакытда Казан татарларының Бохара белән сәүдәләре зур булганлыктан, һәрвакыт Казан белән Бохара арасында кәрван белән йөк йөреп торган.

Ул вакытка кадәр Мәрҗани үз авылыннан башка һичкайда чыкмаган булган. Хәтта Казанга килгәне дә юк икән. Шуның өчен Мәрҗанинең бу беренче сәфәре аңа байтак тәэсир иткәндер. Мәрҗани Бохарага сәфәр иткән вакытда чуен юллар булмау сәбәпле, ат белән, бәгъзе урыннарны дөя белән барырга тугры килгән. Ул юлда күргән шәһәр вә авылларны үзенең хатирә дәфтәренә язып барган. Кукмара, Алабуга, Чаллы, Троицки, Тургай, Ак мәсҗед, Сырдәрья дигән шәһәрләргә туктаганыны язадыр.

Бохарага барышлый, Троицкида юлчылар туры килмәү сәбәпле, анда берничә ай торырга тугры килгән. Шулвакыт Троицкида голямалар мәҗлесенә йөреп, алар белән күп катнашканны сөйлидер.

Мәрҗани хәзрәтләре Бохарада «Ишан хәлифә Ниязколый» мәдрәсәсендән 35 сумга бер хөҗрә[2] сатып алып, шунда урнашкан. Соңра Бохараның иң карт вә олуг мөдәррисләрендән дамелла Мирзасалих әл-Хөҗәндидән дәрес укырга керешмештер.

---

[1] Мәнбәгы гыйлем – гыйлем чыганагы.

[2] Хөҗрә – бүлмә.

Мәрҗани, баргач та, авылда укыган дәресләрен «Гакаид»тән[1] башлап яңадан дәрес итеп укырга башлаган. Әүвәл елларда бик тырышып, Бохара гадәте, Бохара тәртибе белән шәрех вә хашияләрнең барысын да моталәга итеп укыган. Ләкин соңга таба Бохараның дәрес тәртипләрендән риза булмый башлап, мәдрәсәләрдә мәкъсуд булган фәнләр укылмыйча, ул кадәр күп шәрех-хашияләр укылуына, әһәмиятсез мантыйк, кәлям[2] моназарәләре белән шәкертләрнең гомер үткәрүләренә, голүме диниягә махсус мәктәпләрдә тәфсир, Коръән, хәдис, әдәбият гарәбия дәресләренең укылмавына тәәссеф[3] һәм тәгаҗҗеб[4] итмештер.

Мәрҗани хәзрәтләре, Бохарадагы дәрес ысулларын ислах итү турысында остазлары белән киңәшеп, аларга тәлкыйн итеп[5] караса да, файда итә алмаган. Икенче төрле әйткәндә, аларны тыңлата алмаган. Мәрҗани хәзрәтләре, мәдрәсәдәге дәресләрдән разый булмый башлагач, күбрәк вакытны Бохараның көтепханәләренә йөреп, андагы кыйммәтле әсәрләрне моталәга итәргә, аларны тәфтиш итәргә, алардан файдаланырга башламыштыр. Үзе дә, Бохараның иң зур, иң мәшһүр мәдрәсәсе булган «Мәдрәсәи Күгелдаш»тан хөҗрә алып, шунда күчкән.

Мәрҗани хәзрәтләренең Бохарада матди җәһәтдән тормышы бик иркен булмаган. Күп вакытда яланаякка башмак киеп йөргән. Ләкин ике-өч ел торгандан соң үзбәк, төрекмән шәкертләрә үзе хосусый дәресләр укыта башлап, мәгыйшәтене киңәйтмештер.

---

[1] «Гакаид» – Нәҗметдин Нәсәфинең (1068–1142) «Гакаиде Нәсәфи» («Ислам инанулары Нәсәфи аңлатуында») китабы. Мәдрәсәләрдә ул китапның үзен түгел, ә шул әсәргә шәрех китапларын өйрәнгәннәр. Халык арасында Сәгъдетдин Тәфтазани (1321–1390) тарафыннан язылган «Шәрхе Гакаиде Нәсәфи» киң таралган булган. Бу китап Казанда 1897 елда басылып чыккан. Әлеге хезмәтләрдә ислам дине кагыйдәләре, исламның тәрәкләре турында сүз алып барылган.

[2] Кәлям – сүз, сөйләм.

[3] Тәәссеф – кайгыру.

[4] Тәгаҗҗеб – гаҗәпләнү.

[5] Тәлкыйн итеп – аңлатып.

Мәрҗани хәзрәтләре, Бохарада биш ел торгандан соң, Төркестанда Бохарадан кала иң зур гыйлем мәркәзе булган Сәмәрканд шәһәренә килеп, анда «Ширдар» исемле мәдрәсәгә керә.

Анда казый Әбү Сәгыйд хәзрәтләре белән танышып, аның балаларына төрле фәннәрдән дәрес укытып, Сәмәркандтә тора башлый. Шул вакытда Мәрҗани, казый Әбү Сәгыйднең көтепханәсенә йөреп, аның хисапсыз күп китапларыны моталәга итмештер. Хәтта бу китапларның бәгъзесене язып та алмыш. Мәрҗани хәзрәтләре: «Миңа аң биргән, минем фикеремне төзәткән, хөласа[1] минем беренче мөршидләрем[2] казый Әбү Сәгыйд хәзрәтләренең көтепханәсендәге китаплары булды», – дип сөйләмештер.

Сәмәркандтә ике ел торгандин соңра, үзе барырга теләмәсә дә, икенче мәртәбә янә Бохарага китмештер. Икенче мәртәбә Бохарага кайткач, Бохараның иң бай, иң мәгъруф мәдрәсәләреннән «Мир Гарәп» мәдрәсәсендән хөҗрә сатып алып, урынлашып, яңадан Бохарада биш ел кадәр торган.

### *Бохарадан кайтуы*

Мәрҗани хәзрәтләре 11 сәнә Бохарада торгандан соң Төркестан тарафына барып сату итүче вә үзләренә кияү тиешле булган Фәйзрахман бине Габделгаффар әт-Тазлари белән (1849 ел 21 майда) үзләренең ватаны булган Ташкичүгә кайтырга чыккан. Ул вакытда Казанның беренче мәхәлләсе имамсыз калган икән. Ибраһим бай Юнусовка[3] (Озын Ибрай) юлда кайткан иптәшләре Мәрҗани хәзрәтләрене бик галим кеше, Бохарадан кайтды дип мактауларына күрә, Ибраһим бай Казанда бик зур голямалар мәҗлесе ясап, Мәрҗанине имтихан итү өчен Казанга чакырмыштыр. Җыелган голямалар Мәрҗани хәзрәтләреннән күп сүзләр сорап, аны әлзәм[4] итәргә теләсәләр дә, ләкин

---

[1] Хөласа – нәтиҗәдә.

[2] Мөршидләрем – юл күрсәтүчеләрем.

[3] Ибраһим Юнусов (1806–1886) – татар сәүдәгәре, хәйрияче, коммерция советнигы.

[4]Әлзәм – иң кирәкле.

Мәрҗани хәзрәтләренең бик тәхкыйкатьле[1] җавап бирүендән һәм зур ислам фәйләсуфларының китапларындан төрле кыйммәтле сүзләр нәкыль итүен[2] күреп, гыйлеменең тирәнлегенә мөсәлләм[3] булмышлардыр. Шуның нәтиҗәсендә, Мәрҗани хәзрәтләре (1850 нче ел, 30 нчы мартда), Казанга килеп, беренче мәсҗедкә имам-хатыйб вә мөдәррис булмыштыр.

Мәдрәсәсе: Мәрҗани хәзрәтләре Казанга килеп мулла булгач та, мәдрәсә ачып укыта башлавына һәр тарафдан зур шәкертләр җыелып, бик тиз мәдрәсәсе тәрәкъкый[4] иткән. Мәрҗани шәкертләренә һәрвакыт тугры фикер, әсаслы[5] гыйлем бирергә тырышкан. Шуның өчен Русия мөселманларында иң эшлекле, иң тәгассыбсыз[6] муллалар – Мәрҗани шәкертләре дисәк, аз хата итәрмез. Мәрҗани хәзрәтләре күп вакытны язу белән, тәэлиф[7] белән шөгыльләнмештер. Әүвәл башлап татарның тарихыны язучы Мәрҗани хәзрәтләре булмыш. Ул бу бабда ике җилдлек «Мөстәфадел-әхбар»[8] китабыны язмыштыр. Андан башка йиде җилдлек «Вафийәт әл-әсляф»[9] исемле тарихи, «Хизәмәт»[10], «Хикмәт әл-гайн»[11], «Хашия мулла Җәлал»[12],

[1] Тәхкыйкатьле – хакыйкый.

[2] Нәкыль итүен – сөйләвен.

[3] Мөсәлләм – канәгать.

[4] Тәрәкъкый – алга китү.

[5] Әсаслы – нигезле.

[6] Тәгассыбсыз – фанатизмга бирелмичә.

[7] Тәэлиф – китап язу.

[8] Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдалы хәбәрләр») хезмәте.

[9] Ш.Мәрҗанинең «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре») хезмәте.

[10] Ш.Мәрҗанинең «Хизәмәт әл-хәваши ли-идәхәт әл-гаваши» («Гаделлекне томалаучы пәрдәне алу өчен шәрехләүләр җыентыгы») хезмәте.

[11] Ш.Мәрҗанинең «Хикмәт әл-балигат әл-җәннияти фи шәрх әл-гакаид әл-хәнәфияти» («Хәнәфиләрнең дини ышанулары турында өлгереп җиткән дөрес карашлар китабы») хезмәте.

[12] Бөтен мөселман дөньясына билгеле XIV йөз илаһият галиме әт-Тәфтазаниның «Газб әл-фурат вәл-мәгез-зөләл эн-нәкыйгли-әсрах-шәрхе әл-Җәләл» («Җәләл шәрехләвен ачыклауга карата бик нык эчәсе килгәндә сусауны басу өчен бирелгән саф һәм татлы су кебек дөрес фикерләр») исемле хезмәтен шәрехләвен тәкъдим итүе хакында сүз.

«Назурәт»[1], «Әл-Бәрк әл-вамид»[2] исемле китаплар язып калдырмыштыр. Йиде җилдлек «Вафийәт әл-әсляф»ы бу көнгә кадәр басылганы юк иде. Менә йөз елы тулу шәрәфенә якынлары, дустлары тарафыннан шул «Вафийәт әл-әсляф»ны бастырып нәшер итәргә карар бирелгән дип ишетелде.

*Хатын-кызларга карашы*

Мәрҗани хәзрәтләренең хатын-кызларга карашы, гомумән әйткәндә, хөр иде. Хатын-кызларның укымый надан калуларына аслан[3] разый булмады. Бервакыт хатын-кызларны алып, мәҗнүнләр йортына барды. Шундагы нәзыйр һәм җәмәгатьләре белән күрешеп утырыштылар. Шундан кайтканда кызларына карап: «Менә аларның кызлары, өч-дүрт төрле тел белүләре өстенә, музыкалар да үгрәнәләр. Сез дә дөм сукыр, дөм гафил булмаңыз, иң азында бер-ике төрле язу өйрәнеңез», – дип, кызларыны үгетләмештер.

Әхлак вә табигате: Мәрҗани хәзрәтләре – гаять мәһабәт, вәкарьле[4], аз сүзле, хаким табигатьле, мөстәкыйль фикерле, гали һиммәтле, тырышчан, гаять җәсүр[5] бер адәмдер. Мәрҗанинең иң бөек хасыятьләрендән берсе – башлаган эшендә сәбат[6] вә гайрәт белән дәвам итүедер. Ул үзенең тотынган эшендә ахырына кадәр барып чыга; мең төрле манигълар, тау кадәр авыр сүзләр, ифтиралар[7] булса да, башлаган эшен эшли, иҗтиһадына аз гына да хәләл[8] китерми иде.

---

[1] Ш.Мәрҗанинең «Назурәт әл-хак фи фәдийәт әл-гашаи вә ин ләм йагаб әш-шәфәкъ» («Эңгер-меңгер төшүгә бәйсез рәвештә кичке намазның кирәклеге турында хакыйкатькә бер караш») хезмәте.

[2] Ш.Мәрҗанинең «Әл-Бәрк әл-вамид фир-рәдд галәл-бәгыйд әл-мөсәмма бин-нәкыйд» («Тискәре исеме белән аталган дошманнарның фикерләрен кире кагып яндыручы яшен») хезмәте хакында сүз.

[3] Аслан – беркайчан да.

[4] Вәкарьле – горур.

[5] Җәсүр – батыр, кыю.

[6] Сәбат – ныклык.

[7] Ифтиралар – гаеп ташлау.

[8] Хәләл – *монда:* зарар.

Мәрҗани һәртөрле гыйлем әсбабына, хәтта кечкенә кагыйдәләргә дә ихтирам итә. Шуның өчен ул үзенә килгән хатларны, дәгъватнамәләрнең һәрберсене җыеп төпләгән.

Мәрҗанинең дикъкатене җәлеп иткән нәрсәләрнең берсе – асаре гатика[1] булмыштыр. Ул һәртөрле иске акчаларны, иске китапларны, иске язуларны, кабер ташларына язылган иске язуларны җыеп забыт иткән[2]. Мәрҗани кием-салымда купшы булып, әйбәт, чиста киенә. Киемендә һичбер тап тотмый, чалмасы, күбесенчә, ак була иде. Нәфел[3], ишрак[4], тәһәҗҗүд[5] намазлары белән шөгыльләнми иде.

Ул заман голямасы рәсем алдыруны хәрам дип тордыклары вакытда Мәрҗани ике мәртәбә рәсем алдырмыштыр. Гәзитә укырга ярата. Истанбулдан «Әл-җәваиб», «Басыйрәт» гәзитәләре һәм «Тәрҗеман»[6] гәзитәсе алдырмыштыр.

1859 ел 17 нче сентябрьдә мәхкәмәи шәргыя тарафыннан Мәрҗани хәзрәтләре Казанда нәшер ителә торган «Кәлям шәриф»кә рәсми мосхәф ителеп, куелып, мосхәфнең[7] рәсми турысында зур хезмәт итмештер[8].

Шушы юбилейгә туры китереп, Мәрҗани хәзрәтләренең мөфассал[9] тәрҗемәи хәле басылып чыкты.

Һәркемгә алып укырга тәүсыя итәмез[10].

Мәрҗани хәзрәтләре хакыйкатән татар дөньясында үрнәк

[1] Асаре гатика – борынгы әйберләр.

[2] Забыт иткән – кулга төшергән.

[3] Нәфел – өстәмә.

[4] Ишрак – кояш чыгу.

[5] Тәһәҗҗүд – төнге, өстәмә.

[6] «Тәрҗеман» – 1885–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә нәшер ителгән әдәби-сәяси, фәнни газета.

[7] Мосхәфнең – Коръәннең.

[8] Монда сүз Коръәннең Казан басмалары текстының тулылыгына һәм төгәллегенә Ш. Мәрҗани тарафыннан күзәтчелек итү турында бара. Соңыннан ул Россиядә Коръән бастыру тарихына багышланган «Фаваид әл-мөһиммә» («Файдалы һәм мөһим») дигән китап чыгара.

[9] Мөфассал – тулы.

[10] Тәүсыя итәмез – киңәш итәбез.

булырлык кеше иде. Ул безнең ифтихар итәрлек[1] мәгънәви атамыздыр. Йөз ел тулуы белән аны сагынамыз. Аның рухына ихлас кальбемез белән дога кыламыз.

*Ягъкуб Хәлили*

*Мәкалә журналист, мәгърифәтче Ягъкуб Хәлили (1877–1938) тарафыннан язылып, «Сөембикә» журналының 1915 елгы 6 нчы санында басылган.*

*Текстны басмага Гөлнара Зәйниева әзерләде*

## Мәрҗани хакында кечкенәлегемдә язган бәгъзе нәрсәләрем мөнәсәбәте илә

Минем бабам һәм остазым булган Хәбиб әл-Нажар хәзрәт Мәрҗанинең иң мөхлис шәкертләреннән вә мәшһүр хәлфәләреннән булган. Хәбиб әл-Нажар хәзрәт мәрхүм Мәрҗанинең мәсләгенә[2] һәм күп гыйлеменә варис булып калган. Тарих һәм мөселман гыйлемнәре бабында мин Хәбиб әл-Нажар хәзрәтне ихатасы[3] Мәрҗанигә нисбәт күп тар булуын игътираф итү[4] белә бергә Мәрҗанигә хилаф[5] саныймын. Чөнки без Мәрҗанине күпме яхшы үгрәнсәк тә, аның тугры «отпечатог»[6]ы фәкать Хәбиб әл-Нажар хәзрәттә булганын игътираф итми чара юк.

1908 ел 18 яшемдә чакта бу кеше хозурыннан качып, Казанга киткән вакытыма кадәр ул мине үзенең мәдрәсә һәм йортында[7] Мәрҗанидән мирас булып калган юл белә тәрбия итте. Мәрҗанидән мирас булып калган юл димен, чөнки ул үзе ислам тарихына

[1] Ифтихар итәрлек – горурланырлык.

[2] Мәсләгенә – ысулына.

[3] Ихатасы – *монда:* белем, аңлау дәрәҗәсе.

[4] Игътираф итү – тану.

[5] Хилаф – каршы, ярамаган эш.

[6] Кирилл хәрефләре белән бирелгән.

[7] Хәбиб әл-Нажар хәзрәт минем анам белә бертуган. Аның электә баласы булмаганлыктан кечкенәлегемнән аның баласы кебек булып өендә тәрбияләндем (Ә.Вәлиди искәрмәсе). Хәбиб әл-Нажар (Хәбибнаҗар) Мөхәммәткафи улы Сатлыков (Үтәки, 1862–1921) – Үтәки авылы кешесе, Мәрҗанинең укучысы. Ул авылында мәдрәсә тоткан һәм З.Вәлиди 1902–1908 елларда шул мәдрәсәдә белем алган (Г. Х. искәрмәсе).

гаид[1] күп кенә әсәрләргә малик[2] һәм Шиһаб хәзрәтнең тарихка гаид язганнарын хәтердән белә торган[3] иде. Безгә даимән тарих бабында һәм ислам фәлсәфәсе һәм кәлямияте бабында Мәрҗани тоткан мәзһәбне[4] тотып килде. Ошбуның өчен мин үземне билвасита[5] булса да Мәрҗанинең шәкерте хисаплыймын.

Мәрҗанине мин бик кечкенәлегемнән ишеткәнмен. Ул йирдә күрше авылда Мәрҗанинең бик мохлис һәм яхшы ук гыйлеме булу сәбәпле, Мәрҗанине битәмамә[6] аңлый торган Шафигъ ахунд бар иде. Мулла бабай (Хәбиб әл-Нәҗар хәзрәтне без шулай атыймыз) белә Шафигъ ахунд бик дөрест иделәр. Һәм боларның бик еш була торган сохбәтләрендә[7] күп вакыт мин һәм була идем. Башка мәсьәләләрдә булган кеби Мәрҗани хакындагы сүзләрен дә ишетер идем. Ошбу сәбәбләрдәндер, ки мин бик кечкенәлегемнән үк хәзрәт бабайны белә идем дә, Мәрҗанине белә идем. Ул заман Мәрҗани минем каштa иске заманда булып үткән зур бер мөселман галиме, Имам Әгъзам дигән кеби бер мөҗтәһид[8] төсле булганын әле дә беләм. Мин Акмулла[9] мәрсиясенең күп йирләрен яттан белә идем, чөнки шунда ук минем туганнарым булган Таһир һәм Зариф муллалар да (Хәбиб әл-Нажар хәзрәтнең бертуган энеләре) Мәрҗани шәкертләре иделәр. Алар агызыннан ишетеп һәм үзем укып, Акмулла бәетләрен ятлаганмын. «Назурәт әл-хак»ны башта укымаган булсам да, ни сөйләгәнен белә идем. Соңыннан «Назурәт», «Хикмәт әл-балигат», «Бәркуль-вәмид» хәзинәне миңа укырга тугры килде һәм 1908 нче ел җәй көне Орен-

---

[1] Гаид – бәйләнешле.

[2] Малик – ия.

[3] Хәбиб әл-Нәҗар хәзрәт тарихны белеп кенә куймаган, аның тарихтан манигъ «әл-Тәварих» исемендә бер әсәре басылган һәм «Мәҗмуга мөһиммә» исемендә үз әтрафының (ягының) тарихын язган бер мәҗмугасы бар (Ә. Вәлиди искәрмәсе).

[4]Мәзһәбне – юнәлешне.

[5] Билвасита – кеше аркылы, ярдәмендә.

[6]Битәмамә – чиксез.

[7] Сохбәтләрендә – сөйләшеп утыруларында.

[8]Мөҗтәһид – дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы.

[9]Акмулла (1831–1895) – татар мәгърифәтче шагыйре.

бург һәм Казанга киткәнемдә мин «Әт-тарикать әл-мөсла вә әл-гакыйдәт әл-хөсна»[1], «Мөнтәхәбел «Вафийә»ләрне[2] гыйбарәләре белә шигырь кеби итеп бикләдем. Оренбургтан Казанга килгәнемдә пароход өстендә Сембергә килеп йитәр алдында «Мөнтәхәбел «Вафийә»не тәмам яттан укып чикканым хәтеремдә. Ул вакыт Курсави[3], Мәрҗани, Габделхәбир әл-Мөслими, Гариф бине Сәламколый, Низаметдин әл-Һами, Әхмәдҗан бине Әмирхан[4]нар безнең өчен идеал иделәр.

Ниндидер бер юл илә миңа кечкенәлегемнән үк бер гадәт кереп калган. Кечкенәлегемнән үк мин колакка бәрелерлек сүзләрне, хикәяләрне язып барганмын. Үткән ел авылга кайтканда иске «Шәрхе Габдулла»м[5] арасында һәм аның катыргысында борынгы хәзрәтләр голямәләре хакында мулла бабай һәм Шафигъ ахунд агызыннан язып алган сүзләрен, хикәяләрен күрдем. Бик хәтеремдә. Мин ун-унбер яшьләремдә булса кирәк, мулла бабай мәдрәсәгә бер шәкерткә Шафигъ ахундлар белә бергә ашка кил-

[1] Мәрҗанинең үзе үлгәннән соң, 1890 елда басылган китап.

[2] Мәрҗанинең «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре») исемле әсәре.

[3] Курсави Габденнасыйр Ибраһим улы (1776–1812), дин эшлеклесе, илаһият галиме.

[4] Низаметдин һәм Гарифлар хакында бу ел 9 нчы гыйнварда чыккан «Йолдыз»да әйттем. Әхмәдҗан хәзрәт Курсавиларның могасыйре (замандашы) һәм шулар мәсләгендә бер кеше булган. 1813 ел Малмыж өязендә Ушма авылында 29 яшьләрендә вафат иткән. Үзе Бохара кебек йирләргә йөремәсә дә, үз атасы Әмирхан хәзрәт янында тәхсил итеп (гыйлем алып), бик күп нәрсәләр белгән һәм гарәпчә яхшы гына язган, «Сөннәт әл-бәшарәт фи сөннәтәл-шәрә» дигән китабы Казанда матбуг (басылып чыккан). Моннан берничә еллар элгәре вафат иткән Мостафа бай Әмирханов бунын нәселеннән иде. Бу көн Истанбул дарелфөнүнендә (югары уку йортында) студент Әхмәд Әмирханов – янә шул нәселеннәндер. Эстәрлетамак өязе Габделхәлил хәзрәт бунын шәкерте булган (Асар, җилд 2, 327 б.).

Әхмәдҗан мәхдүм – элекеге авторитетларга тәнкыйть белә карый башлауның иң әүвәлге дәвере кешеләреннәндер. Тәрҗемәи хәле «Мөстәфадел-әхбар» җилд 2, «Асар» җилд 1, 131–133 б.дә бар.

[5] «Шәрхе Габдулла» – дәреслек. Тулырак мәгълүматны Ягъкуб Хәлилинең «Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре» исемле мәкаләсенә язылган аңлатмадан карагыз.

гән иде. Шунда минем Рабига Гадавия һәм Хәсән Басрыйлар[1] хакында Шафигъ ахунд агызыннан язып алган нәрсәләремне сөйләп, мине мактап утырды; бу эш, әлбәттә, мине тагын гайрәтләндерде. Әле бу ел кайтканымда тагын китаплар арасыннан 1907 һәм 1908 еллар шул мулла бабайда укып яткан вакытта язып алган нәрсәләр таптым. Ләкин тагын элегерәк елларда язгалап килгән нәрсәләрем бар иде, алар табылмадылар. Табылган кадәресенең беразын бу урында күчерәм:

1906–1907 елларда язылган. Башы юк. Монда Мәрҗанинең үлем алдындагы хәлен сөйләгән.

«... кәндесе[2] какрып, күзләре эреннәр илә тулу улып ята иде. Шу хәлендә дә гыйлем илә иштигален[3] куймады. Миңа «Мөстәфадел-әхбар»ның[4] икенче җилдennән[5] бәгъзе мәүзыйгларын тәкмил итмәк[6] эшен тапшырды. Семипулат һәм Сәгыйд касабәсе[7] хакында бәгъзе мәгълүмат гыйлавә идракә[8] боерды. Бер ел буена йоклай алмас улды. Бәгъзе вакыт йокы килгән кеби булыр иде, дәрес вакытында мендәр сорар һәм башын куеп торыр, ләкин янә йоклый алмас иде.

Дәрес вакытында аю тиресенә утыра, әмма мендәргә утырмый торган иде. Иң хуп күргән мәҗлесе – мәдрәсә мәҗлесе иде. Ничә самавырлар бетәр иде, чәйне бик яратып эчәр иде. Шәкертләр дамеллага[9] бәлеш пешереп, кул илә ашамакка чакырырлар иде. Рәхәтләнеп ашар иде. Башыннан чалмалары, түбәтәйләре төшеп китәр иде.

Үзем бервакыт тир авыруы илә авырдым. Хәзрәт, һәркөн

---

[1] Рабига Гадавия (717–801), Хәсән Басрый (642–728) – илаһият галимнәре.

[2] Кәндесе – үзе.

[3] Иштигален – шөгылен.

[4] Монда сүз Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдалы хәбәрләр») исемле әсәре хакында.

[5] Җилденнән – бүлегеннән.

[6] Бәгъзе мәүзыйглары тәкмил итмәк – кайбер урыннарын тәмам итү.

[7] Касабәсе – өяз шәһәре.

[8] Гыйлавә идракә – өстәмә белү, төшенү.

[9] Дамеллага – дәрес бирүчегә, укытучыга.

ике-өч мәртәбә ишектән башын тыгып: «Нихәл, мулла Наҗар, төзәлмәйсеңме әле?» – дип сорай торган иде. Бераз төзәлгәч, бүлмәгә таягы белә таянган хәлдә кереп торды һәм «Йә, мулла Наҗар, чәчне алаек», – диде. Аның чәчен күп вакыт мин ала идем, җылы су илә йибетә торган идем. Башы зур иде, тигез иде. Маңгаеның уң ягыннан җилкә тарафында бер чуаны бар иде. Менә шул вакытта ул күп сүзләр сөйләшә иде»[1].

1907 нче ел хатирә дәфтәре кәгазьләренә язылган:

Мәрҗани үзе, Бохара тәртибен яратмаса да, ни өчен дәресләрне Бохара өслүбендә алып бармыштыр[2].

Иң әүвәл шуны әйтергә кирәк: Мәрҗанинең вакытында улып татар халкының, гомумән, әһле исламның ул вакыттагы хәлен яхшы белгән кеше ничек тә ул вакыттагы әхваль илә ашна[3] улган кемсә мондый сөальне бирмәс.

Мәрҗанинең вакытында Казан вә әтрафында[4] гыйлем эшләре ля нөсәллим[5] иде. Бөтен мохит ля нөсәллим илә агуланган иде. Бу хәл ул вакытта халыкның мәгънәви, рухи хәлләрен тәрбия итүче кемсәләр Наполеон[6] кадәр эшлекле, Чыңгыз хан[7] кадәр куәтле улсалар да, янә үзләренең максудларына бик аз гына якынлаша алалар иде. Ваграк идеалистлар, прогрестлар[8] ул вакыт һәм Мәрҗанидән соңра аз зоһур итмәделәр[9]. Халыкның, мохитнең ул куәтле агымында, рухында изелеп тапталдылар да беттеләр. Фарыз итеңез! Мәрҗани үзе-

[1] Мулла бабай ошбу мәзмундә (әйтергә теләгәне) бәгъзе сүзләрне 1912 нче ел һәм сөйләгән иде. Язган кәгазьләремне таба алмадым (Ә. Вәлиди искәрмәсе).

[2] Бу хосуста ошбу 1908 яки 1909 ел Ризаэддин хәзрәткә һәм бер нәрсә язып йибәргән идем. Ул аны «Шура»да бастырды бугай.

[3] Ашна – таныш.

[4] Әтрафында – тирә-ягында.

[5] Ля нөсәллим – канәгатьләнерлек түгел.

[6] Наполеон I Бонапарт (1769–1821) – Франция императоры.

[7] Чыңгыз хан (1155 ел тирәсе – 1227) – Монгол империясенә нигез салучы, җиһангир.

[8] Прогрестлар – прогресс яклылар.

[9] Зоһур итмәделәр – мәйданга чыкмадылар.

нең мәҗмугъ[1] планнарын вөҗүдкә куеп йибәрсен – аңа берәр шәкерт килер идеме? Кышкарларда, Мәчкәрәләрдә гайн[2] Казанның үзендә ля нөсәллим шәкертләре Мәрҗанинең шәкертләрен, ля нөсәллим улмаганнары фарызда, һәрбер мәҗлестә галәбә итеп[3], ыргытып ташлап, халык күзеннән төшереп, һиммәтләрен, күңелләрен сындырып торсыннар. Инде шул вакытта Мәрҗани шәкертләренең тәфсир, хәдис, җәгърафия, тарих укып утырулары мөтәсаувирмы[4]? Мәрҗани күп вакытларда үзенең шәкертләренә үзенең кашында[5] сөекле улган өслүбтә дәрес укытырга башлады. Ләкин шәкертләре, аның ул юлы илә барганда «Надан калырмыз (!)» зан итеп[6], эшләрен туктаттылар. Ошбуның өчен Мәрҗани үзенең дошманы улган күп нәрсәләрне әхвальгә, шәкертләрнең кәефенә карап укытып торырга һәм шул эшләрне эшләп, шәкертне суындыруны икенче бер юлга кертүгә иҗтиһад иткән[7]. Мәрҗани ля нөсәллимнәрне укытып бетергәннең яки шәкертләрнең бу эшләр илә иштигален[8] карап торганның соңында: «Әй, юк эш илә булышасыз, юкка вакыт әрәм итәсез!», – дип әйтә торган булган. Һәм ошбу эш шәкертләргә күп тәэсир иткән. Һәр сабакның ахырында әһәмиятле улган бер мәсьәләне үткән сабакка караганда бу әһәмиятле дигән мәгънәне аңлатып сөйли торган улган. Шушындый рухи тәрбия Мәрҗанинең шәкертләренә күп тәэсир иткән. Мәдрәсәнең эчендәге шәкертләрнең үз ана телләрендә тасниф[9] эшләренә керешүләре, рус мәктәпләренә төркем-төркем кереп укулары, остаз вә хәлфәләргә ихтирам мәгънәсе бирелгән коллыкны ташлап, истикъляль[10] рухы илә

---

[1] Мәҗмугъ – барлык.

[2] Гайн – бөтенләй.

[3] Галәбә итеп – җиңеп.

[4] Мөтәсаувирмы – сурәтләүчеме.

[5] Кашында – *монда:* алдында.

[6] Зан итеп – уйлап.

[7] Иҗтиһад иткән – тырышкан.

[8] Иштигален – шөгыльләнүен.

[9] Тасниф – китап язу.

[10] Истикъляль – бәйсезлек.

мөдәррис вә мөдирләреннән гомуми бер кыям[1] илә үз хакларын таләп итүчелекләре Мәрҗани шәкертләренең ни дәрәҗәдә остазларының тәрбиясенә муафыйк[2] чыкканнарын ачык күрсәтәдер. Мәрҗани мәдрәсәсе эчендә төрекчә җәгърафия, тарих вә гайре[3] гыйлемнәр вә голүме исламия илә чыннан иштигаль итүчеләр күп улган. Мәдрәсәдә гомуми кыям вакытында илле-алтмыш чана извозчиклар мәдрәсә төбенә килеп туктагач, шәкертләр ашыгычлык илә нәрсәләрен мәдрәсәдән чыгара һәм чаналарга төйи башлаганнар. Шулвакыт бәгъзе берләренең көррәи әрыз[4] сурәтләре (глобуслары), лампалар илә бергә кар башына утыртылып торган икән. Галимҗан хәзрәт һәм көн буе мәдрәсәләреннән бу шәкертләрне озата килүчеләр: «Әнә йиреңез», – дип мыскыл итеп әйтә торган булганнар. Бу эшләр ул мәдрәсә шәкертләренең бер-берсеннән никадәр мәсафә[5] илә ерак улуларын күрсәтмимени?

Ошбу хәлләрне мөляхәзә иткәннең соңында[6] адәм углы югарыдагы сөальне бирергә дә оялыр. Яки ничек тә икенче бер гыйбарәгә әйләндереп, «Ни өчен Мәрҗани үзенең бундый тәрбиясен сәясәтләр астында каплап йөртте, ни өчен ачыктан-ачык эшләмәде?» – дип әйтергә генә калса калыр.

Болардан башка язган бәгъзе нәрсәләрем булса да, мәйданга чыгарырлык кадәр әһәмиятләре булмаганлыктан калдырдым. Дөрест, бу китергәннәремнең соңгы кыйтгасы хакында да бүген икенче төрле уйларга мөмкин. Чөнки Мәрҗани үзе Бохара тәрбиясен генә күргән кеше булганлыктан, ул тәрбиянең ноксанатын[7] белсә дә, аларны Бохара биргән мәгълүмат даирәсеннән артык китеп, ислях итә алмаган[8]. Ул түгел әле, аннан күп соң

[1] Кыям – баш күтәрү.
[2] Муафыйк – яраклы.
[3] Гайре – башка.
[4] Көррәи әрыз – Җир шары.
[5] Мәсафә – аралык.
[6] Мөляхәзә иткәннең соңында – уйлаганнан соң.
[7] Ноксанатын – кимчелекләрен.
[8] Ислях итә алмаган – үзгәртә алмаган.

килгән габедләр[1]дә шулай иделәр. Ләкин мин әле бу йирдә бу мәсьәләләрне мөхакәмә итәргә[2] теләмим. Мин Мәрҗанинең миңа кечкенәлегемдә нинди тәэсире булганын сөйлим. Менә әле яңа гына мин бер убежденный «семинарист»[3] идем. Мин һаман шул муллалар һәм семинариядәге мөгаллимнәр персоналы арасында кайнап, муллалар дөньясыннан башка галимне белми, аның мулла бабайлары, Шафигъ ахундлары, Мәрҗаниләре илә генә саташып йөри идем. Шуны хәтергә алам, шунда Мәрҗанинең кодсиять[4] илә хакимлек иткәнен әйтәм. Бик хәтеремдә, бервакыт мин Шафигъ ахундны үземезгә кунакка алырга бардым. Кыш көне иде. Ахунд хәзрәткә ихтирам бик зур булганга, ул кешене кысрыкламас өчен, чананың читенә генә утырып бардым. Ул миңа күп сүзләр сөйләде. Ул үзе Мәрҗани белә хат язышкан һәм китаплары чыгу белә Мәрҗани бу ахунд хәзрәткә йибәреп торган. Ахунд хәзрәт шуларны сөйли-сөйли барып, миңа әйтә иде: «Углым, инде шул Мәрҗани кебек булсаң иде». Мин дә шуның артыннан ук эчемнән: «Йә Рабби, Мәрҗани кеби булсам иде», – дип, Ходайдан тели-тели бардым. Ул заман фәкать руханилардан гыйбарәт булган татар аңлы, зыялы гали сыйныф өчен иске авторитетларга игътибар итмәүдә белемне тарихи нигезгә корыр һәм шуңа карап, мөселманнарның дини вә мәдәни хәяттагы барышларыннан риза булмауда Бохараны, иске схоластиканы сүгү кеби эшләрдә Мәрҗани һәм аның тоткан юлы бер «недосягаемый образец»[5] иде. Мин үземне бер мисал итеп китердем. Идел буе татарлары арасында мондый мисаллар күп иде. Мәрҗанинең бөтен безнең хәяте иҗтимагый вә динемездәге зур фагыйлияте[6] һәм шуннан гыйбарәттер.

*Әхмәдзәки Вәлиди*

[1] Габедләр – бәндәләр.

[2] Мөхакәмә итәргә – тикшерергә.

[3] Кирилл хәрефләре беләя бирелгән.

[4] Кодсиять – изгелек.

[5] Кирилл хәрефләре беләя бирелгән.

[6] Фагыйлияте – эшчәнлеге.

*Мәкалә сәясәт эшлеклесе, тарихчы, публицист Әхмәтзәки Вәлиди (Вәлидов, 1890–1970) тарафыннан язылып, «Сөембикә» журналының 1915 елгы 6 нчы санында басылган.*

*Текстны басмага Гөлназ Хөснетдинова әзерләде*

## Юбилей көне

Мәрҗани куркынган сыманрак уянып китә. Сәгать йиде. Иртә намазы әллә кайчан үткән.

Ул, соңга калып торуына үкенебрәк: «Мин тагын шигый.[1] Иртә намазына да керми. Ах, шигый, шигый, фарызны да үтәми башлады инде, дип тиргәрләр, тагын бәйләнерләр», – дип сөйләнә-сөйләнә тора башлый. Мәрҗани сискәнеп китә. Ни күзе белән күрсен: аңа күренгән бар әйбердә дә ят төс, ят калеб. Аның уянган бүлмәсе кичә яткан бүлмәсенә бер дә ошамый, кичә моталәга кыла-кыла[2] йокыга киткән китап та юк, стена да зур күренми. Таныш булмаган шәмаилләр астында әллә нинди яшь кенә кешеләр рәсемнәре, тик аларның арасында ак мыеклы, кырган сакаллы, ябык чырайлы, ялан башлы бер карт кына күренә. Аларны күрүгә, Мәрҗани сикереп тора да: «Машалла, ни бу? Гаҗәп. Бу нинди бүлмә, бу рәсемнәр кемнәр? Берсе дә миңа таныш түгел. Кичә аларның берсе дә юк иде. Минем кичә моталәга кылып яткан китабым кайда соң? Бу шкаф нинди китаплар белән тулган? Бернәрсә белмим. Дөньяның асты өскә килгән, мин берсен дә сизмәгәнмен. Әллә мин үлем йокысы белән йокладыммы?» – ди дә тиз генә ишек кагарга тотына. Ишек тавышына чәч толымнары иңнәрен каплаган, зур мөлаем күзле, йолдыз кебек кенә калпак кигән ал күлмәкле кечкенә генә бер кыз килеп керә. Мәрҗанигә бу кыз да таныш түгел. Гадәт буенча, бер әби килергә кирәк иде. Ул Мәрҗани сүзгә керешкәнчә: «Сөекле бабам, бәйрәмең котлы булсын. Без сине бик сагынып көттек. Нинди матур булып торгансың», – дип, бабасының кулын үбә башлый. Мәрҗани ни әйтергә дә, ни уйларга

[1] Шигый – Коръәнне танып та, Мөхәммәд пәйгамбәр турындагы сөннине танымаучы дини мәзһәб тарафдары.

[2] Моталәга кыла-кыла – укый-укый.

да белми... Төшме, өнме икәнен дә аера алмый. Матур кыз чыга. Мәрҗанинең исе китә. Ул аңар бер сүз дә эндәшә алмый кала. Кинәт аның күзе көзгегә төшә дә тагын яшен тоткан кебек була... Ак сакаллы, маңлайлары җыерылып, йөзләре суырылып беткән кичәге карт юк. Көзгедә кап-кара сакаллы, тулып, нурланып торган йөзле 25 ел элек гайрәт белән дәрес әйткән 50 яшьлек Мәрҗани. Тагын карый, тагын карый. Көзгенең янына ук бара. Һаман шул, һаман шул. Тик матурлана гына бара... Шул арада аның стенадагы ак сакаллы, зур чалмалы бер рәсемгә күзе төшә. Атылып аның янына бара. Караса, нәкъ кичәге Мәрҗанинең үзе. Кискән дә куйган үзе. Аны күрү белән ул борчылып китә дә: «Ах, менә бу – мин, дөрес, мин, мин» – ди. Тагын көзгегә килә. Ләкин анда һаман шул матур чырайлы, кара сакаллы Мәрҗани. Бусы да – Мәрҗани. Аның Мәрҗани икәнчелегендә һич шик юк. Бу ике хәлне күреп, Мәрҗани ни эшләргә дә белми. «Мин, ахры, гакылымнан язганмын... Яисә төш күрәм, яисә саташам. Юкса, ни күрәм мин, бернәрсә дә аңлый алмыйм. Бу ни бу?» – ди дә, тагын ишекне кагарга тотына... Ишектән ак сакаллы, мәһабәт кенә бер карт килеп керә: «Кадерле атам! Олуг бәйрәмең котлы булсын, синең шатлыкны күрү белән бәхетлемен!» – ди дә, атасын кочаклап үбә. Мәрҗанинең тагын исе китә.

Кем соң син? Атам дисәң, мин танымыйм. Шулай да үзеңне төсмерлим. Әллә мин саташаммы?! Бернәрсә дә аңлый алмыйм, нинди бәйрәм белән котлыйсыз? Бу нинди бүлмә? Болар кемнәрнең рәсемнәре? Нигә мин яшь?

Кадерле атам, мин углың Әхмәд. Синең урынга имам, мөдәррис булган улың Әхмәд[1].

Минем имам, мөдәррис углым Әхмәд?! Ак сакалың?

Атам, сабыр ит... Сиңа азрак аңлашылмаган нәрсә бар. Син безнең белән 25 елдан соң күрештең... Минем сакалым агарды. Син шулай ук яшәрдең. Ачык әйтәм, син 25 ел элек үлгән идең, аны хәтерлә. Бүген үз бәйрәмеңә уяндың. Бүген бөтен татар баласының авызында, күңелендә синең матур исемең... Үлгәнгә 25 еллар үтеп китсә дә, син елдан-ел яшәрә бардың. Хәзер инде

[1] Әхмәд – Беренче Җамигъ мәчетендә имам-хатыйб, мәдрәсәдә мөдәррис булган улы Әбел Габбас Борһанеддин Мөхәммәд.

нинди матур, нинди ямьле, яшь булып торгансың... Бүген татар матбугаты сине гарешкә күтәрә[1] ...

Газиз балам, Әхмәд, бу матур сүзләрең көнемдәме? Нинди татар матбугаты дисең... «Тәрҗеман»мы?

Көнеңдә, кадерле атам, көнеңдә. Хәзер инде бер Казаныңда унлап гәзитә, журнал бар. Меңнәр белән санарлык татар телендә язылган китаплар.

Рәсемнәр?

– Аларның һәркайсы татар әдәбиятында, матбугатында зур эш эшләгән мөхәррирләр, әдипләр, шагыйрьләр..

Газиз балам, Әхмәд! Алар кайдан килсен, рус әдәбиятын әйтәсеңдер?

Юк, атам, юк. Барысы да татарныкы... Мин сиңа кыска гына алар хакында әйтим дә, матур татар дөньясына чыгыйк инде. Сине балаларың сагынып көтәләр... Менә бу карт рәсем сиңа азрак таныш булырга тиеш. Ул 30 еллар артык «Тәрҗеман» гәзитәсе чыгарып, бу ел гына бездән аерылган Исмәгыйль бабамыз[2]. Менә бу кара сакаллысы үзенең күп мәктәп, китаплары, халыкка хезмәте белән мәшһүр унъеллык гәзитәнең баш мөхәррире *Һ*. Бу үзеңә мәгълүм бит... Ахун – аның углы. Халык хадиме. Гәзитәсенең баш һәм иң эшлекле мөхәррире *F* ... Менә бу татарның зур әдибе. Аның 30 лап әдәби әсәре бар. Татарга әдәбият нигезен салган һәм тел биргән кеше *G*. Менә болары – яшь мөхәррирләр, шагыйрьләр һәм драматурглар... Әнә теге шкафта аларның әсәрләре. Шул мөхәррирләр, шагыйрьләр үзләренең үткен каләмнәре белән сине тәкъдир итеп, гәзитә-журналларын да сиңа багышлап чыгаралар. Алар синең бөтен әхвалеңне, бөтен эшләреңне сине күрмәгән аңлы татар балаларына көзге үтәли күрсәтәләр.

Минем әсәрләрем кайда соң?

Алар хәзер китапханәләрдә. Алар карт яфрак төслерәк булып калдылар, искерделәр. Синең чәчкән орлыклардан үскән алма

---

[1] Гарешкә күтәрә – олылый.

[2] Тәрҗеман» – 1883–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) төркитатар телендә чыккан сәяси, фәнни һәм әдәби газета. Аның нашире һәм мөхәррире – Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914)

агачлары йитеште инде. Әсәрләрең искерсә дә, үзең яшәрә генә барасың... Хәзер инде уңгай эшлекле варисларың, татар балаларының күрсәткән эшләрен үз күзең белән күрәсең. 25 ел эчендә нинди яшәреп, матур булып тугансың. Тагы шулкадәр вакыттан соң уянасың, яшь егет булып йитәрсең... Чыгыйк инде, кадерле атам. Балаларың зарыгып көтәләрдер.

Гакыллы балам, мине кем көтсен? – димен. – Мине, шигый, кяфер, дип өреп калучылар, фәләннәр күптер бит әле.

Кадерле атам, инде аларның берсе дә юк. Алар хәзер көлкегә генә зикер ителәләр[1]... Ул вакыттагы «Карагыз әле, карагыз, шигый, динсез Мәрҗани» дигән һөҗүмнәр урынына, «Яшәсен безнең рухани атамыз, яшәсен эшлекле бабамыз Мәрҗани!» дигән матур тавышлар ишетерсең.

Сартларның җыелышып бүдәнә[2] сугыштырулары төсле Кышкари, Бохари, Мәчкәри хәзрәтләрне өенә чакырып, үзара талаштырып кызыкланган теге йонсыз таз Бари исәндер бит? Әле дә шулаймы?...

Атам, хәзер инде бүдәнә сугышлары бетте. Кышкариның исеме генә. Йонсыз Бари да юк... Шул арада иң элек күренгән ал күлмәкле матур кыз бер кочак гәзитә-журналлар күтәреп бүлмәгә керә: «Сөекле бабам, синең зур бәйрәмеңне котлап чыгарылган гәзитә-журналлар!» – ди дә көлеп, оялып кына бөек бабасына карап тора... Әхмәд: «Кадерле атам, бу – синең заманда «Шәрхе Габдулла»[3] укып йөргән углым Камилнең кызы. Хәзер гимназиянең икенче классында бик күңелле укып йөри. Ул сине бик сагынып көтте. Синнән сөйдерәсе киләдер инде!» – ди. Мәрҗани, бер кулы белән гәзитә-журналларны алып, икенче кулы белән кызының чәченнән сөя... Гәзитә-журналларның һәркайсында үз рәсеме һәм үзенең тәрҗемәи хәле. Эшләгән эшләре хакында энәдән йебенә кадәр язылган мәкаләләр күрә. Ул матур тәмле итеп, татар телендә язылган бер кочак әйбергә исе китә,

[1] Зикер ителәләр – телгә алыналар.

[2] Бүдәнә – бытбылдык.

[3] «Шәрхе Габдулла» – дәреслек. Тулырак мәгълүматны Ягъкуб Хәлилинең «Шиһабетдин Әл-Мәрҗани хәзрәтләре» исемле мәкаләсенә язылган аңлатмадан карагыз.

анда язылган нәрсәләрне йотып укый.

Әхмәд, газизем, бу нинди гәзитә-журналлар? Язучылары кемнәр? Безнең татар балалары чыгара моны? Ник соң? Мин бер дә ышана алмыйм.

Татар балалары, кадерле атам... Сезне җыеп сугыштыручы, дин бозучы дип теңкәгә тигән татар балалары чыгара. Әле боларның барысы да, – тик Казан гәзитә-журналлары. Болар гына түгел. Күп, тагын күп. Һәммәсен күрерсең әле...

***

Мәрҗани яңа татар дөньясы һәм гәзитә-журналлар һәм аларның мөхәррирләре белән таныша. Бу төн татар әдәбиятын үз күзе белән күрә. Ул һәммә йирдә өмид, матур киләчәк хис итә. Инде бармак төртеп күрсәтүчеләргә очрамый. Тик кая гына барса да, алкышлар белән каршы алына... Бар йирдә яңалык, матурлык, тик мәсҗеде генә бераз караланган, искерә төшкән.

***

Мәрҗани балалар кичәсенә, клубка дәгъвәт ителә.[1] Ул кичәдә аңкып торган хәятне, киләчәк татар дөньясының өмидле буыннары булган ирләр, кызлар катнаш балалар көтүен күреп хәйран була. Күбәләк кебек киенешкән матур татар балаларын ул күреп туя алмый.... Шул матурлык эчендә аның канына сеңгән Печән базар татарлары, әфьюн белән кибешкән, мөгаләта[2] белән бар гомере үткән, бөтен вөҗүдләреннән[3] кабер исе аңкып торган иске муллалар, мөдәррисләр күренеп, үткәндәге ямьсез, күңелсез хәлләренең һәммәсе бер-бер артлы агып-агып китәләр... Пәрдә ачыла, яшь татар балалары бердәмләп тә, күмәкләп тә сәхнәгә чыгып җырлыйлар, укыйлар. 6–7 яшендәге бер кыз бала саф матур тавыш белән «И туган тел»не җырлый. Мәрҗани шатлык вә дулкыны эчендә бөтенләй югала. Татарның яңа тормышына сихерләнеп, кичәнең кайчан беткәнен һәм үзенең кайчан өйгә озатылганын да тоймыйча кала.

[1] Дәгъвәт ителә – чакырыла.

[2] Мөгаләта – ялгыштыру, буташтыру.

[3] Вөҗүдләреннән – яшәешләреннән.

Ул, өенә кайтса да, һичбер нәрсәне төпләп, ныклап уйлый алмый. Ни әйтергә, ни уйларга гаҗиз булгач[1]: «Минем белән бар гомерләрене талашып үткәргән хәзрәтләр, муллалар кайда соң? Кая гына барсам да бармаклары белән тотып, шигый дип кычкырып кала торган Казан татарлары кайда? Бу мөхәррир, шагыйрьләр, бу меңнәр-меңнәр татар телендә язылган китаплар кайчан туганнар? Машалла, 6–7 яшендәге күбәләк кебек татар балалары үзләренең телләре, милләтләре хакында сөйлиләр, укыйлар... Рух, хәят, өмид... Илаһым нинди матур дөнья, нинди күңелле! Ничә еллар гына элек якты йөзле бер татар күрергә тилмергән кеше – бүген миллионлап татар авызында мин...»

Шул сүзләрне әйткәндә, Мәрҗанинең яшәрүе күңеленә төшә дә тагын көзгегә килә. Ул һаман шулай матур җырлый. Тулган йөзле... Ул үзенең төсенә карап туя алмый.

Ишектән кергән кызчыгы аңар килә дә: «Сөекле бабам, бәйрәмең нинди матур үтте инде. 25 елдан соң матур егет булырсың, без тагы сагынып, зурлап, сине каршы алырбыз... Сиңа, бабакаем, тәмле йокылар телим, хуш бул!» – ди дә бабасының кулын үбеп чыгып китә. Мәрҗанинең керпекләрендә талганлык хис ителә...

*Шәһид Әхмәдиев*

*Әсәр язучы, җәмәгать эшлеклесе Шәһид Әхмәдиев Гыймадетдин улы (1888–1930) тарафыннан язылып, 1915 елда «Сөембикә» журналының 6 нчы санында басылган.*

*Текстны басма өчен Эльмера Галимҗанова әзерләде*

[1] Гаҗиз булгач – аптырап калгач.

## Шиһабеддин әл-Мәрҗани хакында фикерләр

Туганына 100 ел тулу мөнәсәбәте белән безнең яд итә торган[1] затыбыз дамелла[2] Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләре бер олуг хәзрәт булган. Ул диянәтле[3], истикамәтле[4], гарәпчәгә бик оста галим, мосанниф[5], икътисадка ригаяле[6], байларга илтифатсыз[7], купшы, күркәм, сәламәт, батыр һәм бәхетле булган. Ләкин Мәрҗани хәзрәтләрен бу сыйфатлары белән генә яд итеп мактасак, аз булачак. Без, әлбәттә, аны бу сыйфатлары белән дә мактыйбыз. Шуның өстенә, без ул хәзрәттә халыкка файдалы, хосусән,[8] хатын-кыз дөньясына файдалы нәрсәләр дә табарга телибез.

Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләрен хатын-кыз дөньясына һич илтифат итмәгән, хатын-кыз таифәсенең[9] ирексезлеген игътибарга алмаган вә алар өчен һич тә борчылмаган диясебез килми.

Без Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләренең туганына 100 ел тулу мөнәсәбәте белән төрле фикер вә төрле тел белән мактаучыларны күрдек. Гаять этрафлы булган Мәрҗани хәзрәтләрен һәркем үз күзе белән карый, аның хакында һәркем үз фикерен алга сөрә.

Мәсәлән, дамелла Галимҗан Баруди[10] Мәрҗани хәзрәтләренең туганына 100 ел тулу мөнәсәбәте белән язган мәкаләләрендә аны дини вә каләме юлларда үрнәккә алырлык, күбрәк чагында имам Әгъзам мәзһәбе[11] белән гыйлем кылучы, файдалы китаплар язучы, гыйбадәт кылучы, күп Коръән укучы, күп зикер тәсбих әйтүче[12] дип телгә ала.

---

[1] Яд итә торган – искә ала торган.

[2] Дамелла – укымышлы зат.

[3] Диянәтле – динле.

[4] Истикамәтле – намуслы.

[5] Мосанниф – китаплар авторы.

[6] Ригаяле – игътибарлы.

[7] Илтифатсыз – әһәмият бирмәүче.

[8] Хосусән – аеруча.

[9] Таифәсенең – җәмәгатенең.

[10] Галимҗан Баруди (1857–1921) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе.

[11] Имам Әгъзам мәзһәбе – Имам Әгъзам Әбү Хәнифә Ногман бине Сабит бине Зута әл-Фариси (699–767, һиҗри 80–150) – бөек ислам галиме, дүрт сөнни мәзһәбнең берсенә нигез салучы. Әбү Хәнифә мәзһәбе Мөхәммәдтән (с.г.в.) алынган белемгә нигезләнгән.

[12] Күп зикер тәсбих әйтүче – Аллаһны искә алучы.

«Йолдыз» мөхәррире Һади әфәнде Максуди[1]:

«Без бунда 25 сәнәләр[2] мөкаддәм[3] аның вафатыннан соңра күргән косурларны[4] ул бездән өч чарик[5] гасыр элек күрмеш», – ди. Димәк, осуле тәгълим[6] вә тәдрис[7] белән иштигаль иткән[8] Һади әфәнде Мәрҗани хәзрәтләрен шул ягы белән карый. Һади әфәнде Мәрҗани хәзрәтләрен: «Гомумдиния вә фөнун дөньявия[9] хосусларында Русиядә фәсыйх бер өслүбтә[10] гарәби китаплар тәэлиф кылучы[11] фазыл[12] Курсавидан[13] кала улдыр», һәм: «Безнең йортта 13 нче гасыр һиҗринең мөҗәддиде[14] ул булмыштыр», – дип мактый.

Г. Баттал[15] әфәнде Мәрҗани хакында язган мәкаләсен «Мәгънә вә хакыйкать эзләүче галим» сәрләүхәле[16] мәкаләсенең эчендә «Мин Мәрҗанинең «Кәлям»га каршы ачкан сугышын[17], гыйлем вә

[1] «Йолдыз» мөхәррире Һади әфәнде Максуди (1868–1941) – педагог, тел галиме, нашир. 1906–1918 елларда «Йолдыз» газетасының нашире һәм мөхәррире.

[2] Сәнәләр – еллар.

[3] Мөкаддим – элек.

[4] Косурларны – кимчелекләрне.

[5] Чарик – чирек.

[6] Осуле тәгълим – укыту ысулы.

[7] Ысулы тәдрис – дәрес бирү.

[8] Истигаль иткән – шөгыльләнгән.

[9] Фөнун дөньявия – дөньяви фәннәр.

[10] Фәсыйх бер өслүбтә – әдәби стильдә.

[11] Тәэлиф кылучы – язучы.

[12] Фазыл – камил.

[13] Курсави – Курсави Габденнасыйр Ибраһим улы (1776–1812), мәгърифәтче, дин галиме.

[14] Мөҗәддиде – новаторы, яңалык кертүчесе.

[15] Г. Баттал – Баттал (Сәетбатталов) Габделбари Габдулла улы
(1880–1969), тарихчы, филолог, журналист, иҗтимагый-сәяси эшлекле.

[16] Сәрләүхәле – исемле.

[17] «Кәлям»га каршы ачкан сугышын – «Хизәмәт әл-хәвәши ли-идәхәт әл-гамәви» («Гаделлекне томалаучы пәрдәне алу өчен шәрехләүләр җыентыгы» (1889) китабында Мәрҗани дини спекуляциягә нигезләнгән кәлям гыйлеменә каршы чыга, илаһият галимнәренең кайбер фәлсәфи төшенчәләрне урынлы кулланмауларын күрсәтә, дини догмалар белән фәлсәфә арасында катгый бүленеш барлыгын яклап чыга.

иҗтимаг[1] тарихымызда бик мөһим урын тотарга тиешле бер хезмәт, дип беләм», – ди. Һәм: «Мәрҗани хәзрәтләре җәсүр[2] бер игътиразчы[3] вә хакыйкать эзләүче бөек бер бахисдыр[4]», – ди.

Гыйсмәти әфәнде[5]: «Мәрҗани коллык дәверенә хәтем биреп[6], фикердә хөрлек дәверен башлады», – дип бара. «Ул коллык тормышының дөрес түгеллеген, дине ислам рухына бөтенләй хилаф[7] идекен күрсәтергә керешде», – ди. Шул ук Г. әфәнде дүрт мәзһәбкә вә дүрт мәзһәбнең берсенә кереп бикләнүне Мәрҗани гаепләде, дип күрсәтә.

Имам мулла Кәшшаф Тәрҗемани[8]: «Шәригать, исламия әдилләи[9] катгыян[10] ки бина кылындыкын[11], Аллаһның шәригатендә рәи[12] вә фикер илә тәсаррыф итәргә[13] һичкемнең хакы булмадыкын, «шәригать илә хикмәт «хакыйкать» исемле бер анадан туган игез балалар» идекен ачык вә катгый дәлилләр илә (Мәрҗани) исбат итте», – ди.

«Тәрҗеман», Мәрҗани хәзрәтләренең үлгән хәбәрен алгач: «Мәхрүм мосанниф[14] вә мөдәрриснең нам[15] вә шөһрәте Русия, Урта Азиянең һәр тарафына җәйрәп, җөмләмез өчен багыйсе ифтихар[16]

---

[1] Иҗтимаг – гомум.

[2] Җәсүр – батыр.

[3] Игътиразчы – фикернең дөреслегенә дәлилләр сораучы.

[4] Бахисдыр – бәхәсчедер.

[5] Гыйсмәти әфәнде – Гыйсмәтуллин Габдулла Төхфәт улы (1883–1938), журналист, сәясәт эшлеклесе.

[6] Хәтем биреп – тәмамлап.

[7] Хилаф – каршы.

[8] Кәшшаф Тәрҗемани – Тәрҗеманов Кәшшафетдин Кыяметдин улы (1877–1943), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин гыйлеме белгече.

[9] Исламия әдилләи – исламият дәлилләре.

[10] Катгыян – тәмам.

[11] Бина кылындыкын – төзелүен.

[12] Рәи – караш, фикер.

[13] Тәсаррыф итәргә – идарә итәргә.

[14] Мосанниф – китап авторы.

[15] Нам – исем.

[16] Багыйс ифтихар – мактануга сәбәп.

улдыгы кеби, вафатыннан сәбәп дәхи[1] җөмлә мөтәэссир улачакдыр», – дигән икән. Шул ук «Тәрҗеман» Мәрҗанинең вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте белән язган мәкаләсендә: «Әбелгази Баһадир хан[2] шәрык вә шималь төрекләренең беренче мөәррихе булса, Шиһабеддин Мәрҗани дә икенчесе гад улынмак лязимдер[3]. Яздыгы тарихта кулландыгы «лисан» шималь төрекләренең лисане әдәбиләренә нәмүнә улмас исә[4] дә, әсас[5] улдыгы инкяр улынмас. Ул вакытның голямасы[6] арасында «газета» вә «матбугат» кадерен аңлаян анчак[7] Шиһабеддин хәзрәтләредер», – дигән.

Исмәгыйль Габди[8] әфәнде: «Мәрҗани хәзрәтләре үзе сау чагында тәкъдир ителмәде. Аңламас вә мөтәгассыйб[9] кешеләр тарафыннан шелтә кылынды, инде хәзер дә аңладык, бүгенге көн инде Шиһабеддин хәзрәтне бөтен милләтемез даре хатир иттерә дә[10] тәшәккер[11] вә сәламнәрен юллап, рухы пакьләренә бөек вә олугларымыздан башлап та сабыйларымызга кадәр хәер-дога кылу белән үзләрен бәхтияр[12] саныйдыр», – ди.

Яшь мөәррихемез Зәки Вәлиди[13] әфәнде:

«Мәрҗанинең яңа мәдәни хәрәкәтемезгә мөнәсәбәте» сәрләүхәле мәкаләсендә Мәрҗани зоһур ителгән[14] вакытларда Азиядa һәм Аурупада Мәрҗани кебек вә андан артык мөтәфәккирләр[15]

[1] Дәхи – тагы.
[2] Әбелгази Баһадир хан – Хива ханы (1645–1663), тарихчы.
[3] Гад улынмак лязимдер – дип саналу кирәктер.
[4] Лисан әдәбиләренә нәмүнә улмас исә – әдәби телләргә үрнәк булмаса да.
[5] Әсас – нигез.
[6] Голямасы – галимнәре.
[7] Анчак – бары тик.
[8] Исмәгыйль Габди – Исмәгыйль Габитов, (1890–?), җәмәгать һәм дин эшлеклесе.
[9] Мөтәгассыйб – кире.
[10] Хатир иттерә дә – искә ала да; хәтер иясе, онытылмас.
[11] Тәшәккер – рәхмәт.
[12] Бәхтияр – бәхетле.
[13] Зәки Вәлиди (1890–1970), башкорт халкының милли азатлык хәрәкәте җитәкчесе, тарихчы, тюрколог.
[14] Зоһур ителгән – күренгән, мәйданга чыккан.
[15] Мөтәфәккирләр – фикер ияләре.

зоһур ителгәнен күрсәтә. Ул вакытларда мөтәфәккир мөселманнардагы тынычсызлыкның Америка табылуыннан, Сүәеш каналы[1] ачылуыннан икәнен аңлата. Һәм күбесенең бу тынычсызлыктан котылыр өчен аларның бәгъзеләре халыкны пәйгамбәр гам заманына[2] кайтарырга тырышканнарын бәян итә. Дөньяның һәр йирендә генә түгел, нәфсе Бохарада да Мәрҗани фикерен сөйләүчеләр булганын белдерә. Сүз арасында: «Әгәр без үземезнең хәятымызда беренче мәртәбә зоһур иткән бу затларны алай зурга хисапласак, әдәби, дини, тарихи хәятымызда шулкадәр зәгыйфь, шулкадәр төссез сурәттә калырга риза булган булырмыз», – ди. Һәм ниһаять: «Без Мәрҗаниләрнең ихтият зоһурларына[3], кадим галим мәсьәләләренә канәгатьләнеп калачак түгелмез. Безнең алдымызда тагын зур әдәби һәм дини хәят тора. Бер мослихе дини[4] килеп чыгар, динемезне дөньяның һәммә мәдәни халыклары карап торырлык бер матур хәлгә китерер. Бер әдип килеп чыгар да, Русиядә төрек-татар кауменең милли мазыйсын[5], милли хиссиятен җанлы нәрсә төсле иттереп, алга чыгарып куеп, безне Яурупа алдындагы швед милләте хәленә китерер», – ди.

Фатих әфәнде Әмирхан[6] «Безнең хыялларда күләгәсе» сәрләүхәле мәкаләсендә Мәрҗанинең Әмирхан гаиләсе кашындагы[7] вә хосусан үзенең шәкерт вә мулла кандидаты чагындагы карашындагы гыйсмәтен[8] яза. Фатих әфәнде үз кашында Мәрҗанинең шәкертләр вә мулла кандидатлары кашында гаять зур вә мөкаддәс урын тоткан мосаннифлар рәтенә кергәнен вә алар рәтендә иң бәһале вә иң зур бер төймә булганын тасвир итә.

Ф. әфәнде Мәрҗани симасын[9] үзенә идеал итеп тота, үзендә

[1] Сүәеш каналы – Урта диңгез белән Кызыл диңгезне тоташтыручы кораблар үтеп йөри торган шлюзсыз канал.

[2] Пәйгамбәр Гам заманы – Мөхәммәд пәйгамбәр яшәгән заман.

[3] Ихтият зоһурларына – саклык белән мәйданга чыгуларына.

[4] Мослих дини – дин төзәтүче.

[5] Мазыйсын – үткәнен.

[6] Фатих әфәнде Әмирхан – Әмирхан Мөхәммәтфатих Зариф улы (1886–1926), татар әдәбиятының классик язучысы, публицист.

[7] Кашындагы – алдындагы.

[8] Гыйсмәтен – намусын.

[9] Симасын – төсен, *монда:* сурәтен, образын.

«Шиһабеддин хәзрәт шикелле имам булырга!» дигән кызыгу пәйда булганын аңлата.

Ф. әфәнде Мәрҗанинең олуг аталган мосаннифларга вә галим саналган мөдәррисләргә каршы күрсәткән шөҗагате кылмаясына[1] вә истихкакына[2] тәхсин кыла[3]. Ул Мәрҗанигә шулкадәр мәхәббәт итә ки, Мәрҗанинең шанын былчырату өчен язылган «Тәүших»ләрне[4] күргәч, Мәрҗанигә мәхәббәте арту гына түгел, ияләре Ишмөхәммәд мулла кебекләрнең битләренә төкерергә тели башлый. Ф. әфәндечә, Мәрҗани, 50 ел яки 75 ел элгәрерәк дөньяга килүе сәбәпле, фән вә шөҗагате мәдәниятенә канәгать итәрлек төгәл бер зат була алмый. Шулай иртәрәк килгәне өчен генә ул Яурупалылар кашында билиттифак[5] саналырлык бер фән кешесе булмый. Шуның белән бергә, Мәрҗани симасы вә Мәрҗани тибы «Милләтнең истигъдад[6] вә истикъмаленә[7] өмидне куәтләндерә, тәрбияли торган вә аңа юл күрсәтә торган йолдыз булып җылкылдый». Ниһаять, Фатих әфәнде: «Төрки әкъвамын[8] фәнгә истигъдад, фәнгә хезмәт дәрде, рухани шөҗагать юк, диючеләр ялганлыйлар. Алар булганнар! Шулай булгач, алар барлар да һәм булачаклар да», – ди.

И. әфәнде Бикколов[9] Мәрҗани шималь төрекләре кашында Бохараның дәрәҗәсен төшерүе вә аның әһәмиятен бетерүе белән һәм хатадан хали[10] мәртәбәсендә тәләкъкый ителгән[11] мосаннифларның хәлен белдерүе белән тәкъдир итә. Бу хәл шималь төрекләренең инкыйлаб вә тәрәкъкый дәверенә юл хәзерләү булып табылды, дип бара.

---

[1] Шөҗагате кылмаясына – батырлык эшләвенә.

[2] Истихкакына – хаклы булуын.

[3] Тәхсин кыла – мактый.

[4] «Тәүших»ләрне – «Бизәк»ләрне.

[5] Билиттифак – уртак.

[6] Истигъдад – булдыклылык.

[7] Истикъмаленә – киләчәгенә.

[8] Әкъвамын – кавымнарын.

[9] И. әфәнде Бикколов – Бикколов Ибраһим Җамалетдин улы (1884–1938), җәмәгать эшлеклесе, педагог.

[10] Хатадан хали – хатасыз.

[11] Тәләкъкый ителгән – каршы алынган.

Мәрҗанинең туганына 100 ел мөнәсәбәте белән бунда мәзкүрләрдән[1] башка да бик күп аның иң әһәмиятле вазифаларын күрсәтергә тырышалар. Якында нәшер кылыначак Мәрҗанинең «Тәрҗемәи хәле» китабында тагын күбрәк кешеләр катнаша. Анда тагын әтрафлырак мөляхәзәләр[2] йөртелә. Мәрҗани «Тәрҗемәи хәле»ндә: аның мосанниф, мөдәррис, галим, мәһабәт, тырыш, истикамәтле[3], чыдам бер хәзрәт булуыннан башка, борадәренең[4] кызы Зәйнәп ханым вә үз кызы Галия ханымнар тарафыннан аның өй эчендәге хәлләре дә бәян ителә.

Безнең күргән кадәремездә Мәрҗани хакында язылган фикерләрнең никадәр бер-берсенә башка икәнчелеге күренерлек булган булса кирәк. Дамелла Галимҗан хәзрәтнең аны диянәт вә гыйлем белән мактавы, Һади әфәнде Максудиның исляхчы мөгаллим вә мөдәррис, дип мактавы, Г. Баттал әфәнденең Мәрҗанине мәгънәви хакыйкать эзләүче, диюе, Гыйсмәти әфәнденең Мәрҗани коллык дәверенә хитам бирде, диюе, шуның соңында язган мелла Кәшшаф Тәрҗеманиның, әдилләи катгыягә бина ителгән шәригать исламиядә тәсаррыф йөртергә[5] һичкемнең хакы юклыгы бәянын Мәрҗанигә иснад кылуы[6], Исмәгыйль әфәнде Гаспринскийның[7] Мәрҗанине Әбелгази Баһадир хан рәтендә саналырлык мөәррих булуын вә аның газета укучы бер зат булганын бәян итүе, Исмәгыйль Габди вә Зәки Вәлидиләрнең дә без күрсәткән фикерләрне сөйләүләре вә буннан башкалар безне Мәрҗани хакында тагын бер ныклап уйланырга мәҗбүр итә.

Мадам ки[8] без ошбу мәкаләне хатыннарга махсус «Сөембикә» журналына язабыз. Шуның өчен без мәкаләбезне дә

[1] Мәзкүрләрдән – югарыда әйтелгәннәрдән.

[2] Мөляхәзәләр – фикерләр.

[3] Истикамәтле – намуслы.

[4] Борадәренең – туганының.

[5] Тәсаррыф йөртергә – идарә итәргә.

[6] Иснад кылуы – сылтавы.

[7] Исмәгыйль әфәнде Гаспринский – Гапринский Исмәгыйль Мостафа улы (1851–1914), язучы һәм җәмәгать эшлеклесе. «Тәрҗеман» газетасының нигезләүчесе, нашире һәм мөхәррире.

[8] Мадам ки – чөнки.

хатыннарга вә хатыннар хокукына караш ноктаи нәзарыннан үткәрергә телибез.

Шәех Мәрҗани галим иде, гыйлеме белән гыйбадәт кылучы иде. Ул исляхчы иде. Тәгълим вә дәрес ысулларын төзәтергә тырышты. Хәзрәт иде, хәзрәт кенә түгел, мосанниф та иде, бер мулла баш белән Озын Ибраһим кебек үзсүзле мөстәбәдләр[1] белән ярышты. Татарның хатадан хали санадыклары хәзрәт вә мөдәррисләрен өреп очырды. Ул мөәррих иде, татар тарихына нигез салды. Ул әквам төркиядән[2] фән әһеле чыгу мөмкин икәнен гамәлән[3] күрсәтте.

Шулай, болар бар да шулай.

Әмма Мәрҗани хатын-кыз мәсьәләсендә ни эшләде? Бу мөһим мәсьәләне ул игътибарга алдымы? Бу зәминдә[4] ул берәр сүз сөйләдеме?

Сөйләсә, кайда сөйләде? Ничек сөйләде?

Менә без шәех Мәрҗани хәзрәтләрен шул яктан да бер карап үтәргә тиешсенәбез һәм бу мәсьәләдә без ул хәзрәттә хәзерге карашларга зарарлы бер хәл тапмыйбыз.

Зарарлы хәл тапмау гына түгел, файдалысын табарга тырышабыз. Мәрҗанинең үз гаиләсе эчендә вә үз гаиләсенә якын мөнәсәбәттә булган Галия ханым вә Зәйнәп ханымнарның сүзләренә караганда, Мәрҗани хәзрәтләре хатын-кызлар алдында үзен күтәренке вә горур тотмаган. Ул аларның халәте рухияләрен[5] сизгән. Мәрҗани хатын-кызлар эчендә утырып, җиңел вә кызык сүзләр сөйләргә сөя, аларга үзенең мәгълүматыннан хәбәр бирергә тырыша. Аларга табигатьнең ләтафәт вә җәмаленнән[6] өлеш бирер өчен, аларны җәйнең матур чакларында сахраларга вә кырларга чыгара, мәдәният дөньясында да аларның хиссалары[7] барлыгын сизгәнлегеннән үзенең атлары

[1] Мөстәбәдләр – изүчеләр.

[2] Әквам төркиядән – төрки каумнәрдән.

[3] Гамәлән – эш белән.

[4] Зәминдә – нигездә.

[5] Халәте рухияләрен – рухи халәтләрен.

[6] Ләтафәт вә җәмаленнән – гүзәллек һәм матурлыгыннан.

[7] Хиссалары – өлешләре.

белән аларны урамнарда гиздерә икән.

Без Мәрҗани хәзрәтләрен хатын-кыз мәсьәләсендә ачык вә хәзерге заман халкына үрнәк итәрлек бер хәлдә булмауда тәмам мәгънәсе белән мәгъзүр[1] күрә алабыз.

Бу мәсьәлә гыйльми вә фәнни булуыннан артыграк мәгыйши[2] вә гыйльми булганга, Мәрҗани хәзрәтләре бигрәк тә гыйльми вә фәнни мәсьәләләр белән уграшканга[3], үзенең тәрбиясе вә гомере башыннан ахырынача Азиядә вә Азия ысулында булганга, Мәрҗанидән хатын-кыз мәсьәләсен мәтлуб рәвештә[4] хәл иттерүне көтмәк һич тә мөмкин түгел иде, дип әйтә алабыз. Һәм бөтен әфкяре[5] вә бөтен торышы хакканиять[6] вә хәятка юнәлмеш булган, коллык дәверенә хитам[7] биргән, иҗтиһад[8] заманы мөнкариз[9] түгел дигән газета вә матбугат укыган, фән вә шөҗагате мәдәния тибы булган, хакканиять хакы хөрмәте өчен һичкемнең исем вә шанына исе китмәгән, статуйлар, музыкалар, хатын була торып әллә ничә төрле тел белергә кирәгенчә иттилягъ[10] вә мәхәббәт белән караган шәех Мәрҗанинең хатын-кызга карашы хәзергәчә дәвам иткән истибдадка[11] ия булуын һичбер мөмкин күрә алмыйбыз. Шәех Мәрҗанинең иткән хезмәтләре ирләргә генә хосус түгел, ул – хатын-кызлар кашында да олуг вә мөхтәрәм кеше. Шәех Мәрҗани тарафыннан кылынган зарбәнең[12] тәэсире ирләрнең төзәлүенә генә түгел, хатын-кыз хәленең дә төзәлүенә үрнәк булырлык, дип барабыз.

---

[1] Мәгъзүр – гозерле.
[2] Мәгыйши – тормышчан.
[3] Уграшканга – шөгыльләнгәнгә.
[4] Мәтлуб рәвештә – теләгәнчә, соралганча.
[5] Әфкяре – фикерләре.
[6] Хакканиять – турылык, дөреслек.
[7] Хитам – бетү.
[8] Иҗтиһад – тырышлык.
[9] Мөнкариз – юкка чыккан.
[10] Иттилягъ – аңлау.
[11] Истибдадка – деспотизмга.
[12] Зарбәнең – һөҗүмнең.

Вә шуның өчен ошбу 1333 ел 7 нче рабигыль-әүвәлдә[1] туганына 100 ел булган шәех Мәрҗани хәзрәт хәзерге вакытта хатын-кызлар тарафыннан да косурсыз[2] ихтирам кылыныр вә киләчәктә хатын-кызлар да шәех Мәрҗанидән ирләр белән бертигез истифадә итәрләр[3], дип өмид итәбез.

*Г.М.Чыгътай*

*Мәкалә язучы, публицист, журналист Гафуров Галиәсгар Мөгыйн улы (Г.М.Чыгътай) тарафыннан язылып, «Сөембикә» журналының 1915 елгы 6 нчы санында басылган.*

*Текстны басмага Фәния Фәйзуллина әзерләде*

## Шиһаб хәзрәт

*Кирәк булса әйтеп бирим: ул шәп хәзрәт,*
*Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,*
*Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,*
*Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.*

*Г. Тукай*

I

Татарның «җаһилият[4] заманы». Татарның бөтен яктан чын наданлык диңгезенә күмелеп, үткәнне уйламый, хәзерне төшенми, киләчәкне фикер итми, рәхәт-рәхәт йоклаган вакыты. Татарстанның һичбер йирендә, һичбер йортында (вилаятендә)[5] чын белемгә таба кечкенә генә дә бер хәрәкәт юк. Чиксез киң һәм чамасыз гүзәл Ак Идел буйларында Кара Иделнең аргы тарафындагы матур гына Җәбәлстан[6] ягында, Казан арты вә башка урта вилаятьләрдәге татарлар тирән бер наданлык караңгылыгына күмелгән, һичбер якта чын хәят әсәре күренми. Барысы да нинди дер бер үзләренә махсус тормышта пыскый-

[1] Рабигыль-әүвәл – елның өченче ае исеме.

[2] Косурсыз – кимчелексез.

[3] Истифадә итәрләр – файдаланырлар.

[4] Җаһилият – наданлык.

[5] Вилаятендә – өлкәсендә.

[6] Җәбәлстан – Тау иле, тау ягы.

лар, ләкин яшәмиләр. Агай-энеләр хакында, гавам[1] тугрысында, әлбәттә, сүз дә әйтергә мөмкин түгел. Ил башлыклары үзләре шул абзый-мужиклардан күп баскыч артка китеп, боларны, мөселманлыкка дип, әллә нинди бер мәҗүсият чокырына таба өстериләр. Бөтен куркыныч, бөтен һәлакәт тә менә боларның – башлыкларның рәт халыктан да күп түбән булуында. Бөтен ил эшенә тәэсир итеп, абызларның[2] йөрәгенә ут ягып алуга, тугры юлга баруда күп тәэсир итәчәк абыз тутайлар – хатын-кыз сыйныфы шулай ук артка таба өстери, инде якынлаша башлаган һәлакәт чокырына бөтенләй үк барып җитүне куәтли, үзе сизмичә үк бөтен көчен шуңар сарыф итә, тәэсирен шул як өчен куллана. Ил башлыклары ул вакыттагы ислам галәменең иң арткысы, иң хыяляткә[3] чумганы, белем урынына әллә нинди чүпчар чәйнәргә өйрәтүче «Бохараи шәриф»кә барып, хыялят һәм әфьюният гыйлемнәренә чумып кайта да, монда халкы эчендә эшкә керешә, ягъни үз эшенә керешә. Һичбер якта бер өмид ялтырамый. Халык арасында чын белемгә таба беренче эзне салучы күренми. Әмма Бохарадан ел саен теге зур-зур чалмалы, яшел чапанлы тәбәррекләр[4], «кәттә» дамеллалар монда таба агыла. «Гыйльме мәхзәне»ннән[5] бик күпне тутырып, монда кайталар һәм эшкә тотыналар. Бөтен әтраф Бохари дамелла белән тула. Кайда гына карама, зур-зур чалма да төрле төстәге чапан, эчке Русия Бохараның копиясенә әйләнеп китә.

## II

Менә шул Бохарадан кайтучылар эчендә үзенең гыйлеме, фикере белән башкаларга караганда бер дә охшамаган бер шәхес – Шиһаб хәзрәт тә була. Ул да башкалар белән бергә бер үк Бохарада кайнаса да, үзендә булган ашкыну, чын гый-

---

[1] Гавам – масса.

[2] Абызларның – укымышлыларның.

[3] Хыяляткә – хыялларга.

[4] Тәбәррекләр – хөрмәтлеләр.

[5] «Гыйльме мәхзәне»ннән – «Гыйлем складыннан».

лемгә омтылу белән бергә, бөек истигъдад сахибы[1] булганлыктан, бөтенләй икенче рухтагы һәм икенче карашлы кеше булып чыккан. Ул чактагы гадәт буенча, Бохараның үзендә үк исем чыгарып кайткан кешене мондагы «кәттә» голяма мәҗлесенә чакырып, имтихан итү кебек сүз сорау гадәте булган. Мәрҗани монда кайткач, аны да Казанның зур голяма мәҗлесенә чакырып, бәгъзе бер батыррак дамеллалар аркылы сүз соратканнар. Мәрҗани, әлбәттә, бөтен хазируннарның[2] күзләрен туйдырырлык җаваплар биргән. Кайсыбер аңлыраклары Шиһаб хәзрәтнең көчле дәлилләренә шундук баш иеп, аны тасдыйк иткәннәр[3], аның фикерләрен куәтләгәннәр, дәлилләрен нигезле тапканнар, кайсылары артык каршы сөйләргә көчләре җитмәсә дә карышканнар, гыйнад иткәннәр[4]. Шулай да Шиһаб хәзрәт боларның барчасына бертигез зур тәэсир ясаган. Аның гыйлеме алдында баш бөгәргә мәҗбүр булганнар. Аның һәйбәте алдында кечерәйгәннәр, калтыраганнар. Шул мәҗлестән соң Шиһаб хәзрәттән мәхәллә халкы һәм берәр зур бай Казанның беренче мәсҗеденә иман булуын үтенеп, Шиһаб хәзрәт тә авылга кайтып, әткәсеннән рөхсәт алгач, Уфада имтихан кылынып, Казанның беренче мәсҗеденә «мөдәррисләр башлыгы» исеме белән имамлык лязименә[5] урнашкан. Менә шул вакыттан башлап, инде Шиһаб хәзрәт гыйльми эшләренә дә керешә башлый. Элек шул мәхәллә мәдрәсәсен ислях кыла[6], җәгърафия, тарих, тәфсир, хәдис кебек ул вакытта мәкруһ күрелгән[7] гыйлемнәрне мәдрәсә программы эченә кертә. Һәм шуннан соң үзенең береннән-бере кыйммәт гыйльми, тарихи әсәрләрен язарга да керешеп китә.

Ул күп еллар сузылган хезмәте мәдәнияттә әллә никадәр ифтиралар[8], чиксез-чамасыз бөһтаннар[9] күтәрә. Аңарга әллә

[1] Истигъдад сахибы – сәләт иясе.
[2] Хазируннарның – шунда булганнарның.
[3] Тасдыйк иткәннәр – раслаганнар.
[4] Гыйнад иткәннәр – каршы чыкканнар.
[5] Лявазименә – хезмәтенә.
[6] Ислях кыла – үзгәртә.
[7] Мәкруһ күрелгән – дин тарафыннан тыелган.
[8] Ифтиралар – яла ягулар.
[9] Бөһтаннар – ялган сүзләр.

никадәр ялалар ягалар. Әллә нинди Озын Ибрай исемендәге караңгы шәхесләр, башка татар муллалары белән уйнаган кебек, Мәрҗани белән дә уйнарга телиләр. Аны да уенчык итәселәре килә һәм Шиһаб хәзрәт аларның кызыктыруларына да, куркытуларына да илтифат итмәгәч, аны әллә нинди нигезсез җимерек дәгъвалар белән урыныннан да төшертеп торалар. Ләкин Мәрҗани, бөек Мәрҗани боларның берсенә дә илтифат итми. Аларның үзенең юлына корган вак-төяк үрмәкүч ояларын таптап, җимереп, үз юлында, үзенең гыйльми хезмәтләрендә дәвам итә. Аны шыйга[1] диләр, кызылбаш диләр, тагын әллә ниләр диләр... Ләкин үзенең идеалына, үзенең хезмәтенең бөеклегенә ышанган бер затка тегеннән көчсез куәтләрнең, мохит коллларының, замана муллаларының, мәгърур байларның төһмәте[2], яласы беркадәр генә булса да тәэсир итәчәкме? Башлаган бөек хезмәтен туктатачакмы? Һич!

Соңрак Мәрҗани хаҗ сәфәренә китә. Менә шул вакытта аң җәһәтеннән шактый үсеп килә торган төрекләр Истанбулда аны бөек гыйлем хадиме[3] иттереп каршылыйлар. Гарәби[4] әсәрләре аркылы аның белән танышып өлгергән төрек бөекләре Мәрҗанине Русия мөселманнарының бердәнбер фикерле галиме иттереп, аның белән гыйльми мосахәбәләр[5] ясыйлар. Үз татарлары тарафыннан сүгелгән Мәрҗани гыйлем әһелләрен тәкъдир итә башлаган, бәһали башлаган төрек табәкасы[6] тарафыннан зур ихтирам белән каршыланып, бөек хөрмәт белән озатыла.

Шиһаб хәзрәт, бу олуг сәфәреннән кайтканнан соң да, тарихи вә гыйльми хезмәтләрен дәвам иттереп, татарларга әллә никадәр кыйммәтле әсәрләр, гыйльми һәм тарихи хезмәтләр белән бергә байтак кына аңлы хәлфәләр-шәкертләр калдырып, бу хезмәт иясе дөньядан китә.

Нинди тулы, нинди мәгънәле хәят!

---

[1] Шыйга – шигый.

[2] Төһмәте – яла ягуы, гаеп ташлавы.

[3] Хадиме – хезмәткәре.

[4] Гарәби – гарәпчә.

[5] Мосахәбәләр – әңгәмәләр.

[6] Табәкасы – катлавы.

## III

Мәрҗани килгән вакытка, аны чолгаган мохиткә караганда, аңардан хатын-кыз хакында хәзерге мөтәфәккирләр карашын ук көтү, әлбәттә, урынсызрак. Ләкин ул башка мәсьәләләрдә шул чактагы хәвастан[1] күп югары торган кебек, хатын-кыз мәсьәләсендә дә үзенә мөнасиб[2] бер фикердә, хөррият тарафында булучылыгын гакыл белән генә тәхмин итү[3] дә читен түгел. Аның бер-бер артлы килеп киткән хатыннары белән мөгамәләсе, бигрәк тә беренчесе вафатыннан соң алган икенче хатыны Бибинәгыймәне бик сөйгәнлектән, әлбәттә, бер кәнизәк иттереп түгел, бер иптәш, бер сердәш, зур бер булышчы, камил инсан иттереп сөйгәнлеген хикәя итеп сөйлиләр. Шул балалар анасы – бигрәк сөекле хатыны Бибинәгыймә вафатыннан мөтәәссир[4] булганлыгын, чиксез кайгырганлыгын, зур бер иптәш югалтканлыгын Мәрҗани үзе дә «Мөстәфадел-әхбар»ында[5] сөйли. Аның хәзер дә Сафи хәзрәт никахында булган Галия исемле кызы – хәзерге заманда да охшашы табылуы читен булган бер галимә хатын. Аның Коръәне хафизә[6] булганлыгын да бик ышандырып сөйлиләр. Әгәр дә бу дөрест булса, ул – бәлки, татар хатыннары эчендә бердәнбер хафизәдер. Бу кызын Мәрҗани бик сөеп, башка балаларыннан күп алда тотканын, әллә нинди гыйльми серләр хакында аның белән сөйләшүен, мөзакәрә итешүен[7] дә сөйлиләр. Аның башка балалары – кызлары да, әлбәттә, арәт[8] остазбикәләр белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә үстеннәр. Габ-

---

[1] Хәвастан – җәмгыятьнең югары катлавыннан.

[2] Мөнасиб – яраклы, туры килгән.

[3] Тәхмин итү – чамалау.

[4] Мөтәәссир – тәэсирләнгән, кайгыга төшкән.

[5] «Мөстәфадел-әхбар» – «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдалы хәбәрләр») – Ш.Мәрҗанинең 1880 елларда тарихи чыганакларга нигезләнеп язылган хезмәте. Татар халкы тарихын беренче гыйльми өйрәнүгә багышланган. Китапның беренче томы – 1885, икенче томы 1890 елда Казанда басыла.

[6] Коръәне хафизә – Коръәнне күңелдән белүче (хатын-кыз).

[7] Мөзакәрә итешүен – фикер алышуын.

[8] Арәт – ахирәт.

дулла хәзрәт Апанай[1] никахындагы кызы да шулай ук галимә остазбикәләрдән, диләр. Гомумән, Мәрҗани үзенең бөеклегенә мөнасиб рәвештә хатын-кыз сыйныфын да олуглаган, аларны укытуны, әлбәттә, ул бик кирәксенгән, бик химая иткән[2], үзенең кызларын бик яхшы укытуы белән ул буны гамәлендә дә күрсәткән. Ләкин гомумгә үк кагылырга бер дә аның вакыты булмаган, чөнки аннан башка мәсьәләләр гаять күп, мөнкирләр[3] бик көчле, аларның барысын да егарга, дәлилләрен сындырырга, җимерергә кирәк булган. Икенчедән, ул чактагы халык эчендә, ул мохиттә бу мәсьәлә тугрысында хәзерге кадәр киңәеп китү дә, билгеле, бик читен булган, мохиттә буңар хәзерлек булмаган. Әмма, гомумән, Мәрҗани хатын-кыз хакында бөек ихтирамлы, аларның наданлыгы өчен чамасыз кайгыручы, аларны укытуны бик кирәксенүче бер зат булган. Мәрҗани кебек гакыл чишмәсе булган бер шәхеснең шулай булмавы үзе дә мөмкин түгел инде. Шуңар күрә ул безнең гомуми бөек атабыз, ирләргә бөек ата булган кебек, хатыннарның да мөхтәрәм аталары, ул гомумтатар милләте кашында бөек мөҗәддидлек[4] – реформаторлык урынын тота һәм тотарга тиеш. Шундый зур бер шәхеснең Русия татарлары эченнән чыгуы – безгә бөек шәрәф[5]. Менә шуның өчен дә бу аның тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән ясала торган бәйрәм – юбилей безнең гомуми бәйрәмебез булып, татар хатыннары да үзләренең бөек кешеләрен хәтерли белүләрен күрсәтергә, тавышларын гомуми матбугатта яңгыратырга тиешлеләр.

*Шәриф Хөсәенев. Казан*

*Мәкалә Шәриф Хөсәенев тарафыннан язылып, «Сөембикә» журналының 1915 елгы 6 нчы санында басылган.*

*Текстны басмага Фәния Фәйзуллина әзерләде*

---

[1] Габдулла хәзрәт Апанай – Апанаев Габдулла Габделкәрим улы (1862–1919), җәмәгать һәм дин эшлеклесе, нашир, педагог. Сәүдәгәр Апанаевлар нәселеннән.

[2] Химая иткән – яклаган.

[3] Мөнкирләр – ышанмаучылар, инкяр итүчеләр.

[4] Мөҗәддидлек – яңалык кертүче, новатор.

[5] Шәрәф – бәхет.

## Мәрҗанинең яңа мәдәни хәрәкәтемезгә мөнәсәбәте

Мәдәни халыкларның олуг бер кыйсеме[1] әле Русиядәге мөселманларга хайван тиресенә ябынып, чаңгылар белән вәхши хайваннлар кугып йөрүче халык дип карыйлар; икенче бер кыйсеме безне инде, бераз рус мәдәниятен исни башлаганымызны күреп, яз көне тирес башында мыжырдый башлаган кортларга охшаталар. Ягъни мәдәни халыклар алдында без чынлап ук саф дикар[2] (вәхши)ләрме, яки боларның бераз төзелә башлаганымы икәне әле мәсьәлә. Хәлбуки без инде үзебезгә чынлап ук аякка баскан бер халык дип карыймыз һәм аның [...] «тарихлы бер мәдәни хәрәкәт»ендә башлап барган Милюков[3], Гаспринский, Мәрҗани, Насыйри[4], Тукаевларына[5] бәйрәмләр, юбилейлар, хәтта йөзьеллык юбилейлар ясап маташамыз. Моның мәгънәсе шул ки, безнең яңа мәдәни хәятымыз шулкадәр микроскопически кечек бер нәрсә икән дә, аны чит адәмләр дикъкать илә караганда гына күрә алалар, әмма ул безнең үзебезгә зур булып та күренә ала. Һәм вакыйган безнең кечкенә генә юлбашчыларымыз булган Мәрҗаниләр, чит халыкларның олуг мәдәни эшче (деятель)ләре арасында күренерлек булмаса да, үзебез тәфтиш итеп күрә алмаслык дәрәҗәдә юк нәрсәләр дә түгел. Хәтта Мәрҗани һәм аның ибдәшләренең заманы безнең үземез җентекләгән вакытда бер тарихи дәвер булып та саналырга мөмкин. Гаспринский заманында без алдымызда олуг матур бер мәдәният барлыгын күреп кызыксындык, әмма андан элгәре бер вакыт бар иде ки, ул вакыт, мөселман мәдәнияте илә агуланган башка халыкларда булган кебек, бездә дә үз хәятымыздан, барышымыздан ничек

[1] Кыйсеме – өлеше.

[2] Дөресе: дикарь.

[3] Милюков – Павел Николаевич Милюков (1859–1943) – рус сәяси эшлеклесе, тарихчы, публицист. Рус либерализмы идеологы.

[4] Насыйри – Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыров (Каюм Насыйри; 1825–1902), татар этнограф-галиме, әдәбият белгече, XIX гасыр мәгърифәтчесе.

[5] Тукаевларына – Габдулла Мөхәммәдгариф улы Тукаев (1886–1913) – татар халык шагыйре, әдәби тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче.

кенә булса да бер канәгатьсезлек бар иде. Менә Мәрҗаниләрнең заманын бер дәвер дип хисаблаганда, аны шундый бер ризасызлык дәвере дип атарга кирәк. Бу дәвер безнең мәдәни хәятымызда әһәмиятсез бер нәрсә дә түгел, ошбу сәбәбдән Мәрҗани хакында халык тавышланган заманда ул дәвер һәм анда Мәрҗанинең роле хакында берничә сүз әйтеп китәргә тиеш дә.

Уналтынчы гасырның башлары тирәсендә сәяси хәлләрен яхшы юнәтеп алган Йаурупа өчен Америка ачылып, яңа бер сәүдә вә тиҗарәт мәркәзе[1] килеп чыгуы, дәхи соңынданрак Сүәеш каналы ачылып, Һиндстанның Йаурупа базары хәленә әйләнүене заманлардан бирле сәяси фетнәләр, мәдәниятсез күчмә халыкларның һөҗүмләре сәбәбле тәмам ябыккан, таланган мәдәни мөселман шәркын бәрде дә екды. Алгы Азиядән ага торган байлык, мәдәният елгасы икенче йирдән йибәрелеп, Йаурупа өстенә акды да, бөтен мөселман галәме кибеп корыды да калды. Унтугызынчы гасырның уртасында мөселман шәркының төрле тарафындан хәятның бу кадәр туң һәм үлтерә торган бер сурәтдә баруындан разый булмаган һәм ничек дә булса бу хәятны юнәлтүне уйлый башлаган адәмләр зоһур итде[2].

Русиядәге мөселманлар арасында бу эш Курсави[3] һәм Мәрҗаниләргә, әмма Һиндстанда Габделхәй әл-Ләкнәви, Рәхмәтулла Һинди, Садыйк Хәсәнханларга, Иранда Мирза Риза хан, Төркестанда Әбү Сәгыйд казый, Анабәк казый дигән кеби адәмләргә, Мисыр вә Гарәбстанда вәһаби мәсләгенә хөсне нәзар иткән[4] галимләргә төшде. Йаурупа голямасыннан Крымский[5],

---

[1] Тиҗарәт мәркәзе – сәүдә үзәге.

[2] Зоһур итде – барлыкка килде.

[3] Курсави – Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштиряк әл-Курсави (1776–1812), татар дин белгече, Нәкышбәндия тарикате шәехе, мәгърифәтче һәм фикер иясе.

[4] Хөсне нәзар иткән – уңай караштa булган.

[5] Крымский – Агафангел Ефимович Крымский (1871–1942), рус һәм украин тарихчысы, әдип, тәрҗемәче, шәрык телләре белгече, ислам белгече, тюрколог.

Вамбери[1], Голдсигер, Дозилар[2] унтугызынчы гасырда мөселманлар арасындагы хәрәкәтләрне язган урынларда безнең Русиядәгеләрдән башка йирдәге һәммә бу кыйсем мөселман мөтәфәккирләрен аермачык сөйләгәнләр. Бу кешеләрнең һәммәсендә галәме ислам өстендәге туңлыкны күреп, ислам интересын күзәтүче, моның өстенә, тагын мөселман кавемләрдән һәрберсе үз башына мөстәкыйль хәятын күреп, Азиягә күп сурәтдә үзләре мәнсуб[3] булган мәмләкәт вә милләтләр интересын караучы дип хисабларга мөмкин. Боларның һәммәсенең дә гомуми сыйфатлары мөселманларның соңгы хәлләре, мадди вә мәгънәви хәяты яхшылыкка таба бармаганын аңлау һәм бу эшнең бар мәнбәгы[4] да динне яңлыш аңлаудан килгән дип белүдән гыйбарәт иде. Ошбуның өчен болар әһле исламның хәле «иске замандагы матур сурәткә кайтарыр өчен» ислам диненең сыйфат бәхәсләре, каза намазларыннан башлап, та ашдан элгәре тоз кабу мәсьәләсенә кадәрге тәртибләрендә тәфтиш итеп пәйгамбәр (гайләйһиссәлам) заманындагы хәленә кайтарырга тырыша башладылар. Болардан һичберсенең дә Йаурупача мәгънәсе илә голүмдән, иҗтимагыятдән хәбәрләре юк иде. Ушандак[5] мөселман хәятының начарлыгына канәгатьләнүләре дә бу хәятны Йаурупа хәятына кыяс итү-итмәүгә карамый иде. Хосусән[6] безнең Русиядәгеләрнеке рус мәдәниятенә баглый булмаганын шундан күрергә мөмкин ки, бу кешеләрнең һәммәсе дә Бохарада өлгерде. Курсавилар да, Мәрҗани дә, башкалары да русның ни икәнен белмәсдән элгәре, бик яшь көйгә Бохарага китделәр. Шөбһәсез, Бохара, барган чорда, алар кашында бик яхшы тәэсир калдыргандыр. Ләкин ахырдан шул Бохарада торып, аларда баягы фикер ясалды. Ул вакыт Русиядән барган

[1] Вамбери – Арминий Вамбери яки Герман Бамбергер (1832–1913), венгр сәяхәтчесе, шәрык белгече.

[2] Дозилар – Рейнхарт Дози (1820–1883), голландияле шәрык белгече, ислам белгече.

[3] Мәнсуб – билгеләнгән.

[4] Мәнбәгы – чыганагы.

[5] Ушандак – шулай ук.

[6] Хосусән – бигрәк тә.

Бохара ыстудентлары[1] арасында бу фикердә йөрүче бер Курсави, бер Мәрҗани генә түгел иде. Мәрҗаниләр кадәр үк үткен фикерле усал Гариф бине Габдессәлам, Низамеддин Илһамилар бар иде, Хөсәен әл-Каргалы да шулар арасына кереп йөргән. Боларда ясалган фикернең һичбер чит тәэсир аркасында булмаганын Мәрҗанинең һәм аның рафикъларының[2] Бохарада чакда язган нәрсәләрендән ачык күререгә мөмкин.

Гариф 1848 ел Бохарадан атасы Габдессәлам хәзрәткә юллаган хатында яза: انا مشوش الحال لم نحصل بعدالاشيئا قليلا من القيل و القال وفات اكثر عمرنا ف التشويش و الاضطراب ... و لم يبق فى هذه البلدة (يعنى بخارا) من العلوم العقلية الا اسمه فيغترون بما هو لا مع السراب وليس لهم مقدمة واصلة الى حدالجزم و اليقين بل يبقون فى كل مرتبة حائرة من غير ترجيح احدالطرفين ... و اما العلوم الشرعية فلا اسم ولا رسم ولا طلل و ما انا الا لذلك قد كنت قاصدا وعازما فى جميع حالاتى سفراو تعربا من بلد فى طلب الرجال والركبان قلما يخلو عنهم الاقطار[3]

Низамеддин Илһами шул ук елны Бохарадан язган хатында әйткән: «Мөрәбби[4] юк, вилаятьләр сәхетлек[5], гыйлем косур табыбдыр[6]. Һәр китаб хашиясене[7], гәрчә ул хашия илә укылса да, бихасыйльрәк[8] уладыр. Мәга әннәһа ләйсәт мимма йәтәгалләка

---

[1] Дөресе: студентлары.

[2] Рафикъларының – дусларының.

[3] Мин аптыраштамын. Белем урынына аз-маз уйдырмалар гына хасыйль иттек. Вакытыбызның күпчелеге икеләнү вә аптырашта узды. Бу шәһәрдә (ягъни Бохарада) гаклый (рациональ) фәннәрнең исемнәре генә калган. [Мондагы галимнәр] хәтта чүлдәге рәшәдә булмаган (юк) нәрсәләргә мөкиббән киткәннәр. Тотрыклы һәм хак фикергә китерерлек дәлилләр аларда юк: һәр мәсьәләдә аптырашта калып, бер фикерне сайлый алмыйлар... Дин фәннәренә килгәндә, аларның исемнәре дә, җисемнәре дә калмаган. Мин аларны эстәп, галим кешеләрне күрәсем килеп, юлга чыгып шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрдем ләбаса. Хәер, юлчыларның (кәрваннарның) саны аз түгел (гарәп теленнән А. Сәлахов тәрҗемәсе).

[4] Мөрәбби – тәрбия итүче, кайгыртучы.

[5] Сәхетлек – аяныч хәл.

[6] Гыйлем косур табыбдыр – фән деградациягә дучар булган.

[7] Хашия – шәрехкә шәрех.

[8] Бихасыйль – нәтиҗәсез.

биһат-тәфәннен[1] ниятемез мөяссәр улган җайда осул вә һәндәсә вә нибәз минәл-һәйьәти[2] вә хәдис вә тәфсиргә гыйшкымыз бар. Вә фәүвәзна әмрина иләЛлаһ[3] гаҗәб күңелләремез мөтәзәлзәл бикарар[4] улыбдыр дип яза»[5]. Шундый ук сүзләр Хорасандан Мәрҗанигә язган хатында да мәгълүм.

Бу кешеләр үзләре һаман шундый ризасызлык, тәшвиш[6], изтыйрабда[7], әмма үзләре тәмам йиренә йиткереп, бөтен тирә-як ибдәшләрендән артык итеп үгрәнгән мөселман гыйлемендән нәразый[8], җәгърафия, тарих, риязият[9] вә гайреләргә гашыйк булганлар. Мөселман галәмендәге уку тәртибләрен яратмаганлар, ләкин үзләре ул хакда төпле бер нәрсә эшләүдән гаҗиз булганлар, ошбу сәбәбдән бөтен мәсләкләре ялгыз нәразыйлыкдан гыйбарәт булган диярлек.

Менә шул кешеләрдән байтакларына вә шул җөмләдән Мәрҗанигә соңындан Йаурупа хәлен күрергә тугры килде. Бу эш аларның игътикадлары[10] ныгуга һәм үз эшләренә тагын зуррак ихлас илә бирелүләренә сәбәб булды. Мәрҗани Йаурупа (үз истляхынча, аруфи) мәдәниятен ишетеп кенә белү түгел, бәлки франклар арасында катнашып йөреп белде. Ошбу сәбәбдән ул үзенә мәгълүм франклардан Радлов[11] һәм

---

[1] Мәга әннәһа ләйсәт мимма йәтәгалләка биһат-тәфәннен – гәрчә моның тирән белемгә мөнәсәбәте булмаса да.

[2] Нибәз минәл-һәйьәти – планиметриядән кайбер мәгълүмат.

[3] Вә фәүвәзна әмрина илә-Ллаһ – үзебезне Аллага тапшырып.

[4] Мөтәзәлзәл бикарар – тетрәнгән һәм аптыраган.

[5] Низамеддиннең дә, Гарифның да тәрҗемәи хәлләре «Асар», җилд 2, с. 267–274 ләрдә һәм «Мөстәфадел-әхбар», җилд 2 дә дәреҗ ителгәннәр.

[6] Тәшвиш – шикләнү.

[7] Изтыйрабда – аптырауда.

[8] Нәразый – риза түгел.

[9] Риязият – математика.

[10] Игътикадлары – ышанулары.

[11] Радлов – Василий Васильевич Радлов ( туганда кушылган исеме Фридрих Вильгельм Радлов; 1837–1918), чыгышы белән алманлы рус, шәрык белгече, тюрколог, этнограф, археолог.

Готвальд[1] вә гайре мөстәшрикъләргә кяфер дип генә түгел, «гыйльме күп булган урыс» дип карарга һәм рус мәдәниятен алмак өчен булмаса да, «мөселман хаҗәте өчен урысча әсәрләрдән истифадә итмәк[2]» өчен рус телен белү тиеш дип ышанырга үгрәнде. Яңа мәдәниятнең бәгъзе нәрсәләренә бик үлчәп кенә булса да «разый булды». Мәрҗанидән соң бу тип мөселман галимләре Йаурупа мәдәнияте белә якынрак танышкан нисбәтдә Әхмәдҗан, Җәмаледдин Әфгани[3], Габдүһ[4] вә Мирза Мөхәммәд Бакыйр – башкалар сурәтендә заһир булдылар. Бу соңгылар бөтен эшне дингә аударуда һәм яңа мәдәниятдән качмауда Мәрҗанилардән дәхи[5] үзгәрделәр.

Мәрҗанинең дә һәм икенче мәмләкәтләрдәге ул тип галимләрнең дә эшләре гомуммөселманга гаид булса да, югарыда әйтеп үтелгәнчә, һәр берсенеке үзләре мәнсуб[6] булган урынларга күбрәк һәм якынрак тигде. Мәрҗани аркасында башка мөселман галимләрендән бигрәк, безнең үземездә иске хәятның ярамаганлыгына ышану, дине исламга киңрәк карый белү, иске авторитетларга үлчәбрәк ышану кеби эшләр нык таралды. Бу хәлләр безне Гаспринский сүзләренә якын торырга хәзерләде.

Русиядәге төрек-татар кавеменең үткәндә һәм хәзерге вакыйгъдагы[7] гомуми нәрсәләре ни икәнен, хайви[8] интереслары, уртак тарихлары, уртак әдәбиятлары күпме көчле икәнен яхшы ук, якындан торып белгән адәмләр булырга тиеш ки, безнең Каюм, Тукай, Мәрҗаниләремезне башка милләтләрнең

---

[1] Готвальд – Иосиф (Йозеф) Фёдорович Готвальд (1813–1897), атаклы шәрык белгече, гарәп һәм фарсы телләре белгечлеге профессоры.

[2] Истифадә итмәк – куллану.

[3] Җамалетдин Әфгани (1839–1897) – дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, мөселман ислахчылыгы идеологы.

[4] Габдүһ – Мөхәммәд Габдүһ (1849–1905), мисырлы, дин галиме, мөселман ислахчылыгы идеологы.

[5] Дәхи – шулай ук.

[6] Мәнсуб – билгеләнгән.

[7] Вакыйгъдагы – булган.

[8] Хайви – хайвани.

хәяте мәдәнияләре тарихындагы Ломоносов[1], Пушкин, Карамзин, Лютерлары илә тиңләргә ашыгу бөтенләй мәгънәсездер.

Чит милләтләрнең әдәби, тарихи һәм дини хәятларында бу кешеләрнең заһир булулары алар тәкяммел иткәч[2], төрле ихтиляфлар бер йиргә җыелгач булды. Бу кешеләрдән соң ул милләтләргә һәммә әдәбия, тарихи, дини бабда төрле ботакларга таралып йимешләнергә генә калды. Әгәр без үземезнең хәятымызда беренче мәртәбә зоһур иткән бу затларны алай зурга хисабласак, әдәби, дини, тарихи хәятымызда шулкадәр зәгыйфь, шулкадәр төссез сурәтдә калырга риза булган булырмыз. Без әдәби хәятымызда халык әдәбияты һич булмаган, матур сүзгә бик ярлы булган Казан татары илә сартка кәнагатьләнеп, тарих бабында Мәрҗанинең летописенә, дини исляхат[3] бабында шул ук Мәрҗаниләрнең ихтияте зоһурларына, кадәме галәм мәсьәләләренә канәгатьләнеп калачак түгелмез, безнең алдыбызда тагын зур әдәби һәм дини хәят тора. Бер мослихе дини[4] килеп чыгар, динемезне дөньяның һәммә мәдәни халыклары карап торырлык бер матур хәлгә китерер, аның җәмигайин (обряд[5])ларын инсанга да, Аллаһыга да сөекле бер сурәткә куяр. Бер әдиб килеп чыгар да, Русиядәге төрек-татар кавеменең милли мазыйсын[6], милли хиссиятен җанлы нәрсә төсле итдереп алга чыгарып куеп, безне Йаурупа алдындагы швед милләте хәленә китерер. Ошбуның өчен без Мәрҗаниләрнең, Насыйри һәм Тукайларның тарих, дин, әдәбият бабындагы хезмәтләренә беренче язгы җылылар дип генә карыймыз, югыйсә эш март аенда кар эри башлаганга карап, сабан күтәреп чыккан кабилендән булыр. Дөрест, Мәрҗани безнең Идел буе кеби китабка бик ярлы наданлык сахрасы эчендә торса да, Бохарадан алып кайт-кан нәрсәләре һәм соңындан,

[1] Ломоносов – Михаил Васильевич Ломоносов (1711–1765), рус энциклопедист галиме, физик, химик, астроном.

[2] Тәкяммел иткәч – җитешкәч.

[3] Исляхат – реформалар.

[4] Мослихе дини – дин реформаторы.

[5] Чыганакта кирилл хәрефләре белән басылган.

[6] Мазыйсын – үткәнен.

уңнан-суңнан җыйган китаблары аркасында дини һәм тарихи бабда байтак нәрсәләр эшләде, дөрест, ул иске «Тәүзыйх»[1], иске «Шәмсия»[2], иске «Мелла Җәлял»[3]ләр өстенә берничә оригинальный сүз дә сөйләде, ихтимал, ул бу хосусы белән иске ислам мөтәкәллимләрендән һәм философларындан зурлары илә һәм соңгы мөәррихләргә материал җыеп бирү җәһәтендән иске ислам мөәррихләрендән Ибне әл-Әсирләр[4], Хафиз Абру, Мәхмүд бине Вәлиләр илә ярыша алыр. Ләкин бу эшләре илә Мәрҗани безнең Йаурупа тәэсиренә кадәрге мазыймызны[5] гына баета, һәм болар бөтенләй икенче мәсьәләләрдер. Без бит ул мәсьәләне сөйләмисез, без Мәрҗанинең яңа мәдәни хәрәкәтемезгә мөнәсәбәте мәсьәләсен сөйлимез. Бу җәһәтдән караганда, Мәрҗани, шул ризасызлык, канәгатьсезлек дәверендә эшләп, безне Гаспринский заманына хәзерләп үткән бер эшчедер. Һичбер артдырмаган вакытда да Мәрҗани – ошбу кадәресе илә безгә кадерле кеше. Ул дөньяның мәдәни хәятында зур урын алырлык булмаса да, безнең үземез өчен зур. Һәм туган елын без иске Ибне Халдунларга[6] булган нәзарымыз[7] илә генә, ягъни үземездән килгән олуг бер шәрык галиме дип кенә түгел, бәлки ошбу яңа мәдәни хәрәкәт ноктасындан искә аламыз, чөнки мәдәни хәрәкәтне башлап алып барган кешеләр илә бергә шул мәдәни хәрәкәтләргә юл хәзерләп килгән кешеләр һәм шул микъдарда кадерлеләрдер. Курсави, Мәрҗани, Низамеддин Илһами,

---

[1] «Тәүзыйх» – Әбү Мөхәммәд Гобәйдулла бине Мәсгуд Тәжушшари китабы («Ачык аңлату» мәгънәсендә).

[2] «Шәмсия» – китапның тулы исеме «Әр-рисалә эш-шәмсия фи-л-кавагыйдел мантыйкыя», мәдрәсәләрдә шәкертләрне матур һәм дөрес сөйләргә өйрәтү өчен кулланылган мантыйк китабы. Авторы: Гомәр бине Гали әл-Казвини, Нәҗметдин әл-Кәтиби (600/1203 – 675/1277).

[3] «Мелла Җәлял» – иске мәдрәсәләрдә дәреслек булып кулланылган мантыйк китабы.

[4] Ибне әл-Әсирләр – Ибне әл-Әсир Гыяздеддин Әбүл-Хәсән Гали бине Мөхәммәд әл-Җазири (1160–1233), гарәп тарихчысы.

[5] Мазыймызны – үткәнебезне.

[6] Ибне Халдунларга – Ибне Халдун Вәли-әд-дин Гаддеррәхман Әбү Зәйд әл-Мәлики әл-Хәдрами (1332–1406), гарәп тарихчысы һәм философы.

[7] Нәзарымыз – карашыбыз.

Гариф Сәйраниларның шул череп беткән Бохара эчендә торып ислам галәмендәге башка мөнтәхәб (отборный[1]) мөтәфәккирләр арасына керүләре һәм шуларның монда кайтып хезмәт күрсәтүләре – тарихымыз бабында гаять кызык бер эшдер. Моны искә алу гына түгел, бик нык итеп үгрәнергә тиеш.

*Әхмәдзәки Вәлиди[2].*

*Мәкалә «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар санында (№1346) дөнья күргән. Текст басмага газетадан алынды.*

*Текстны басмага Гөлчирә Ханнанова,*
*Абдулла Сәлахов әзерләделәр*

## Олуг мослих вә мөҗәддидемез[3]

Бондан йөз ел элек, 1233 нче сәнә, һиҗрия 7 нче рабигыль-әүвәлдә, ислам галәменә тәэсире иҗраэ итәчәк[4] вә фикри инкыйлабга сәбәп булачак зат, остаз Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре дөньяга килде. Бу көн мәрхүмнең вәләдәтенә[5] йөз ел тулу мөнсәбәте илә аның мөселманларның интибаһ[6] вә тәрәкъкыйларына тәэсире тугрысында берәр җөмлә язмак буламын.

Мәрҗани хәзрәтләренең интибаһ вә тәрәкъкыймызга тәэсирен аңлау өчен, андан элек вә аның заманында булган гомум халкымызның дәрәҗәи фикрияләрен һәм тәҗдид вә исляхат[7] бабында мәрхүмнең хезмәтләрендән бәгъзеләрен күз алдына китерү йитәдер. Мәрҗани гасырында гомумхалык Аллаһы Тәгаләдән вәхи кылынып[8], пәйгамбәр тарафындан мәгълүм

[1] Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Әхмәдзәки Вәлиди – Әхмәтзәки Әхмәтша улы Вәлиди (Вәлидев; 1890–1970), тарихчы, тюрколог, башкорт милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе.

[3] Олуг мослих вә мөҗәддидемез – олы реформатор һәм новатор.

[4] Тәэсире иҗраэ итәчәк – тәэсир итәчәк.

[5] Вәләдәтенә – тууына.

[6] Интибаһ – уяну чоры.

[7] Тәҗдид вә исляхат – яңарту һәм реформа ясау.

[8] Вәхи кылынып – Алла тарафыннан күңелгә иңдерелеп.

кылынган чын шәригать илә хосусый адәмләрнең фикерләре арасыны аермыйлар, шунлыкдан бонлар динне гаять тар бер даирә тасвир итеп, аны үзләренчә аңламаган бик күп мөселманларны ул даирәгә сыйдыра алмыйча тәкфир вә тәзълил итәләр[1], ушандак[2] голүм вә фөнүне дингә[3] зарарлы, мөселманга анларны тәхсил итү[4] дөрест түгел, дия игътикад кылалар[5] иде. Бонлар динне дөрест аңлаудан мәхрүм, әхвале галәмдән хәбәрсез булдыклары хәлдә, үзләренә хөсне занлы, гыйлем вә фикерләренә канигъ иделер[6]. Мәрҗани хәзрәтләре, боның кеби хата фикерләрне әсасындан[7] йимереп, шәригате исламия әдиләи катгыягә[8] бина кылындыкыны, Аллаһының шәригатендә рәи вә фикер[9] илә тасвир итәргә һичкемнең хакы булмадыгыны, «шәригать илә хикмәт», «хакыйкать» исемле бер анадан туган игез балалар» идекене ачык вә катгый дәлилләр илә исбат итде.

Мәрҗани хәзрәтләре дини мәсьәләләрдә Коръән вә сөннәт юлындан кыл кадәр читкә китүне дөрест күрмәдекендән, игътикад вә гыйбадәт бабларында китап вә сөннәт юлына вә сәләф мәсләкенә мохалиф булган[10] эшләрне каты интикад вә җәрех итде[11]. Аның бу эшләре гаммәнең[12] фикер вә идракендән[13] өстен, аларга ят булдыгындан, вакытында зур шау-шуга, үзенә һәртөрле тагын вә тәгаддидләргә[14] сәбәб булсалар да, бонлар ислам голямасына тәэсирсез калмады. Мәрҗани китаблары таралгандан соң, хосусан, татар голямасы арасында динне

[1] Тәкфир вә тәзълил итәләр – динсез дип саныйлар һәм хурлыйлар.

[2] Ушандак – шулай ук.

[3] Фөнүне дингә – дини фәннәргә.

[4] Тәхсил итү – өйрәнү.

[5] Игътикад кылалар – ышаналар.

[6] Канигъ иделер – кәнәгатьләнер.

[7] Әсасындан – төбеннән.

[8] Әдиләи катгыягә – катгый дәлилләргә.

[9] Рәи вә фикер – уй һәм фикер.

[10] Мохалиф булган – каршы килгән.

[11] Интикад вә җәрех итде – тәнкыйть итте һәм хурлады.

[12] Гаммәнең – халык массасының.

[13] Идракендән – аңлавыннан.

[14] Тагын вә тәгаддидләргә – шелтәләргә һәм гаепләүләргә.

аңлауда даирә киңәю, башкаларның фикерләренә хөррият бирү, фөнүн[1] вә сәнаигъга[2] дөрест карау кеби фикри, зур инкыйлаблар күрелә башлады.

Мәрҗани хәзрәтләренең мәзкүр бәянлары динне хата аңлауда югарыда әйтелгән таифәгә[3] иштирәк иткән[4] икенче бер таифәнең дә фикере төзәлүгә вә хакны аңлавына сәбәб булачакдыр. Ул таифә исә мөселманларның фөнүн вә сәнаигъга ихтыяҗларыны, тәдәнни вә инхитатда[5] булдыкларыны аңлаган, ләкин боны исламиятдән күрү кеби яңлыш фикердә булган кемсәләрдер.

Бу ике таифә динне фөнүн вә сәнаигъга каршы дия хата аңлауда мөштәрәк булып[6], фәкать бонлардан беренчесе – диннең вә икенчесе – фәннең надан дустларыдыр. Имди Мәрҗани китабларыны вә аның исламиятнең голүме хәкимиягә нәзары тугрысындагы бәянларыны күргән кемсәләр тәдәнни вә инхитатымызга сәбәб исламият түгел, бәлки исламиятне яңлыш аңлавымыз идекенә канәгать хасыйл итәчәкләрдер.

Дәхи[7] бонларга башка Мәрҗанинең тәгълим вә тәдрис ысулларыны[8] интикад итүе[9], тарихы милли вә тарихы әдәбиятымызга башлап нигез салуы, үзендән соңгыларының шул юлларда хезмәткә керешүләренә вә тәкмилгә тырышуларына[10] сәбәб вә мөәссир булды[11]. Хөласа[12]: интибаһ вә тәрәкъкыемезнең каю гына тармагындан кителсә дә, аның очы Мәрҗанигә барып чыкканы күреләдер. Шунлыкдан ул интибаһ вә тәрәкъкыемезгә башлап тәэсир итүче олуг мослих вә мөҗәддид саналадыр.

[1] Фөнүн – фәннәр.

[2] Сәнаигъга – сәнәгатькә.

[3] Таифәгә – төркемгә.

[4] Иштирәк иткән – катнашкан.

[5] Тәдәнни вә инхитатда – артка калу һәм түбән төшүдә.

[6] Мөштәрәк булып – уртак булып.

[7] Дәхи – тагын, яңадан.

[8] Тәгълим вә тәдрис – уку-укыту.

[9] Интикад итүе – тәнкыйть итүе.

[10] Тәкмилгә тырышуларына – тулыландыруга тырышуларына.

[11] Мөәссир булды – йогынты ясаучы булды.

[12] Хөласа – нәтиҗә.

Мәрҗанидә булган фазыйләт[1] вә тәхкыйкат[2] өстенә аның башкаларга нәмүнә[3] булырлык дәхи бер фазыйләте – дин вә хакыйкатьне һәрнәрсәдән гали күреп, шул юлда фидаи[4] булуы вә мәсләкендә сәбат[5] итүендәдер. Ул хакыйкатьне сөйләүдә дошманларның сүэ касд[6] кылуына вә дустларның хәтере калуга илтифат итмәде. Бу хәрәкәтләре өчен дошманларының сигаясе[7] сәбәбле, ике мәртәбә урыныннан газәл кылыну, гомере буенча наданларның иза вә җәфаларыны күреп тору, аны мәсләкендән кыл кадәр авышдыра һәм хакны сөйләүдән туктата алмады. Мәрҗани хәзрәтләре кеби үзенә бер дәвер иясе булган затның әһәмиятен берничә сәтырлы[8] мәкаләдә бәян итеп аңлату мөмкин түгелдер. Аны якыннан тану, мәсләк вә хезмәтләрендән хәбәрдар булуны эстәгән[9] кемсәләремез Мәрҗанинең вәләдәтенә йөз ел тулу мөнәсәбәте илә мәшһүр мөхәррирләремезнең иштирак вә могавәнәте[10] илә тәртиб вә табгы ителгән[11] «Мәрҗани» мәҗмугасына мөрәҗәгать итәрләр. Алты йөз илле битлек бу мәҗмугада мәрхүмнең мөфассал[12] тәрҗемәи хәле, төрле мәүзугълардагы[13] гыйльми хезмәтләре, ихтисас[14] вә имтияз[15] иткән мөһим мәсләк вә фикерләре, дияре исламда[16] мәшһүр бәгъзе галимләрнең ушандак мәмләкәтемездәге мәшһүр затларның Мәрҗанигә карашлары вә бәгъзе затларның аның тугрысын-

[1] Фазыйләт – өстен сыйфатлар.
[2] Тәхкыйкат – хакыйкатьләр эзләү.
[3] Нәмүнә – үрнәк.
[4] Фидаи – үз-үзен аямыйча эшләүче, фидакяр.
[5] Сәбат – нык.
[6] Сүэ касд – явыз ният.
[7] Сигаясе – яла ягулары.
[8] Сәтырлы – юллы.
[9] Эстәгән – теләгән.
[10] Иштирак вә могавәнәте – катнашы һәм ярдәме.
[11] Тәртиб вә табгы ителгән – төзелгән һәм нәшер ителгән.
[12] Мөфассал – тулы, җентекле.
[13] Мәүзугълардагы – темалардагы.
[14] Ихтисас – белгечлек.
[15] Имтияз – өстен булу.
[16] Дияре исламда – ислам ияләрендә .

дагы хатирәләре вә бәгъзе рус мөәррихләренең аның тарихи хезмәтләре хакындагы фикерләре язылмышдыр.

*Мелла Кәшшафетдин Тәрҗемани*[1]

*Мәкалә «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар (1346 нчы сан) санында дөнья күргән.*

*Текстны басмага Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Мәрҗани көтебханәсе һәм аның соңгы язмышы

Мәсьәлә тулырак һәм ачыграк аңлашылсын өчен, сүзне эшнең тарихи ягыннан, кыскача гына Мәрҗанинең тәрҗемәи хәлен язудан башлыйк.

Мәрҗани Казан өязе (Арча кантоны Ябынчы авылында)[2] 1818 ел, 3 гыйнварында туган; 1889 ел, 18 апрелендә, 74 яшендә Казанда үлгән)[3]. Ул яшьдән үк таза тәнле, зур гәүдәле, көчле кеше булган. Егет вакытында Мәрҗани сабан туйларында көрәшче батыр булыб көрәшеб йөргән, аны көрәшче Шиһаби[4] диб йөрткәнләр. Мәрҗанинең яшь вакытындагы тәрбиясе авыл мәктәбләрендә булыб, ул кечкенәдән үк тарихи хикәяләр тыңларга бик яраткан. Ләкин авыл тормышы, авыл мәдрәсәләрендәге укулар аны канәгатьләндермәгәнләр; ул 1838 елда Бохарага укырга китә[5]. Бохара вә андагы мәдрәсәләр һәм укыту ысуллары Мәрҗанигә бер дә ошамыйлар. Шундан соң ул әүвәле Бохарада, андан соң Сәмәркантдә төрле көтебханәләргә йөреб, андагы кульъязмаларны тикшерү һәм өйрәнү эше белән шөгыльләнергә керешә. Аның бу хезмәте унбер елларга сузыла. Шушы унбер ел эчендә Мәрҗани бик күб кульъязмаларны

---

[1] Кәшшафетдин Тәрҗемани – Кәшшафетдин Кыяметдин улы Тәрҗеманов (1877–1943), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин гыйлеме белгече.

[2] Ябынчы авылы – Казанның төньягында, илле чакрым ераклыгында, Мәрҗан авылы якынында бер авыл.

[3] Мәрҗани мәҗмугасы, 8 нче бит.

[4] Мәрҗани мәҗмугасы, 13 нче бит.

[5] Мәрҗанинең «Бохара сәяхәтнамәсе» исемендә зур гына кульъязма бер китабы бар.

күчереб языб ала һәм башкалардан күчертә. «Вафиятел-әсляф», «Мөстәфадел-әхбар» һәм «Мәрҗани» мәҗмугасында язылган мәгълүматларга караганда, ул Бохара һәм Сәмәрканд якларыннан күб санда кульязма китаблар һәм башка тарихи материаллар алыб кайткан.

Мәрҗанинең язуына караганда, аның ата һәм бабалары да тарихчы кешеләр булганлар. Ул «Мөстәфадел-әхбар»да үзенең бабаларындан байтак тарихи вакыйгаларны күчереб яза. 1877 нче ел, 31 июлендән 18 августына чаклы дәвам иткән IV Археология съезды выставкасының күрсәтмәсендә (указатель) язылган мөһим кульязмаларның эчендә Мәрҗанинең Габделкәрим (бу кеше йөз яшендә, 1206 һ. Мәрҗан авылында вафат) исемле бабасындан калган бер кульязма Коръән бар иде. Бу кульязма Коръән турында Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар» II җилд, 142 битдә болай яза: «Бабабыз Габделкәрим Мәрҗанидән калган, баш ягында ике кәгазь, ахыр ягында һәфтияк өлеше төшкән, рәсме хатты[1] бик гүзәл, укымышлы кеше тарафындан язылган бер Коръән кулыбызда бар иде. Бу кульязма Коръәннең кәгазе безнең җиребездә иске заманларда истигъмаль ителгән[2], борынгы кәгазь бар иде. Карасы мазу, күкфараз һәм сәмихдан кушылыб ясалган иде. Һәрбер җөзьэнең башында (җөзьэ – Коръәннең утыздан бере, Коръәндә утыз җөзьэ бар) бер юл язу бөтенләй куе кара калын каләм белән язылыб, һәрбер җөзьэнең дүртдән беренең алдынгы беренче сүзендә шулай ук калын итеб язылган иде. Бу кульязма Коръәнне бабабыз Сөбхан Габделкәрим углы Мәрҗани үзенең ата ягындан булган кардәше бер кыз тарафындан язылган булганлыгын сөйлидер иде. Кат-кат ишеткән идем. Ләкин ул вакытда яшьлек гафләте сәбәбле, ул (мәзкүр Коръәнне язучы) кызның исемен, шәмаилен вә башка аның хәлләрен тәфсилләб языб кала алмаганлыгыма бик зур тәәссеф итәмен».

Мәрҗанинең озак яшәгән берничә борын бабаларындан бирле җыелыб килә торган бай көтебханәгә варис уларак хуҗа булыб калуы мәгълүм. Менә мондан күренә ки, Мәрҗани көтебханәсенең башлаб нигезләнүе, Бохара вә Сәмәрканд һәм,

[1] Рәсме хатт – язу рәвеше.

[2] Истигъмаль ителгән – кулланылган.

гомумән, Төркестан ягыннан үзе алыб кайткан күб сандагы кулъязма һәм документлар белән, ата-бабаларыннан аңар мирас булыб калган кулъязмага бай борынгы көтебханәнең кушылуыннан килеб чыккан бер көтебханә булган.

Мәрҗани Казанда мөдәррис булыб торган заманларында Казаннан читдә булган төрле татар авылларына йөреб, кульязмаларны, кабер ташларын һәм документларны тикшергән, җыйган. Ул бик күб авылларда булган[1]. «Мөстәфадел-әхбар»да Мәрҗани үзенең төрле авылларга йөреб тикшергәндән кулга төшергән кулъязма һәм документларга таяныб, бик күб нәрсәләр яза. Мисал өчен кайберләрен күчереб языб китик. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар» I [җилд] 22 битдә Казан сәүдәгәре Исмәгыйль Апанай углы исемле кешедән калган бер документның гыйбарәсен күчерә. Анда языла: «Тарих мең дә йите йөз дә сиксән сигезенче елда январьнең сигезенче көнендә Казанның Иске Бистәнең йомышлы кеше мин Йосыф Динмөхәммәд углы сатдым үземнең хассемә[2] тигән колымны Казанның Иске Бистәнең Исмәгыйль Апанай Хафиз угылына йөз сум хак берлә, ошбу мәзкүр колларым Алат юлында Арча округында Күшәр илендә йорт берлә торгучыдыр мәзкүр колларым ул Бикбау Сөйдекәй угылы хатыны Нәсыйхә, бер кызы сабый берлә углы Бикчәнтәй Бикбау угылыны, икенче колымның угылы Мортаза Мөэмин углыны вә дәхи шул Күшәр илендә биләй торган йирләрем һәм печәнлегем көллүсе[3] Исмәгыйль агайгадыр».

«Мөстәфадел-әхбар», шул ук җилд, 70 битдә Мамадыш кантоны Тенеки авылында, мондан ике йөз еллар алда Әмкә мулла дигән кеше тарафыннан язылган кулъязма китабдан материалар күчерә, «Мөстәфадел-әхбар», шул ук җилд 78–89 битләрдә Идел буе Болгар галимләре вә аларның әсәрләре турында язганда, XII, XIII, XIV йөзләрдә булган кулъязма әсәрләрнең баш һәм ахыр

---

[1] Миңа быел җәй көнне Иске Рәҗәб авылында моннан алтмыш еллар элек Мәрҗанинең Спас кантоны Рәҗәбдә булганлыгын, анда кабер ташлары һәм кулъязмаларны тикшереб, языб йөргәнлеген, авыл картлары белән төрле мосахәбәләр ясаганлыгын сөйләделәр. Мәрҗанинең Казан, Мамадыш, Лаеш, Зөя һәм Тәтеш өязләрендә булганлыгы да мәгълүм.

[2] Хасс – бер нәрсәгә билгеләнгән.

[3] Көллүсе – барчасы.

якларындан гыйбарәләр күчереб, алар турында изахәләр[1] яза[2] һәм үзенең сүзләренә бу кулъязмалардан алыб дәлилләр китерә.

«Мөстәфадел-әхбар», II җилд, 8 битдә Спас өязе Иске Рәҗәб авылы имамларындан мулла Зәйнелгабидин Габделкәрим угылы исемлә кешенең тәрҗемәи хәленә теркәлгән документның тәрҗемәсендән түбәндәге урынны күчерә. Бу документ Рәҗәб халкының игенлек, печәнлек һәм умарталарның чикләрендән башка авылларның чикләрендән аерыр өчен, хөкүмәт мөһере белән ныгытылган рәсми документ булган. Документына язылa: «Тарих йите мең дә ике йөз өченче декабрь аеның унөченче көне илән указ олуг газыйм падишаһ хәзрәте олуг кенәз Петр Алекчиеч барча олуг вә кечек ак падишаһ Русия йортыны үзе тотгучы, үзе биләкүче указ кувәте илән Казан өязенең Рәҗәб авылының татарлар юкарыда язылган йирләр сукалатмак өчен һәм печәнен чапмак өчен указлар илән биләргә олуг падишаһ хәзрәтенең бердән ясак илән тармакга, ягъни түләмәккә бер замандагы аңлатуны Казанга түләргә яздым».

«Мөстәфадел-әхбар», II җилд, 9 битдә Олы Кавал имамы Сәлимҗан Дусмөхәммәд углы дигән кешенең кулъязма бер китабындан менә мондый тарихи бер парчаны күчерә: «Бихисабе рус[3] йите мең дә ике йөз дә сикез улган иде, бактылар Гайсәнең тарихыны һәм мең дә йите йөз дә булмыш ул Адәм галәйһиссәлам тарихыны ташладылар, ошбу мең дә йите йөздән алдылар, имди Гайсәнең тарихыны мең дә йите йөз дә бер диб санай башладылар. Мең дә йите йөз дә сикез улды печин[4] елында биш мең дә биш йөздә сикез елы тәмам ташланды, дәхи

[1] Изахәләр – аңлатмалар.

[2] Бу кулъязмаларның күбесе Мәрҗани көтебханәсендә булган (С. Вахиди иск.).

[3] Монда ике йөз егерме тугыз ел алда, әле урыслар һаман иске гасыр тарихы белән хисаб алыб баралар иде. Олы Кавал авылының Сәлимҗан Дусмөхәммәд углының кулъязмасы язылган ел урыслар хисабынча 7208 булган. Бу ел милади белән 1700 ел булыб, шундан иске гасыр тарихының 5508 елы ташлана да, 1701 диб санаб кителә. Бу вакыйга заманында зур үзгәрешләрдән хисабланган.

[4] Печин (бечин) – маймыл.

белгел әй, сахибе тәмиз[1], сале шәмсиянең[2] өч төрле хисабы вардыр, беренә фарсия хисабы дирләр, аның берлә әһле Болгар гамәл тотмышдыр. Вә беренә румия хисабы дирләр әһле нәсара[3] гамәл тотмышдыр бәс мәгълүм вә мәшругъ[4] булды хәмәл хисабын җәмигъ мөэмин вә мөселманларга белмәк ляземдер... вә дәхи мәгълүм ула ки ул фарсия нәүрүзе улыр, ун көндән соң румия нәүрүзе улыр, андан ун көндән соң хәмәл[5] нәүрүзе булыр, нитәкем шәһре Болгар голямасы ишарәт кылдылар: билә нәүрүз карт нәүрүз, вәссәлек нәүрүз дию вә һәрбер нәүрүз берәр гаҗүз[6] хисабыдыр».

«Мөстәфадел-әхбар», II җилд, 127 битдә Ташкичү авылында мондан бер йөз туксан ике ел алда язылган бер китабның Ташкичү урманында яшеренеб язылуы турындагы мәгълүматлары, шулай ук «Мөстәфадел-әхбар»ның Идел буе болгарлары турында язылган бәетләрендә Шәһре Болгардагы олы манараның егылуы турында, Спас өязе Олы Чаллы авылының крестьяны Фазлулла Бохарай углы тарафыннан язылган «Мәҗмәга»сендән күчереб, әлеге манараның, 1136 нчы һиҗри елның җәендә сәламәт булучылыгы вә ул манара турында байтак тәфсыйлатләрне язуы – боларның барысы да Мәрҗанинең документ һәм кулъязмаларны эзләгәнлеген, җыйганлыгын, алардан файдаланганлыгын күрсәтәдер.

Мәрҗани бу мәсьәлә турында байтак кешеләргә хатлар да язган. Безнең өчен гыйльми вә тарихи әһәмиятле булган бер хатындан кайбер урынларын күчерәбез. Мәрҗани мондан алтмыш дүрт еллар алда, үзенең шәкерте Хөсәен Фәезхановның вафатына тәәссеф итеб (Фәезханов Петербург (Ленинград) дарелфөнүненең[7] шәрык телләре бүлегендә лектор булыб торганда 1866 ел 30 июлендә вафат) Газизулла һәм Кәлимулла дигән

[1] Сахибе тәмиз – чисталык, пакьлек иясе.

[2] Сале шәмсия – кояш календаре.

[3] Әһле нәсара – христианлылар.

[4] Мәшругъ – шәригатькә ярашлы.

[5] Хәмәл – кучкар йолдызлыгы; ел исәбенең 22 марттан 22 апрельгә кадәрге вакыт аралыгы.

[6] Гаҗүз – карт кеше.

[7] Дарелфөнүненең – университетының.

кешеләргә һижри 1283 ендә язган хатында болай яза: «Мескенем мулла Хөсәен... Вафат булган икән ләбаса, ни кылмак кирәк... Күб-күб хезмәтләр кыйлыб, бинибая файдалар тигергән иде... , һәйбәт кеше иде... Аның һәртөрле мәҗмугалары вә китаблары булса кирәк иде. Безгә кул китаблары булганда, сатмакны ихтыяр кылсалар, без, бәлки, алыр ирдек. Аның мәдрәсә хосусында тәхрир кылган[1] бер рисалә мөсвәддәсе бар иде. Аны бәяз кылыб[2], басдырмак ирадәсендә[3] иде бичара. Бәязга форсаты булмагандыр, шул рисалә җуялмаса икән, мин үзем аны бәязга чыкарыб, басдырмак садрында[4] булыр идем, тәгаддәдә нөсхи (нөсхәләрен артдыру) булырлык биш-алты нөсхә яздырыр ирдем. Бичараның сәгый вә иҗтиһады заигъ булмаса икән,[5] ул бик яхшы бик мөфид[6] нәрсә иде... Хасыйле кәлам,[7] мөмкин булса, тизлек илән мәрхүмдән калган китабларны исемләрене языб алыб, тәфсыйлән фиһрист[8] ясаб, мөмкин булса, баягы рисаләсе, шуңар мөтәгалликъ[9] җөзьи кәгазьләрдә булган тәхрирләрне һәм безгә йибәрәсез. Мөкаддәмдәрәк[10] үзенең җәмгъ кылган бер мәҗмәгы булса кирәк иде. Янә татар телендә вазыйг кылган[11] нәхүе, сарфы булса кирәк иде. Болгар вә Казан хакында мәкаләсе булса кирәк иде. Безнең хатымызның һәм мәзмуныны[12] хат белән җәмәгатенә ифадә итәсез[13]».

Мәрҗани «Гыйляләтез-заман фи тарихи Болгар вә Казан»

---

[1] Тәхрир кылган – язган.

[2] Бәяз кылыб – акча күчереп.

[3] Ирадәсендә – теләгендә.

[4] Садрында – эшнең алдында, башында.

[5] Сәгый вә иҗтиһады заигъ булмаса икән – бирелеп эшләве һәм тырышуы әрәм булмасын иде.

[6] Мөфид – файдалы.

[7] Хасыйле кәлам – кыскача әйткәндә.

[8] Фиһрист – исемлек.

[9] Мөтәгалликъ – караган, бәйле.

[10] Мөкаддәмдәрәк – алдарак, элегрәк.

[11] Вазыйг кылган– төзегән.

[12] Мәзмуныны – фикри эчтәлеге.

[13] Ифадә итәсез– аңлатасыз.

исемле әсәрендә бу китабны һәртөрле мәҗмәгъ[1] вә мәҗмугадән шулай ук бу йирнең халкы тарафындан язылган төрле язмалардан җыйнап тәәлиф иткәнлеген[2] яза.

Югарыда язылган материаллардан ачык күренә ки, Мәрҗани һәртөрле иске кулъязмалар, документлар, мәҗмугаләр вә башка тарихи әсәрләрне тикшерергә, җыярга, алардан истифадә итәргә шул дәрәҗәдә әһәмият биргән. Боларның өстенә Мәрҗанинең үз гомерендә утыз бишдән артык мөһим әсәрләр язганлыгын игътибарга алсак, үзе язган әсәрләренең матбуг[3] булганларының үзендә калган кулъязмалары – матбуг булмаган әсәрләренең оригиналлары һәм читдән йибәрелгән төрле кешеләр тарафындан язылган шәһәр вә авыллар турындагы тарихларның кулъязмалары, менә болар үзләре генә дә Мәрҗани көтебханәсенә галимләрнең дикъкатьләрен җәлеб итүдә зур гамил[4] була алалар. Шуларга таяныб без әйтәбез: Мәрҗани көтебханәсе чаклы, хәзерендә бөтенләй табылмый торган кулъязма төб нөсхәләр, документлар, шәҗәрәләр, юридический памятниклар, авыллардан җыелган яки алардан күчереб алынган нөсхәләр бик күб булганлар. Мәсәлән, Бохарада укыган чакларында Мәрҗани ибне Фазланның Болгарга килгән вакытында язган сәяхәтнамәсенең бер нөсхәсен интихаб[5] белән күчереб алган булган. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»дә язуына караганда, Мәрҗани күргән ибне Фазлан әсәренең нөсхәсендә Якут әл-Хәмәви һәм башкалар күчергән сүзләрдән артык сүзләр анда бик күб булган.

«Мөстәфадел-әхбар»дә язылуына караганда, Мәрҗани көтебханәсендә Идел буе Болгар галиме Ибраһим бине Хәзәр әл-Болгариның 751 һиҗридә язылган «Китабе ысул әл-Хисами» исемле әсәренең төб нөсхәсе һәм икенче бер болгар галиме Сәдер бине Галәветдин әл-Болгариның шәкерте Ибраһим бине Мөхәммәдхуҗа Карәтмәни[6] дигән галимнең шул «Имам Фәхрелислам» исемле, һиҗрәтдән 765 нче елда язылган әсәре-

---

[1] Мәҗмәгъ – җыелма, тупланма.

[2] Тәәлиф – җыйнау, төзү.

[3] Мәтбуг – басылган.

[4] Гамил – фактор, көч.

[5] Интихаб – сайлап алу.

[6] Карәтмән авылы хәзер Татарстанның Яшел Үзән районына керә.

нең һәм бер нөсхәсе аның кулында булган. Шулай ук «Мөстәфадел-әхбар»дә язылуына караганда, ибн әл-Әсирнең «Мәгърифәт әс-сәхабә» исемле әсәренең бик иске нөсхәсе Мәрҗани көтебханәсендә булган. Бу нөсхәне Мәрҗани ибн әл-Әсирнең үз гасырына бик якын заманда булучылыгын яза. Боларга башка Мәрҗани көтебханәсендә аның хакында тикшеренү дәвам итә торган «Нәһҗел-фәрадис» нөсхәсенең бик иске вә бик мөһим кульязмасы булганлыгы һәм Хөсәен Фәезхановның байтак әсәрләре, бигрәк дә мәдрәсәләрне ислах турындагы әсәренең әле 15 нче елга кадәр Мәрҗани көтебханәсендә сакланган булучылыгы, менә боларның барысы да Мәрҗани көтебханәсенең гыйлем ияләре өчен ничаклы әһәмиятле бер көтебханә икәнлеген күрсәтүдә көчле дәлил була алганлыкларын тәкрар итәбез.

Мәрҗани сәламәт вакытда үзенең милкендә булган китабларның кадерен белгән һәм аларның югалтмау, таралмаулары турында тәдбирдә[1] кылган. Хәтта ул үзе үлгәннең соңында да көтебханәсендәге китапларның таралмыйча саклану чараларын күрергә тырышкан. Без моны Мәрҗанинең үз кулы белән язып, үзенең һәм шаһидләрнең имзалары вә үзенең мөһере белән расланган васыятьнамәсендән аңлыйбыз. Мәрҗани 1297 һиҗри шәгъбән аенда язган васыятьнамәсендә бу турыда менә болай яза: «Вә дәхи кәнде[2] милкем улгучы җәмигъ китабларымны үз әүладемә[3] вәкыф итдем. Карнән бәгъде карн[4] бер дә сатылмас. Истигъмаль кылыб файдаланудан башка урында истигъмаль кылынмас. Файдалана торган ышанычлы кешегә дөрест вәсика[5] берлә аз заманга гарият[6] биреб торырлар. Мәгазе Аллаһы[7], кәнде әүладем киселсә, туганларыма вә әүладларына шул тарика[8] вәкыф улыр. Бу китабларның һәркаюсына исемемлә мөнәкъкаш[9] «Вакфы

[1] Тәдбир – тиешле чара.
[2] Кәнде – үземнең.
[3] Әүлад – балалар.
[4] Карнән бәгъде карн – гасыр артыннан гасыр.
[5] Вәсика – ышанычлы документ, дәлил.
[6] Гарият – вакытлыча файдалануга алып тору.
[7] Мәгазе Аллаһы – Аллаһ сакласын.
[8] Тарика – юлга.
[9] Исемемлә мөнәкъкаш – исемем белән бизәлгән.

әүлад[1]» дию яздырган мөһерем басылыр вә тәфсыйль дәфтәрдә исемләр илә язылыб рәкымләр[2] берлә мәркум[3] кылыныр»[4].

Васыятьнамәдән аңлашылуына караганда, Мәрҗани көтебханәсе гасырлар буе таратылмыйча сакланырга тиеш булган. Көтебханәдәге әсәрләр белән вакытлы файдаланырга теләгән ышанычлы кешеләргә кулларындан кәгазь алыб, бераз заманга биреб торырга рөхсәт ителгән. Ләкин көтебханәдәге китапларның һәр каюсында «Балаларга вакыф» диеб язылган мөһер булырга тиеш булган.

Мәрҗани көтебханәсенә хәзерге вакытда баш хуҗа – аның угылы Борһан хәзрәтнең хатыны Маһисәрвәр абыстай Мәрҗания һәм аның балалары. Алар әле дә шул ук Мәрҗани торган өйдә торалар, Мәрҗанинең көтебханәсе дә алар белән бергә шул ук йортда саклана. Мәрҗанинең васыяте варислар тарафыннан эшкә ашырылгандырмы яки юкдырмы, ул мәсьәлә, әлбәттә, безгә караңгы, аны тикшерү безнең эшебез дә түгел.

Мондан берничә еллар алда ук мин Мәрҗани көтебханәсенә кереб, андагы әсәрләр белән танышырга, алардан файдаланырга теләгән идем. Мәрҗанинең васыяте буенча, көтебханәгә кертерләр диб уйлаган идем. Ләкин эш мин уйлаганның киресенчә булды, Мәрҗани көтебханәсендән файдаланыр өчен, аның соңгы хуҗаларындан рөхсәт алу мөмкин булмады. Мәрҗанинең варислары, бигрәк дә Борһан хәзрәтнең хатыны Маһисәрвәр абыстай, көтебханәнең иң әһәмиятле өлешен сандыкларга тутырыб кладовойда асрау, мөмкин кадәр андый әсәрләрне үзенә якын торган берничә кешеләрдән башкаларга күрсәтмәү юлы белән саклау тактикасын алыб барган. «Мәрҗани» мәҗмугасында язылуына караганда, Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән мәзкүр мәҗмуганы язучы һәйәте тәхририя әгъзаларына көтебханәнең бөтен өлеше белән файдаланырга рөхсәт ителмәгән. Аларга да Борһан хәзрәтдән калган шкафларда булган китабларны каратудан ерак җибәрелмәгән.

Хәзерге вакытда Мәрҗани көтебханәсенең баш хуҗасы булган Борһан хәзрәт хатыны Маһисәрвәр абыстай, анардан шул

[1] Вакфы әүлад – балалар вакыфы.

[2] Рәкымләр – саннар.

[3] Мәркум – номерланган.

[4] Мәрҗани мәҗмугасы. 135–136 битләрдә.

турыда мәгълүмат алырга җибәргән минем кешемә түбәндә язылачак сүзләрне сөйләгән, аның сүзләрен үзендән ишеткәнчә, үзгәртмичә без монда языб китәбез. Ул әйтә: «1917 елны безгә хәбәр бирәләр, Мәрҗани хәзрәтнең көтебханәсен университетка алалар икән. Бу көн мәсҗид очырмасындагы китабларны карыйлар, иртәгә сезгә керәләр, диб. Шуны ишеткәч, мәрхүм улым Габделхәмит хәзрәт: «Әни, без бу китабларны бераз яшеребрәк куйыйк», – диде дә, шул көнне очырмага биш сандык китаб ташыб куйдык. Ул китаблар очырмада шулай тордылар. Ике-өч ел үткәч, бездә пожар булыб, очырмабыз янды, шунда бу китаблар да яндылар. Яныб бетми калган кисәкләрен, урталарын яндырсак гөнаһ булмас микән диб, Галия абыстайга (Мәрҗани кызы, Сафый мулла хатыны) киңәш итдем дә, ауналыб йөргәнче диб яктык. Кайбер калганлары, кырыйлары көйгәнләре әле дә очырмада ике кабчык ята. Миндән «Нәһҗел-фәрадис» китабы сораб абтыраталар, бик кыйммәт бәһагә алабыз диб әйтәләр; хөкүмәт кешеләре дә сорадылар, ләкин ул китаб хәзер бездә юк, каядыр, кая киткәнен дә белмибез, хәзер инде хәзрәтнең (Мәрҗани) күб китаблары бетде. Без инде аларны яхшы саклый белмәдек шул», – ди абыстай.

Мәрҗани варисларының кайберләре белән мин үзем бу турыда мосахәбәләр[1] ясадым. Аларның Мәрҗани көтебханәсе турында сөйләгән сүзләре менә шундан гыйбарәт: «Көтебханәгә моңа кадәр байтак кешеләр кереб-чыгыб йөрделәр. Үткән ел бер мулла көтебханәне тикшереб караб чыкды. Андан соң Әфтах мулла Тәрҗемани көтебханәдәге барлык китабларның исемлеген язды. Ул исемлек әле дә Әфтах мулла кулында, Яңа Бистәдә ди». Дәвамында «Безнең китаблар әкренләб югалдылар шул инде. Вакытлы файдаланырга алган кешеләр китабларны яңадан кайтармадылар. 1920 елда булган ут казасындан очырмага куйган биш сандык китаблар яныб юкка чыкдылар», – диләр.

Әгәр дә аларның Мәрҗани көтебханәсе турында сөйләгән сүзләре барысы да дөрес булса, Татарстан җөмһүриятенең мәркәзе булган Казан шәһәрендә бик зур гыйльми дәүләт юкка чыккан була. Шөбһәсез, моңар бик тирән аяныч вә тәәссеф белән карарга туры килә.

[1] Мосахәбәләр – сөйләшүләр, әңгәмәләр.

Мәрҗани көтебханәсенең соңгы кызганыч тәкъдире белән XIV йөзнең соңгы яртысында борынгы татар әдәби теленең ничек булганлыгын күрсәтә торган бердәнбер кулъязма «Нәһҗел-фәрадис» нөсхәсенең тәкъдире дә, шул ук варисларның сөйләвенә караганда, һичбер кыйммәтле булмаган бер рисалә шикелле юкка чыгарылган була.

Мәрҗани көтебханәсе, аның башлаб төзелеше, анда булган һәртөрле әсәрләр, ниһаять, көтебханәнең бу көндә гомумхалык өчен файдаланырга мөмкин булыб яки булмавы мәсьәләләре, менә болар шөбһәсез әһәмиятле булган, хәзерге вакытда чишелергә тиешле мәсьәләләрдән булганга күрә, без, гәрчә бу хезмәтебезне рус телендә чыга торган гыйльми журналларның берендә басдырырга хәзерләб куйган булсак да, менә боларны мөляхәзә итеп[1], татарча да нәшер итәргә уйладык. Шуны да әйтеб китәргә тиеш ки, безнең бу тикшеренүләребез бәлки тулы тикшеренү вазифасын үти дә алмас. Һәрхәлдә, киләчәкдә бу мәүзугъда[2] казынучы егетләргә безнең бу хезмәтебез материал була алса, без вазифабызны үтәгән булабыз.

Мәрҗани көтебханәсенең әүвәлдә каталогы яки инвентарь журналы булганмы, юкмы, яки алар көтебханәдән югалтылган бик күб әсәрләр шикелле соңындан югалганлармы, без әлегә ул турыда һичбер төрле мәгълүмат ала алмадык.

Мәрҗани көтебханәсендән бик күб әсәрләр югалган һәм яныб юкка чыккан булсалар да, шөбһәсез, әле анда сәламәт сакланыб калганлары да байтак булырга тиеш. Һәрхәлдә, көтебханәгә кереб җитди тикшерүләр ясаганда, әһәмиятле кулъязма, аерым кәгазь һәм документларның табылачагына мин ышаныб карыймын.

*Сәет Вахиди*

*Мәкалә 1929 елда «Безнең юл» журналының 6–7 нче саннарында басылган.*

*Текстны басмага Илһам Гомәров әзерләде*

## Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле

[1] Мөляхәзә итеп – игътибар итеп.
[2] Мәүзугъ – тема, мәсьәлә.

Шиһаб хәзрәт Мәрҗани 1818 елда 19 гыйнварда дөньяга килә. Атасы Баһаведдин хәзрәт Ябынчы авылының имамы (соңыннан Ташкичүгә күчә), карт бабалары Казан тирәсендә «Мәрҗан» авылыныкылар. Аның үзенә «Мәрҗан» дигән исемне куюы шуның өчендер. Мәрҗанинең нәселе бер якдан Казанның зур байлары Апанаевларга барып баглана.

Мәрҗани яшьдән әтисе мәдрәсәсендә укый һәм 16 яшендән башлап шул мәдрәсәдә хәлфәлек кыла. Шул яшендән үк әлеге мәдрәсәдә укыган чагында ук китап моталәга кылуга һәвәсле булу өстенә, үзендә һәрнәрсә турында үзлекле һәм тәнкыйди карашын сиздертә барган. 18–19 нчы гасырда татар руханилары өчен гыйлем үзәге Бохара диеп танылганга күрә, Мәрҗани 1838 елда 22 яшендә шунда китә. Юлда бераз тукталып, Троицки тирәсендә казакъ-кыргызлар арасында сабак укытып, юллык акча хәзерләп алган. Бохарага баргач, андагы мәдрәсәләрнең укуларын, андагы схоластика методларын яратмый. Шуның өчен анда Бохараның иске бай көтепханәләренә йөреп, үз-үзендән гыйлем алырга тотына. Шулардагы тарих китапларындан файдалана башлый. Бохарада 5 ел торгач, ул вакытларда Урта Азия гыйлем үзәкләренең икенчесе саналган Сәмәркандка килә. Анда казый Әбү Сәгыйд исемле бер галимдән файдалана. Бу галим үзенең бик бай көтепханәсен Мәрҗанинең ихтыярына куя. Хәтта Мәрҗанинең тарих белән шөгыльләнеп китүенә, тарих китапларын укырга, тикшерергә бирелүенә, Мәрҗанинең үз сүзләренә күрә, шул ук казый Әбү Сәгыйд баш сәбәп була. Мәрҗани Сәмәркандда ике ел торгач, тагы Бохарага кайта. Анда янә 4 еллар чамасы тора. Соңыннан, 1849 елда Казанга кайта. 1850 нче елда указ алып, беренче мәхәллә мәсҗеденә мулла булып, 40 ел (үлгәнче) шунда имамлык кыла һәм мәдрәсә тотып дәрес итә. Үзенең хөр фикерлеге, тәнкыйтьчелеге, каты теллелеге сәбәпле, ике мәртәбә муллалыкдан чыгарылып булса да, соңыннан шул урында ныгып кала һәм 1877 елда ахун-мөхтәсиб була. Мәрҗани Казандагы «Учительская школа»да 9 ел дин укыта. 1880 нче елда хаҗга барып, Гарәбстан һәм Төркиягә сәяхәт итеп кайта вә Солтан Габделхәмит тарафындан кабул ителә вә бик зур хөрмәт күрә. Мәрҗани

Казандагы мөстәшрикъләр (ориенталистлар) белән таныша, аралаша. Тарих тикшерә, җыелышларына йөри вә аларның мәҗмугаларында мәкаләләр дәрҗ итә[1]. Мәрҗани әллә ничә җилдлек тарихи вә дини әсәрләрен гарәпчә язган. Барысы 24ләп гарәпчә язган әсәре санала. Мәрҗани – гарәб телендә бик оста язучыларның берсе, аның дини мәсьәләләрдәге тәнкыйди карашлары күбесе һәм төплеләре шул гарәб телендәге әсәрләрендә язылган. Шул әсәрләре аркылы ул мөселман руханилары (бигрәк дә татар руханилары) арасында фикри дулкын, дини бер яңгыр тудырды. Татар телендә язган әсәрләре «Вафиятел-әсляф»ның мөкатдимәсе, «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» һәм дә «Гыйляләтез-заман фи тарихи Болгар вә Казан» һәм дә хаҗ сәяхәте хакында язган рисаләседер. Мәрҗани хәзрәтнең бу тарихи китаплары – безнең халыкда үзебезнең шәүкәтле дәверләрмезне искә төшергән беренче китаблардыр. 18 апрельдә 1889 елда Мәрҗани хәзрәт Казанда вафат итә.

*Разия Дәүләткилде*

*Мәкалә Разия Вәлиулла (Дәүләткилде) тарафыннан язылып, 1936 елның 17 гыйнварында «Милли байрак» газетасында басыла.*

*Текстны басма өчен Ләйлә Гарипова әзерләде*

## Шиһабеддин хәзрәт кичәсе

19 гыйнварда кич сәгать 9 да мәктәб бинасында Мукден Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте идарәсе тарафындан Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең тууына 120 ел тулу мөнәсәбәте илә бер җыелыш ясалды. Мәҗлескә бөтен бу оешма әгъзалары һәм мәктәб шәкердләре дә килгәнлекдән, сәгать 9 тулуга мәктәб бинасы халык белән шыгрым тулы иде. Сәхнәгә милли байраклар белән бизәлгән мәрхүм Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең рәсеме куелган вә сөйләүчеләр өчен махсус көрси хәзерләнгән иде. Мәҗлесне идарәнең кятибе Әхмәдшаһ әфәнде

[1] Дәрҗ итә – бастыра.

Гыйззәтулла[1] өчен, мәктәб шәкерде Гаяз Уразбәков тарафыннан мәрхүмнең рухына багышланып Коръән укылды. Мәктәб мөгаллимәсе Разыя ханым Дәүләткилде[2] озын вә тәфсилле мәгърузәсе[3] белән мәҗлесне Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле вә иҗады белән танышдырып узды. Мәктәб шәкердләре: Мөнирә Багдаш һәм Габделәхәд Хөсәен Шиһаб хәзрәткә багышлап язылган шигырьләрене укыгандан соң, Рокыя туташ Мөхәммәдиш,[4] Мәрҗани хәзрәтнең тарихчылык юлында иткән хезмәтләренә туктап, безнең үзлегебезне саклау юлында Шиһабеддин хәзрәтнең, хезмәтләренең никадәр әһәмиятле булуын аңлатды. Мондан соң бөтен халыкга чәй тәкъдим ителде. Чәй арасында мәшһүр дин галимебез хакында төрле хатирәләр сөйләнде. Чәйдән соң хөрмәтле әдибемез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабләре Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең безнең халыкны тәгассыб[5] юлындан чыгуына вә үзен үзе тикшереп карый, үзенә бәһа бирә белү дәрәҗәсенә җитүенә сәбәбче булуын нигез ташы итеп алып, озын вә гаять тәэсирле нотык сөйләде. Шиһаб хәзрәт хөрмәтенә хәзерләнгән мәрасим[6] тәмам булгандан соң, оешма халкының бергә туплануындан файдаланып, Әхмәдшаһ әфәнде Гыйззәтулла идарәнең елдагы гадәте буенча «шәрык кичәсе» кую фикерендә икәнлеген мәҗлескә белдерде. Бу мәсьәлә халык тарафындан бик зур разыйлык белән каршы алынганга, шунда ук кичәдә булачак латари[7] төзәр

[1] Әхмәтшаһ Гыйззәтулла (1901–1972), чыгышы белән Казан губернасының Акъегет авылыннан. 1917 елдан соң Казахстанның Кызылъяр шәһәрендә, 1920–1921 елларда Кытайда яши. 1935–1945 елларда Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татарларының дини-милли хәрәкәт эшчәнлегендә актив катнашучы.

[2] Разыя ханым Дәүләткилде – Разыя Вәлиулла (Дәүләткилде) Мукден татар мәктәбендә укытучы, 1927–1933 елларда И. Дәүләткилденең хатыны.

[3] Мәгърузәсе – доклады.

[4] Рокыя туташ Мөхәммәдиш – Рокыя Сабирҗан кызы Мөхәммәдиш (1908–1989), укытучы, публицист, тәрҗемәче. Ерак Шәрык төрек-татарларының милли хәрәкәте активисты, «Милли Байрак» газетасының җаваплы хезмәткәре.

[5] Тәгассыб – фанатизм.

[6] Мәрасим – церемония.

[7] Дөресе: лоторея.

өчен акча да җыелып алынды. Вә латари кору мәсьәләсе ханымнарга тапшырылып, алардан якын арада бу эшкә тотынулары риҗа ителде[1]. «Шәрык кичәсе»н февральнең беренче атнасында ясарга булып мәҗлес ябылды.

*Мәкалә «Милли байрак» газетасының 1936 елгы 24 гыйнвар (12 нче сан) санында имзасыз дөнья күргән.*

*Текстны басма өчен Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәт кичәсе

*Токио мәхәлләсендә*

Ошбу ел 19 нчы гыйнвар мәрхүм Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең тууына 120 ел тулу мөнәсәбәте илә шул көн кич махсус җыелыш ясалды. Идел-Урал төрек-татар мәдәнияте җәмгыяте әгъзалары балалары илә хазир булдылар[2]. Мәҗлес алдына мәрхүмнең рәсеме куелды. Җәмгыятьнең рәис вә имамы Гали әфәнде Дашкин бүгенге җыелышның морад икәнен аңлатканнан соң, мәрхүмгә хөрмәт йөзендән бер дакыйкә аякка калкып тәгъзыйм итүне[3] тәкъдим иткәч, мәҗлес аякка калыкды. Мондан соң имам Гали әфәнде Коръән укып, мәрхүмнең рух шәрифләренә багышлап дога кылдырды. Андан соң мәрхүмнең кыскача тәрҗемәи хәле сөйләнде. Аның дин вә милләт юлында иткән хезмәтләре вә шул юлда, мәрхүм никадәрле авырлыкларга очраса да, ул һич үзенә каршы килгән манигъларга[4] карамыйча милләтен агарту юлында дәвам иткәнлеге аңлатылды. Мәрхүмнең милләте өчен иткән хезмәтләрене вә язып калдырган юлларыны күз алдыбызда тотып, без дә милләтебезнең истикъляли өчен хак юлыбыздан барчабыз да бер тән, бер җан булып дошманнарыбызның киртә салуына карамыйча, армый-талмый эшләргә тиешбез дип сүзен тәмам иткәч, [...] Коръән укып мәрхүмнең рухына, ушандак[5] дин вә милләт юлында шәһид булганларның

[1] Риҗа ителде – соралды.

[2] Хазир булдылар – шунда булдылар.

[3] Тәгъзыйм итүне – олылауны.

[4] Манигъларга – киртәләргә.

[5] Ушандак – шулай ук.

рухларына багышлап, мәҗлес шуның илә тәмам булды вә җыелыш да кич сәгать 9 да таралды.

*Мөхбир*

## *Хайлар төрек-татар мәктәбендә*

Бөек юлбашчыбыз, милләт каһарманыбыз мәрхүм Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең тууына бу елның 19 гыйнварында 120 ел тулу мөнәсәбәте белән шушы көннең без Идел-Урал төрек-татарлары өчен нинди зур бәйрәм икәнен вә бу көннең [...] үтәр өчен Хайлар төрек-татар мөселман мәктәбендә мәрхүмнең мирас итеп калдырган кыйммәтле хезмәтләрен тәкъдир итәрәк искә алу мәҗлесе ясалды. Шәкердләргә бу хакда мәгълүмат бирелгәндән соң, 4 нче вә 5 нче сыйныф шәкердләре тарафыннан гүзәл мәкам белән Коръән укылып, мәрхүмнең рух шәрифләренә багышланды. Андан соң мәрхүмнең тәрҗемәи хәле сөйләнде вә милләтемезгә күрсәткән олуг хезмәтләре хакында мәгълүмат бирелде. [...] бәйрәмне бөтен мәхәллә белән бергә туплап, тагы да тулырак вә тантаналырак уздырырга дигән теләк булса да, хөрмәтле имамыбыз Хатип хәзрәт Халиди[1] бүгенгә кадәр азад ителмәгәнгә күрә, мәктәбемездә шәкердләр белән генә үткәреп канәгатьләнергә тугры килде. Шушы көнне мәхәлләбез тарафыннан мәсҗеддә өйлә намазы укылып, намаздан соң Коръән укылып, мәрхүм Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең рух шәрифләренә багышланды.

*Зөһрә Кугуш*

## *Харбин мәхәлләсендә*

Харбин мәхәлләсенең хәяты һаман табигый юлга салынып җитмәгәнлекдән, Харбинда яшәүче илдәшләребез бөек гали-

---

[1] Хатыйп хәзрәт Халиди – Хатыйп Халиди (1893–1977), имам, җәмәгать эшлеклесе. Тумышы белән Татарстан Республикасының Апас районы Карамасар авылыннан. 1917 елның көзендә Россиядән Төньяк Маньчжуриядәге Хайлар шәһәренә, соңрак Тяньцзинь шәһәренә күчеп китә. 1936–1948 елларда шунда яши, төрки-татар җәмәгатьчелеге арасында мөгаллим һәм имам вазифасын башкара. 1948 елның көзендә Истанбулга килеп урнаша, 1977 елны биредә вафат була.

мебез Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең тууына 120 ел тулу мөнәсәбәте белән 19 гыйнварда махсус тупланыш ясый алмадылар. 24 нче гыйнварда, җомгадан соң, Мөнир хәзрәт Хәсбиулланың[1] тәкъдиме буенча Госман әфәнде тарафыннан гүзәл мәкам белән Коръән укылып, мәрхүм Шиһабеддин хәзрәтнең рух шәрифләренә багышланды.

*Җомгада булучылардан берәү*

*Фузан милләтчеләрендә*

Фузанда яшәүче милләтчеләр, 19 нчы гыйнварда имам Вәлимөхәммәд әфәнде Гобәйдулланың йортында җыелып, Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең тууына 120 ел тулуны бәйрәм итделәр. Вәлимөхәммәд әфәнде тарафыннан мәрхүмнең рухына Коръән укып багышланганның соңында аның тәрҗемәи хәле сөйләнде вә халкыбызга иткән бөек хезмәтләре күздән кичерелде.

*Хәбәрче*

*Әлеге хәбәрләр «Милли байрак» газетасының 1936 елгы 31 гыйнвар (№13) санында дөнья күргән.*

*Текстларны басма өчен Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Шиһаб хәзрәт кичәсе

Мукден яшьләр түгәрәге 19 гыйнварда Шиһабеддин хәзрәт Мәрҗанинең туган көне булу уңае белән мәктәб бинасында, кич сәгать 9 да бер тупланыш ясадылар. Тупланыш мәрхүм остазыбызның рух шәрифләренә Коръән укып багышлангач, Рокыя туташ Мөхәммәдиш вә Мансур әфәнде Арсланбәк тарафыннан

[1] Мөнир хәзрәт Хәсбиулла – Мөнир Хәсбиулла (1896–1944), Харбин шәһәре төрек-татар мәхәлләсе имамы.

Шиһабеддин хәзрәт хакында мәгърузәләр[1] укылды. Мәктәб шәкердләре тарафыннан бу көнгә тәгаллекъле шигырьләр сөйләнде.

*Әлеге хәбәр «Милли байрак» газетасының 1937 елгы 22 гыйнвар (№60) санында имзасыз басылган.*

*Текстны басма өчен Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

[1] Мәгърузәләр – докладлар

# III бүлек
# Хатлар

*«Гыйлемнәр тирәнлегенә ирешкән һәм мөхтәрәм, башкалардан өстен, белемле мәгъруур остаз...»*

*Х.Фәезханов*

## Мәрҗани мәктүбләре

Мәрҗани хәзрәтләре үз гомерендә иң күп мәктүб язган һәм дә мәктүбләрнең мөндәриҗәсе[1] гыйльми, әдәби вә фәнни мәҗлесләргә даир булган[2] адәмнәрнең бере булса кирәк. Күп адәмнәр үз кулларында саклана торган Мәрҗани мәктүбләреннән нөсхәләр язып җибәрделәр. Вә бәгъзеләрдә асыл нөсхәләрне күндерделәр. Шул сәбәпле бездә Мәрҗани мәктүпләреннән күп нәрсә җыелды. Китапның озын булуыннан куркып, без бу мәктүпләрнең һәрберсен түгел, бәлки кайберләренең әһәмиятле җирләрен генә чүпләп, бу йирдә күчерәмез. Нәмүнә[3] өчен, Иншаллаһ, шулай кифаять кылыр[4] (бу сүзләр – «Асар»да язган сүзләрдер. Бу мәктүпләрне күчерергә теләүчеләр «Асар»га мөрәҗәгать итәрләр). Ләкин Габделхәбир әл-Мөслимигә язган хатларын хосусый мәктүпләр илә дә, матбугат васитасы[5] илә дә эзләп карадык исә дә, һәнүз табып булмады.

Оренбург Духовный Собрание архивында түгәр өчен дип әрҗәгә тутырылган чүпләр, кирпеч вә пыяла ватыклары арасында табылган бер мәктүбнең клишесе бу йиргә куеладыр.

---

[1] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.

[2] Даир булган – бәйләнеше булган

[3] Нәмүнә – үрнәк.

[4] Кифаять кылыр – җитәр.

[5] Васитасы – чарасы.


بسم الله الرحمن الرحيم

Мәрҗани хәзрәтләренең Казан шәһәреннән Уфадагы Духовный Собрание әгъзасы Мөхәммәди казыйга язган мәктүбе

*Хатның хәзерге графикага күчерелгән тексты түбәндәгечә:*

Бисмилләһир-рахмән-ир-рахим

Газизел надир кирам вә мөхтәрәм старший казый наиб мәнаб мөфти дамелла Мөхәммәди бине Саләх әл-Гомәри җәнабе сәгадәт мәабләренә, әһле-әүладларына ихтирам үзрә, бәгъдә әс-сәлам сөннәтел-ислам аңар җаниб тәкыйулла әлхәмде!

Шәһре рамазан әл-мөбарәкне хушлык үзрә гизәр итебмез. Эчемез сахих улды, ләкин бәгъдел-гаед кәефемез тәбәддел табып, берничә нәхуш ак булып торамын. Хак Тәгаләә бихәер әйләйә. Без бу сәнә гаеде фитырны яуме дүшәмбе укыдык. Әһле

бәлдә вә әһле карья, бәгъзән ул да безнең берлә, арадамыз. Һәм дүшәмбе укырга мелла хөҗҗәтемез һәм юк иде. Ләкин меллалар үзләре әксәре иттифакъ итеп, дүшәмбе укымак булып күп йиргә, әтрафка һәм хәбәр салганнар. Әмма безгә бер дә хәбәр итмәделәр вә мәхәллә һәм килмәй тәмам карар биргәннәр. Безгә хөҗҗәтләрене күргәзмәделәр. Шул әснадә казый мелла Җәлалдән телеграф килде. Бездә гаед шимбә, дийү ул хәбәрне игълан кылып кәгазь йибәрдек. Аны ишеткәннәр янә кул куймадылар, кабул итмәделәр. Марра ухра хөҗҗәт язуыгызны йибәреңез, йә үзеңез килеңез дигәч, хөҗҗәтләр китереп күргәзеп безнең гыйндемездә билә шөкер, ул рамазан шимбәдә сабит ай күренмәсә, һәм дүшәмбе укыймыз дип, исрар итеп, без һәм аерылып калмакны мөнасиб күрмәймен. Һәм сезгә тәкълид берлә укыймын дип, кулларыннан язу алып, кул куйдырып алып, мөтәбагыйд иттек. Вәссәлам идәм. Хиҗри яумел 11 шәүвәл, сәнә 1302. Мелла Шиһабетддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани. Биссаләме.

*Хәзерге әдәби телгә күчермәсе:*

Бисмилләһир-рахмән-ир-рахим

Аеруча хөрмәтле, кадерле һәм мөхтәрәм «старший»[1] казый һәм мөфти урынбасары дамелла Мөхәммәди бине Саләх әл Гомәри әфәндегә һәм аның гаилә әгъзаларына яшәгән җирләрендә һәм тирә-якта ислам гадәтләре, бәхет, ихтирам һәм мактаулар булсын!

Хөрмәтле рамазан аен шатлык белән үткәрәбез. Өй эчемез сәламәт, исән-саулык. Ләкин бәйрәмнән соң, кәефебез үзгәреп, беркадәр кәефсез булып агарынып торамын. Хак Тәгалә яхшыга юрасын.

Без быел гает фитырын дүшәмбе укыдык. Шәһәр халкы да, авыл халкы да. Кайвакыт ул да безнең берлә арада. Һәм дүшәмбе укырга мелла таныклыгыбыз (указыбыз) юк иде. Ләкин меллалар үзләре, күбесе берләшеп, дүшәмбе укырга булып, күп җиргә, тирә-якка хәбәр таратканнар. Әмма безгә хәбәр итмәделәр, шуңа күрә мәхәллә халкы килмәскә карар биргән. Безгә таныклыкны (указны) да күрсәтмәделәр. Шул арада: «Бездә гаед шимбә»

[1] Гарәпчә текстта да русча бирелгән.

дип, казый мелла Җәлалдән телеграф килде. Ул хәбәрне игълан итеп кәгазь җибәрдек. Аны ишеткәннәр янә кул куймадылар, кабул итмәделәр. Икенче юлы дәлил булырлык язу, документыгызны җибәрегез, я үзегез килегез дигәч, безнең яныбызда, бик шөкер, дәлил булган аргументлар китереп күрсәтеп, ул рамазан шимбәдә, ай ачык күренмәсә, дүшәмбе укыйбыз дип, сүзебезне ныгыттык. Һәм без аерылып калуны яраклы күрмибез дип, кулларыннан язу алып, кул куйдырып алып аерылыштык.

Тәмам итәм. Хиҗри белән шәүвәлнең 11 нче көне, 1302 ел. Мелла Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани. Сәлам юллап.

*Гайнан бине Вилдан*

*Язма «Шура» журналының 1914 елгы 8 нче санында басылган.*

*Текстны һәм тәрҗемәне басма өчен Гөлназ Алиева әзерләде*

## Хөсәен Фәезхановның Ш. Мәрҗанигә хатлары

## Учитель и ученик: о переписке Х. Фаизханова и Ш. Марджани

*Вниманию читателей предлагается переписка двух выдающихся деятелей татарской науки XIX века Шигабутдина Марджани (1818–1889) и Хусаина Фаизханова (1823–1866). Данная переписка впервые была подготовлена татарским ученым и редактором Ризой Фахретдином и была опубликована в его книге «Асар» («Следы») в 14-й части 2 тома. Оставшиеся письма были напечатаны в журнале «Шура» («Совет») в 1916 году. Часть писем, которые в основном были написаны рукой Х.Фаизханова, в 1980 году были введены в научный оборот на русском языке археографом М.А.Усмановым в его книге «Заветная мечта Хусаина Фаизханова». Позже, в 2006 году эти письма опубликовал на современном татарском языке археограф Р.Ф.Марданов в сборнике «Хөсәен Фәезханов:*

*тарихи-документаль җыентык». Наиболее полный пере-вод писем на русский язык осуществил А.М.Ахунов в сборнике «Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: историко-документальный сборник». В дополненном и исправленном виде эта книга была переиздана в Москве в 2018 году*[1].

*В данной публикации использованы переводы на современный татарский и русский языки, выполненные Р.Ф.Мардановым и А.М.Ахуновым.*

Хусаин Фаизханов родился в деревне Сабачай (Сафаджай) Курмышского уезда Симбирской губернии (ныне село Красная Горка Пильнинского района Нижегородской области). Благодаря стараниям татарского ученого-богослова Шигабутдина Марджани, которому удалось восстановить шеджере рода Фаизхановых, мы имеем представление о его предках. Известна следующая цепочка: отец – государственный крестьянин Фаизхан, дед Файзулла, прадед Биккина, далее Исмагил и Тангрибирди ал-Джабали ас-Сабачаи ал-ханафи. Позднейшие изыскания ученых позволили документально подтвердить правильность родословной.

Способный Хусаин перебрал много старометодных сельских медресе, в большинстве которых его не устраивала схоластика. Таким образом, он оказывается в медресе Шигабутдина Марджани.

Это был 1850-й год. Марджани после одиннадцати лет скитаний на чужбине, куда он отправился за поиском знаний, наконец-то вернулся в Казань. Слава о нем шла впереди каравана, который вез его на родину. В Казани он получил должность имама и мударриса, а это значило, что его знания, его ученость признали не только местные мусульмане, но и татарские купцы-баи, без финансовой поддержки которых ни медресе, ни мечеть не смогли бы существовать и функционировать. В тот год Шигабутдин Марджани взял себе семьдесят шакирдов, среди

[1] Письма Хусаина Фаизханова Шихабутдину Марджани (пер. А. М. Ахунов) //Нерасторжимая связь: письма Хусаина Фаизханова Шихабутдину Марджани. 2-е изд. испр. и доп. Москва: Медина, 2018. С. 53–184.

них был и Хусаин. С этого дня началось их сотрудничество: сначала как учителя и ученика, а позже как двух равноправных ученых, двух знатоков и ценителей древних манускриптов.

Марджани щедро делился своими знаниями, но со временем Хусаин понял, что для дальнейшего образования ему надо обратиться и к европейской науке. В Казани он сотрудничал с некоторыми казанскими востоковедами, в особенности с А.К.Казем-Беком, И.Н.Березиным, с которыми, видимо, познакомился при посредничестве своего учителя. Целеустремленный, стремящийся к знаниям Фаизханов мечтал о продолжении учебы, но после долгих размышлений выбрал не традиционную Бухару, а Санкт-Петербург – центр иного мира и цивилизации. Марджани, который поначалу не хотел отпускать своего ученика и всячески его отговаривал, позднее согласился, надеясь, что его любимый шакирд станет своего рода мостом между ним и европейской наукой, к которой он также стремился.

Важным фактором отъезда Фаизханова послужило и то, что в 1854–1855 годах Восточный разряд Казанского университета был переведен в Петербург. Все именитые востоковеды также переехали в столицу. Первым деканом нового факультета стал А.К.Казем-Бек, который и пригласил Фаизханова к себе на работу.

Дата переезда Фаизханова в Петербург точно неизвестна, но то, что во второй половине 1854 года он уже находился в столице, полностью подтверждается документально. На новое место жительства он перебрался с коллекцией рукописей, которые ему пришлось продавать на первых порах по причине тяжелого материального положения. Именно в Петербурге Хусаин Фаизханов раскрылся как ученый общероссийского масштаба, который по своим знаниям, эрудиции, научной подготовке ничем не уступал именитым русским востоковедам.

В Петербург Фаизханов приехал с солидным научным багажом, пройдя школу Ш. Марджани. Сочетание специфической татарской востоковедческой подготовки и освоение русско-европейской научной методики, плюс талант и трудолюбие самого Фаизханова и сформировали его как уникального

ученого.

На протяжении всей своей жизни он вел переписку со своим наставником Шигабутдином Марджани. Он ставил его на голову выше многих мусульманских ученых того времени, делился с ним своими мыслями и находками, просил совета, морально поддерживал в период гонений, в целом, выполнял роль посредника между восточной и европейской культурами.

Фаизханов обращался в письмах к наставнику крайне уважительно, не иначе как: «олицетворяющему собой обитель славы и почести, Вашему превосходительству, уважаемому учителю, с уверениями в нашей искренности и преданности», что говорило о том, что Марджани для него был и остается непререкаемым авторитетом.

Их переписка открывает нам двери в творческую лабораторию Фаизханова и Марджани. Из них можно понять насколько серьезно оба ученых относились к источникам, к достоверным фактам, которые они пытались добыть любым путем. В письмах перечисляются книги и авторы, к которым обращались ученые. Это значит, что и Марджани, и Фаизханов опирались в своих работах на серьезную источниковую базу, хотя и не всегда отражали это в своих книгах.

Кроме того, письма несут важную информацию о повседневной жизни Петербурга и Казани XIX века, ярких событиях, связанных с жизнью мусульман Российской империи, здесь упоминаются имена видных деятелей науки, политики и дипломатии того времени.

Напряженный, упорный, непосильный труд, сырой климат северной столицы подорвали здоровье ученого, что привело весной 1865 года к обострению болезни. В конце мая Фаизханов, не решившись на дальнюю поездку в киргизские степи, едет в Уфимскую губернию. Отступившая к зиме болезнь весной 1866 года усиливается вновь. Он пишет в Казань учителю, что его состояние сильно ухудшилось и держится он только благодаря поддержке своей супруги. Но и в этот сложный жизненный момент он не забывал про своего наставника, переживал, что не сможет и дальше оказывать ему помощь. «Я никак

не смог исполнить ни одного Вашего поручения. Прошу прощения», – писал он Ш. Марджани. Хусаин Фаизханов скончался 28 августа 1866 года, похоронили ученого в родном ауле.

*Азат Ахунов*

**Беренче хат[1]:**

«Шөһрәтләрнең сыену урыны, гыйлеме белән мәшһүр хөрмәтле остазыбызга буйсынуыбыз һәм тугрылыклы булуыбызны белдереп, сез мәрхәмәтлебез белергә теләсәгез, Аллага шөкер, сәламәтлектә һәм исәнлектә икәнлегебезне хәбәр итәм. Шуннан соң 19 нчы июльдә сау-сәламәт Петербург шәһәренә килеп җитү насыйп булып, гаиләм, дус-ишләрне, Аллага мактау булсын, сәламәтлектә таптык. Сезнең тарафыгыздан янгын афәтеннән соң язылган хатыгыздан соң хат алганым юк. Мелла Габделлатыйф сәламәт вә исәнлек хәбәрегезне китерде, үзем дә ватанга кайтканнан һәм монда кайтканнан соң да хат яза алмадым, кичерегез.

Бу тарафта язарга лаек һичбер яңа хәбәр юк. Бохарадагылардан хат алганым юк, Иншаллаһ, Сезләргә хатлары килгәндер.

Ул тарафта нинди хәбәрләр бар? Быел муллалар кайтканы юкмы яки кемнәр кайттылар һәм кешеләр ничек? Хаҗилардан хәбәр бармы? Сәламәт кайталармы икән? Казан мөселманнарына, гомумән, бик зур каза булган. Мактаулы һәм бөек Алла хәерле каза кылсын! Сезләргә дә күп зарар булса да, шул таш нигезегез калуы да бәхет. Мелла Габделлатыйф агай бездә биш-алты көн торды. Бик яхшы суфи булган. Мәгърифәте һәм гыйлеме җәһәтеннән минем әүвәлдә дә аңа ихласым юк түгел иде. Хәзер яхшы әхлакы җәһәтеннән тагын да ихласым артты. Аерым алганда, Сезләргә камил ихласлыгын да аңлатты һәм һәрвакыт хәерхаһ булганлыгы беленде. Йортыгызны шаять бераз киртәләп торырлык итеп ясагансыздыр? Ярдәм итүче булмадымы?

Мин фәкыйрегез хәзергә иске фатирда торам. Ләкин тиздән

[1] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз-авт. Р. Мәрданов. Казан: Җыен, 2006. Б. 337–338.

күчәргә ният кылам. Бу фатирыбыз ерак булса да, җәй өчен бик яхшы, әмма кыш көннәр бераз дымлылык була ки, яшь балалар өчен бу җирдә бик зарарлы. «Вафийәт»егезне тәмамладыгызмы? Яки «Шәрхе гакаид»егезне тәмам иттегезме? Дамелла Габденнасыйр әл-Курсавиның «Мөфассаль шәриф»кә булган тәфсирен күргәнегез бармы? Быел авылга кайткач, үзебезнең авылыбызда бер муллада күргән идем, яхшы күренде. Хәтта бастыру нияте дә кылам. Бу хакта Сезнең карашыгыз ничек? Бастыру кирәкме? Әгәр дә Сез хупласагыз, бәяләмә язарсызмы? Бәяләмәгезне дә бастырыр идек. Хат язарга ниятләсәгез, бу юлы мулла Мөхәммәдгалим Хантимеров исеменә «Чернышев мостта Литкин өенә» дип, русча һәм шуннан соң мөселманча «Хөсәенгә бирелсен» дип язгыгыз.

Үтенеп, фәкыйрегез Хөсәен.

*1859 ел, 17 июль».*

*Русчага тәрҗемәдә*[1]*:*

Выражая верность и преклонение известному своими знаниями уважаемому нашему наставнику, олицетворяющему собой вместилище всех славных дел. Если Вы, милостивый, хотите узнать о наших делах, то сообщим, что мы, слава Аллаху, в добром здравии.

19 июля мы целыми-невредимыми вернулись в Петербург и нашли, да вознесется похвала Аллаху, свою семью, друзей-знакомых в полном здравии. От Вас пока не получал писем, кроме того, что Вы написали мне после пожара. Мелла Абдел-латиф принес мне весть о Вашем здравии, а сам я, будучи на родине, да и после возвращения сюда, никак не мог написать Вам весточки, Вы уж простите.

С нашей стороны нет ничего интересного, о чем можно было писать. Вернулись ли в этом году муллы, кто возвратился и как они? Нет ли вестей от хаджиев? Нет ли ущерба их здоровью?

[1] Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: историко-документальный сб. / пер. со старотат. А.М. Ахунова и И.Ф. Гимадеева; сост. и отв. редактор Д.В. Мухетдинов. Н. Новгород: Медина, 2008. С. 95–96.

Казанским мусульманам пришлось перенести большую беду. Да пусть восхваляемый и великий Аллах поможет побыстрее избавиться от этих бед! Хотя неприятности не обошли стороной и Вас, но, по крайней мере, сохранилось каменное основание Вашего дома. Мелла Абделлатиф оставался у нас 5–6 дней. Очень хороший суфий. Что касается его просвещенности, то я и раньше никогда не сомневался в этом. Но после того, как еще раз убедился в его высокой нравственности, мое искреннее и доброе отношение к нему только увеличилось. В свою очередь он пояснил, как искренне уважает Вас, ценит Ваше доброе и сочувственное отношение к нему. Что-нибудь делается, чтобы Ваш дом стал пригодным для проживания? Есть ли помощники?

Я, все еще живу на старой квартире. Но скоро собираюсь переезжать. Квартира находилась далековато, но для лета вполне годилась, однако зимой страдали от влажности, что вредно для детей. Закончили ли «Вафият»? Завершаете ли «Шархе акаид»? Приходилось ли Вам встречать тафсир «Муфассаль шариф» дамеллы Абд ан-Насыра Курсави? В этом году в деревне видел его у одного нашего муллы. Впечатление благоприятное. Даже задумался о том, не напечатать ли его? Что Вы думаете насчет этого? Нужно ли его печатать? Если Вы одобрите эту идею, то сможете ли написать отзыв? Мы бы и его опубликовали. Если будете писать мне, то указывайте следующий адрес: «Мулле Мухаммадгалиму Хантимерову. Чернышев мост. Дом Литкина». И припишите по-мусульмански: «Хөсәенгә бирелсен» («Передать Хусаину»).

Испрошающий и покорнейший слуга Хусаин, 1859, 17 июля.

## Икенче хат[1]:

«Шөһрәтләрнең сыену урыны булган Сез галиҗәнапләргә, мөхтәрәм остазыбызга ихласлар һәм тугры булуыбызны белдергәннән соң, без фәкыйрь тарафындагы хәлләрне белергә теләсәгез, Аллага шөкер, һәм мактаулар булсын, хәзерге вакытта

[1] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз-авт. Р.Мәрданов. Казан: «Җыен», 2006. Б. 340–341.

исән-иминмен.

Мирза «Мин гайре истиснаи әгъйане ислам»ны тәрҗемә итеп бастыра. Минем «Тәфсире рухел-бәйан»ны укыганым юк, бер унбиш минут кадәр генә караган идем, ләкин Ибраһим Хаккыйга ихласым бар. «Мәгърифәтнамә»сендә вөҗүд һәм рух, нәфес мәсьәләләрендә булган сүзләренең күбесе минем инануыма муафыйк. Шуңа күрә тәфсире дә файдасыз булмас дип уйланыла. «Җәбәрти»нең беренче томының яртысы кадәр, минем хәтеремдә тора, һаман кайтарганым юк. Чөнки бераз зиһене чуалган. Монысын кайтарып, калган томын сорый барсам, анысын да, әүвәлгесен дә бирмәс дип уйлыйм. Бу томнан тулаем сайлап күчереп, мин Сезгә җибәрдем. Ләкин кайбер шафигыйлар вә мәликиләр мәшһүр түгелләр һәм күпчелек әдипләр вә философлар госманлылар, хакимнәр вә әмирләргә золымлы һәм бозык, аларны кертмәдем. Чөнки Сезнең максатыгыз – ислам гыйлеме тарихы һәм сахәбәләр, табигыйннар һәм элекке изгеләр гыйлеменең, хосусан хәнәфиләрнең безнең көннәргәчә элемтәсе. Икенчедән, үзегез: «Шафигыйләр һәм мәликиләрнең мәшһүрләре булмаса кирәк түгел», – дигән идегез. Имам Гасякир урынына кайбер халыклар ялынгач һәм йөдәткәннән соң аларга яхшылык йөзеннән ризалык күрсәткән идем. Аннары кайберәүләр аларга каршылык итәр кебек булгач, «риза булмам» дип, катгый җавап бирдем. Чынлыкта, хәзер алдыма китереп куйсалар да, өстемә алмам, мәгәр ки шәфкать йөзеннән йотсам йотармын.

Якут «Мөгъҗәмел-бөлдан»ын Казанда күрдем дигәнсез. Бу хәбәр – безнең өчен зур шатлык. Алкиндамы, бөтенме, дөресме? Ничек итеп аны алырга мөмкин? Күчереп язу беләнме? Мирза арадашлыгы белән хат языйммы? Яки Академия исеменнән сорыйммы? Яки анда шәкертләрдән һәм муллалардан яздырып буламы? Бу китапны кулга төшерү өчен, Казанга махсус бару һичнәрсә түгел. Сатарлык булсалар, бик начар хаталы булмаса, кыйммәт биреп алыр идек. Монда Академиядә бер тулы нөсхә бар, ләкин бик хаталы. Пруссия башкаласында да бер нөсхә бар, ул да хатасыз түгел. Лондонда бер нөсхә бар, анысы, бик яхшы нөсхә. Аннан гайре һич җирдә юк. Французлар быел

Солтан китапханәсеннән яздырып алганнар. Әгәр дә яхшы нөсхә табылса, Академия бастырмакчы була. Бастырган очракта ул эш башкаларның ярдәме белән миңа йөкләнүе ихтималга якын. Кыскасы, «Мөгъҗәмел-бөлдан»ны белешеп, мин фәкыйрьгә хәбәр язсагыз, бик сөендерер идегез. Монда алдырырга насыйп булмаганда үзем Казанга махсус барып, берничә шәкерттән яздырып, үзем бик дикъкать белән чагыштырып китерер идем.

«Мөккаддимәи Ибне Хәлдун»гә ия булырга телим. Аннары «Рихләте шәйхе Рәфага»ны юнәтергә насыйп булмасмы? Чиркәс Гомәр әфәндегә хыянәт итеп, аның китабын Нәҗипләргә җибәргән идем, ул китап анда вакытлыча бирелгән. Үзенеке булса, бер сүз дә әйтмәс иде. Аның алдында бик оятлы булдым. Биш-алты тәңкәгә бик риза булып алыр идем. «Шәмаиле Тирмизи»дән гаять дөрес һәм «Гали әл-Карый шәрхе»ннән күчерелгән бер нөсхә бар. Академия акчасына бастырмакчы булабыз. Хәзергә ул нөсхә минем кулымда, бик мөбарәк нөсхә, әмма бик иске түгел. Моннан 110 ел элек кенә язылган. «Мөгъҗәмел-бөлдан» хакында җавабыгызны интизар булып көтәм.

*1859 ел, 24 декабрь»*

*Русчага тәрҗемәдә[1]:*

Олицетворяющему собой обитель славы и почести, Вашему превосходительству, уважаемому учителю, с уверениями в нашей искренности и преданности.

Если возникнет интерес к тому, как дела в наших краях, то слава Аллаху, узнаете, что все благополучно.

Мирза начал печатать без исключений «Айан Ислам». Тафсир «Рух ал-байан» читать не приходилось, лишь однажды подержал в руках – минут 15, не более. Насчет авторства склоняюсь к Ибрагиму Хакки[2].

Проблемы вуджут (существование), рух (дух), нафс

[1]Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: ист.-док. сб. / пер. со старотат. А.М. Ахунова и И.Ф. Гимадеева; сост. и отв. ред. Д. В. Мухетдинов. Нижний Новгород: Медина, 2008. С. 96 –98.

[2] Хусаин-эфенди предполагает, что автором «Рух ал-байан» был Ибрагим Хакки. – *Р.Ф.*

(самость), отраженные в «Марифат-наме», вполне соотносятся с моим мироощущением. Поэтому и тафсир не будет бесполезным, так мне кажется.

Первый том «Джабарти» до сих пор числится за мной. Если пойду просить следующий том, то, видимо, не получу его – не даст. Мало того, лишусь и первого. Из имеющегося на руках тома сделал избирательные выписки и выслал Вам. Тем не менее, не стал переписывать сведения о малоизвестных маликитских и шафиитских [деятелях], а также о том, что большая часть [лучших] писателей и философов – это османы, которые [проповедовали зло и распутство в отношении правителей и амиров. Ведь Ваша цель в том, чтобы показать, опираясь на историю исламской исторической науки, современную актуальность знаний асхабов, табиинов и святых, особенно ханафитов. Тем более что Вы сами писали: «Если среди шафиитов и маликитов не встретятся известные, то не надо».

«Имама Гасякира» некоторые деятели [предлагали] так сильно, буквально заискивая и унижаясь, что из чувства милости к ним поначалу сдался, но потом, увидев то противодействие, которое возникло по отношению к ним, резко сказал: «Не согласен!». Если сейчас даже и поставят перед носом, все равно не возьму на себя этот груз, даже если таким образом окажу им милосердие.

Пишете, что видели в Казани «Муджам ал-булдан» Якута. Эта новость – большая радость для нас. У кого, Алкина? Сама рукопись полная ли, верная ли? Как ее можно заполучить – сделать копию? Может ли Мирза стать посредником в этом деле? Или мне просить от имени Академии? Можно ли сделать копию с помощью тамошних мулл или шакирдов? Чтобы заполучить эту книгу, я готов даже ехать в Казань. Если будут продавать и если сам список хорош, без ошибок, готовы назначить высокую цену. В здешней Академии естъ полный список, но весь в ошибках. Один список находится в столице Пруссии, да и он не без погрешностей. Хорошая рукопись хранится лишь в Лондоне. Больше нигде нет. В этом году французы заказали копию из библиотеки султана. Если найдется хороший список,

Академия готова издать его. Если это дело выгорит, то перевод, видимо, возложат на меня. Естественно, при поддержке других [ученых]. Вообщем, если Вы узнаете все о «Муджам ал-булдан» и сообщите мне, ничтожному, то очень обрадуете. Если не получится организовать все отсюда, то тогда я сам специально поеду в Казань, закажу копию нескольким шакирдам, и после тщательного сравнения и изучения вернусь с ней обратно.

Хочу займетъ «Мукаддиму» Ибн Халдуна. А также может удастся достать «Рихла шейх Рифа»?

Совершил оплошность по отношению к черкесу Умару. Его книгу отослал Наджипу, а, оказывается, она была взята на время. Была бы своя, ни слова не сказал бы. Теперь очень стыдно перед ним. Был бы очень рад найти эту книгу за 5–6 рублей.

Есть один очень хороший список – из «Шамаил Тирмизи» и «Шарха» ‘Али ал-Кадыри. Хотим опубликовать его на средства Академии. Сейчас этот список у меня на руках – очень добротный, хотя и не достаточно старый. Был составлен 110 лет назад. С нетерпением жду от Вас ответа насчет «Муджам ал-булдан».

*1859 год, 24 декабря*

## Өченче хат[1]:

«Шөһрәтләрнең сыену урыны булган Сез галиҗәнапләргә ихласлык һәм тугрылыкны белдергәннән соң борчырга кыючылык итүнең бу ки: моннан ике атна элек Якут әл-Хәмәвинең «Мөгъҗәмел-бөлдан» китабы хакында белешеп, мин фәкыйрьгә хәбәр итүегезне үтенеп язган идем. Хәзер кабатлап, ул хакта камиллеге һәм җитешсезлеге турында үтенәм: җитешсез булган очракта ничә хәреф вә нинди хәрефләр барлыгын, төзек һәм кимчелеген язуыгыз көтелә. Бу көннәрдә Госманлы мәмләкәтләрендә булган китапханәләр каталогын укырга насыйп булды. Аны инглизләр бастырганнар. Алар арасында Җәбәрти һәм «Табакате Тамими» күп җирләрдә бар. Хәзер билгеле түгел,

[1] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз-авт. Р. Мәрданов. Казан: Җыен, 2006. 343-344 б.

[бәлки] тагын өч атнадан мәгълүм булыр, быел язда мине Академия тарафыннан ул илләргә җибәрүне фикер итәләр. Әгәр насыйп булса, Сезнең өчен күчереп алуыбыз мөмкин булыр иде. Тагын Сезнең тарихыгыгызны бу көннәрдә вакыт табып укыдым. Күп яхшы табам. Ләкин мин фәкыйрь җөръәт итеп тагын бер сүз әйтә алам: минем фикеремчә, ягъни һәрбер гыйлемнең нидән вә кемнәрнең тырышлыклары белән башланып һәм ничек киңәеп, үсеп никадәр дәрәҗәләргә җиткәнлеген вә ни сәбәптән төшенкелек тарафына киткәнлеген ачык, тәфсилләп язу тиеш иде. Мәсәлән, фикъһ гыйлеме, кәлям гыйлеме, мантыйк вә гарәп теле фәннәреннән синтаксис-морфология, мәгани (семантика), әдәбият теориясе һәм башкаларга ни сәбәптән ихтыяҗ төште һәм ни сәбәптән җыентыклар төзеделәр? Бу гыйлемнәрнең юнәлешләре үтемле булырга этәргеч ниләр булды һәм кайсы заманнарда үтемле булдылар? Түбән төшүләренә сәбәпләр булды, бу гыйлемнәргә кемнәр күп хезмәт иттеләр һәм әүвәлге дәрәҗәләреннән никадәр менгерделәр? Шулай ук исемнәр һәм нәсәбләрне бик игътибар белән дөресләп хәрәкәләр белән язу яки искәрмәдә тулыландырырга кирәк. Мәсәлән, мин Мисгарь исемен бер сәгать эзләдем. Аны, ни өчендер, «Мөсәгъгыйрь» (хәзерге заман сыйфат фигыль) дип укый идем. Аннан соң таптым: асылда «Мисгарь» (корал исеме калыбында) булып, изге мөхәддисләрдән Мисгарь бине Кәдамны фаразлап кына «м» хәрефеннән соң «ә» белән укыйлар икән. «Мөгъҗәмел-бөлдан» хакында тизрәк хәбәр язуыгызны интизар булып көтәм.

Үтенеп фәкыйрегез Хөсәен.

*1860 ел, 7 гыйнварда»*

*Русчага тәрҗемәдә:*[1]

Обладателю всяческих достоинств, щедрому учителю выражаю свое искреннее преклонение. Осмелюсь побеспокоить Вас по следующему вопросу – две недели назад я просил Вас сооб-

[1] Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: ист.-док. сб./ пер. со старотат. А.М. Ахунова, И. Ф. Гимадеева; сост. и отв. ред. Д. В. Мухетдинов. Нижний Новгород: Медина, 2008. С. 99–99

щить мне что-либо о книге «Муджам ал-булдан» Якута ал-Хамави. Сейчас вновь я повторяю эту просьбу – напишите мне о достоинствах и недостатках [этой книги]. Не могли бы Вы уточнить – если есть недостатки, то конкретно в каких местах, какие слова? В эти дни удалось просмотреть каталог библиотек Османскoто государства. Его подготовили англичане. Согласно ему, Джабарти, а также «Табакат» Тамими есть во многих местах. Пока не могу сказать с точностью, возможно, что-то прояснится недели через три, но есть мысль со стороны Академии послать меня этой весной в те края. Если удастся, тогда смог бы сделать копии и для Вас.

На днях выделил время, чтобы прочесть Ваш [труд] по истории. Нашел много полезного. Однако я, ничтожный, осмелюсь высказать свое мнение. По-моему, было бы хорошо, если бы в этом труде Вы более четко рассказали бы об истории наук, то есть когда и благодаря кому [науки] получили рост, какого уровня достигли и почему пришли в упадок. Скажем, откуда возникла потребность в таких науках, как фикх, калям, логика, синтаксис и морфология, семантика, теория литературы и др. И почему начали составляться труды по этим [направлениям]? Что стало толчком к популяризации этих наук, и в какое время они пользовались наибольшим спросом? Что стало причиной упадка, кто наиболее активно трудился на ниве этих наук, и до какого уровня им удалось поднять их уровень, по сравнению с предыдущим? В то же время хотелось бы, чтобы имена и нисбы писались более точно (не подумайте, что нынешнее написание ошибочное) с использованием диакритических знаков. Например, я, ничтожный, целый час искал слово «мисар». И почему-то прочел его в форме «мусаир» (причастие действительного залога). Позже нашел – на самом деле «мисар» (имя орудия), а иначе, гадая, будут читать с фатхой имя известного хадисоведа Мисара ибн Кадама.

Ожидаю Вашего скорейшего ответа по «Муджам ал-булдан».

Презренный Хусаин. 1860 год, 7 января.

## Дүртенче хат[1]:

«Шөһрәтләрнең сыену урыны булган, гыйлем бәхетләренең төбенә төшкән мөхтәрәм һәм бөек остазыбыз!

Бохараның әмир Насрулла Бәһадир хан вафат булган, шаять, хәбәре Сезгә дә ирешкәндер. Тәфсилле тәрҗемәи хәлен белүегездә шөбһәбез юк. Форсат булганда безгә дә язсагыз, зур ярдәмегез булыр иде.

Чыңгыз нәселенең шәҗәрәләрен, туу һәм тәхеттә утыру (әгәр дә патша булган булсалар) һәм вафат тарихларын яза башлаган идем. Шәйбани, Мавәраэннәһерләрне тәмамлап киләм. Ләкин хәзергә туктап торам. Сезнең доглат әмирләреннән Бабир илә замандаш Мирза Мөхәммәд Хәйдәр Күргәннең тарихын ишеткәнегез яки күргәнегез бармы, аның асылы фарсы телендә язылып, Кашгар төркичәсенә тәрҗемәсе бар. Шуның фарсычасы табылмасмы? Мин сатып алыр идем. Монда университетта бар, ләкин гаять ялгыш. Яхшы нөсхәсе табылса – алыр идем.

Коръән бастыру мәсьәләсе ни хәлдә? Бүген Археология җәмгыятенең сәркятибе Вельяминов белән әңгәмәбез вакытында Казан һәм тирә-ягында булган борынгы истәлекләр хакында сүз чыкты. Сезнең мәчетегездә булган таш язуыннан Ильминский күчермә алып, җәмгыятькә җибәргән икән. Ләкин кирәгенчә эшләп җиткермәгән. Беренчедән, бу ташның кайдан монда төшүе хакында Казан халкы арасында булган риваятьне язмаган. Икенчедән, «бу ләүхне» сүзен «булучыны» дип, «булу» фигыленнән дип укып саташтырган. Вельяминов Сездән ул ташны яхшылап карап язуыгызны һәм дә моның хакында Казан халкында булган риваятьләрне, кабер ташының иясе кем булырга мөмкинлеген, ташның биеклеге, иңе һәм калынлыгы никадәр булып, нинди җирдән табылуын, язуларының югалган җире нинди урыннар икәнлеген һәм башка моңа бәйле нәрсәләрне тулаем бәйан кылып җибәрүегезне үтенде. Шулай да, бу таш беркадәр мәгълүм.

[1] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р.Мәрданов. Казан: Җыен, 2006. Б.354–355.

Архиерей бакчасында булган таштан фотография ысулы белән өчданә рәсем алып җибәргәннәр, ләкин укырга һич мөмкин түгел. Сез шуны укый алмассызмы? Һич югы ел һәм исемнәр тулысынча укылмасмы? Хәзер кыш вакыты булганлыктан, моны яз көне карарсыз. Әмма мәчеттә булган ташның язуларын тиз җибәрүегез зарур.

Болгарга кагылышлы хәбәрләрне игътибарга лаеклы һәм әһәмиятсезләрен дә җыеп, халык телендә булган хәбәрләр вә инануларны, дөрес вә ялгышларны тәфсилләп һәм бөтен ихтималларны язсагыз һәм үз карашыгызча дөрес булганнарын дәлилләре белән бәйан итеп, башкаларын дәлилләр белән кире каксагыз, зур эш кылган булыр идегез. Казан тирәсендә «Тәкә тавы», «Елан тавы» исемле урыннар бар. Халык фикеренчә, боларның аталу сәбәпләрен, булса кайбер истәлекләрен дә язу – Археология җәмгыятенә хезмәт хисапланыр. Русиялеләр Казанны алганда, мөселманнарның галимнәре юк идеме? Китап һәм гыйльми әсәрләре һич калдымы? Ханнарның китапханәләре булмадымы?

*1860 ел»*

*Русчага тәрҗемәдә*[1]*:*

Олицетворяющему собой обитель славы и почести, постигшему радость глубины наук, уважаемому и великому наставнику!

Слышали, наверное, что скончался бухарский эмир Насрулла Бахадир-хан? Не сомневаюсь, что Вы хорошо знаете его биографию. При возможности напишите и нам, было бы очень полезно.

Начал писать историю династии чингизидов: указываю даты их рождения и смерти, а также даты восшествия на трон (если кто-то из них стал правителем). Заканчиваю шейбанидов, а также [правителей] Мавераннахра. Но пока остановился. Не

[1] Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: ист.-док. сб. / пер. со старотат. А. М. Ахунов, И. Ф. Гимадеева; сост. и отв. ред. Д. В. Мухетдинов. Нижний Новгород: Медина, 2008. С. 100–101.

приходилось ли Вам слышать или видеть «Историю» Мирзы-Мухаммада Хайдара Кургана? Он современник Бабура, из эмиров доглатов (магулов?). Оригинал написан по-персидски, есть перевод на тюркский язык Кашгара (впрочем, этот перевод Вы видели). Нельзя ли найти персидский вариант? Я готов купить его. В здешнем университете он есть, но очень ошибочный. Если найдется хороший список, то приобрел бы его.

Как продвигается вопрос с печатанием Корана? Сегодня во время беседы секретарем Археологическкото общества Вельяминовым шла речь о древних памятниках Казани и Заказанья. Оказывается, Ильминский снял копию с надмогильного камня из Вашей мечети и прислал ее в Общество. Но не довел дело до конца. Во-первых, ничего не сказал, откуда появился этот камень и что за легенда ходит среди казанских жителей на этот счет. И потом все перепутал, неправильно прочтя слово «бу ләүхне» как «булучыны», то есть вывел из глагола «булу». Вельяминов хотел попросить Вас получше изучить этот камень и уточнить: что за легенда ходит среди казанцев на этот счет, кому был поставлен этот памятник или кому мог быть поставлен, его высота, ширина и толщина, где был найден, в каких местах стерта надпись и другие, связанные с этим вопросы. Впрочем, этот камень еще как никак изучен.

Также прислали три фотографических рисунка могильного камня, которые хранятся на Архиерейской даче, но разобрать, что там написано, невозможно. Вы не смогли бы прочесть эти надписи? Может удастся выяснить год или какое-либо имя? Поскольку сейчас зима, это дело придется отложить до весны. Но, что касается камня из мечети, необходимо ответить как можно быстрее.

Было бы большим делом, если бы Вам удалось собрать сведения по Булгару. Пусть они будут ценными или не очень. А также было бы интересным, если бы Вы изучили различные сведения и верования на счет этого, которые распространены среди народа. Пояснили бы какие из них правильные или ошибочные, какие заслуживают внимания, при этом подтверждая или опровергая их убедительными доводами. Возле Казани

есть места под названием «Тәкә тавы», «Елан тавы». Если бы удалось узнать, что думает народ по поводу этимологии этих названий, укрепить их дополнительными сведениями, то это засчиталось бы за большую службу Археологическому обществу. Когда русские брали Казань, не было ли в то время мусульманских ученых? Неужели не осталось книг и научных трудов? Не было ли у ханов своих библиотек?

*1277(1860) год*

**Бишенче хат[1]:**

«Бердәнбер, галимнәр галиме һәм балкып торучы зирәк акыллы остаз галиҗәнаплары!

Ибне Хәлдунның гарәп телендәге «Мөкаддимә»се минем кулымда. Ходай теләсә, бу язда да хезмәтләрегез белән танышу бәхетенә ирешү өметем бар. Шул вакытта алып барырмын. Милек итеп булмаса да, вакытлыча сездә калдырырмын, чөнки бик ләззәт белән укыйм. Бик яхшы җирләре бар. Дөрес, кайбер фәннәрдә зәгыйфьлеге юк түгел. Ләкин күпчелек өлешендә шикләнмичә үзләштергән, мәзһәб һәм һөнәрдә фанатик түгел. Рухлар һәм сафлар галәмен сөйләп, моның белән вилайәт пәйгамбәрлеге һәм изгеләрчә карашы һәм дә соңгыларның барлыкка килүенең күп нәрсәләрен ачмакчы була. Бу сезгә ничек? Мәгъкульме? Мәгъкульме, түгелме, әмма «тасвир, танылган мәгънәләргә проблема, билгесез, хосусан, рухлар галәмендә һәм соңгыларының яратылышында булган нәрсәләрдән кимрәк», – ди. Бу сүз мәгъкуль кебек. «Суфичылык тарафдарларының рухлар галәмен өйрәнүләре бар вә анда ачык булган нәрсәләрдән гыйбарәләр кыскалыгыннан төрлечә сөйләргә тырышып аңлаешсыз һәм көлке хәлләр була», – ди. Мондый сүзләре күп, ул җәһәттә безгә мәгъкуль күрелә. Ахыргы ике томы, ягъни асыл тарихы бездә юк. Мөселман илләрендә дә сирәк булса кирәк.

Мөфтилек вазифасы турында яңа хәбәр юк. Хаҗи әфәнде дә шул арада ул эшне тәмам кылмакчы иде, ләкин бер-ике атнадан бирле бераз кәефсез булып тора. Чыгып йөргәне юк. Безгә бик

[1] Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / төз.-авт. Р. Мәрданов. Казан: Җыен, 2006. Б. 357–358 .

дуслык кыла, ничә мәртәбәләр, чакырмыйча, өебезгә килгәне бар. Үз өенә еш-еш чакыра һәм төрле фаразлар кылабыз. Безнең фикеребезчә, ул кеше инсафсыз адәм түгел. Үз карашынча лаек лы күрелгән ике-өч ахунның берсе булса, шул юлда тырышмакчы. Аларның (мөфти) булу ихтималы булмаганда үзе ихтыяр итмәкче. Аның уена күрә, дәүләт җитәкчеләренең аңа ышанычы артыграк вә сүзе дә үтемле булыр һәм бу ысул белән мөселманнарның кайбер хәлләрен ислах кылырга мөмкин булыр иде. Гәрчә ачыктан-ачык әйтүе шулай булмаса да, сүзләреннән шул мәгънә аңлашыла.

Аның белән кылган фаразларыбызның берсе бу: бөтен хаҗәтләре һәм зарур нәрсәләре яхшылап җитештерелеп, Казанда олуг бер мәдрәсә ачылыр. Казна хисабыннан буларак, 60–70 шәкерт тәрбияләнер һәм, алардан тыш, дәрес тыңлаучылар кабул ителер. Гимназиядә укыла торган барлык фәннәр укылу өстенә шәригать һәм гарәп теле гыйлемнәре укытылыр. Европа телләре, география һәм медицина, табигать фәннәре рус телендә, аннан башкалары төрки-татар телендә укытылыр. Монда ике йөздән алты йөзгә кадәр хезмәт хакы алучы ике-өч дәрәҗә мөдәррисләр булыр. Мәдрәсәдә ун сыйныф булып, әүвәлге өч сыйныфта барлык шәкертләр төрки, фарсы, гарәп, рус телләрен һәм моннан тыш география, геометрия, Коръәнне дөрес уку өйрәтелеп, аннан соң сыйныфлар икегә аерылып, бер шөгъбәсе мөселман укымышлылары юлы булып, тәфсир белән хәдис, риторика, семантика вә стилистика укырлар һәм дә элекке мөселманнар ысулынча табигать фәннәре, математика һәм ким дигәндә фельдшерлык дәрәҗәсендә латинча вә тыйбб укырлар. Чөнки медицина гыйлемен белүче муллалар үз мәхәлләләренә күп хезмәтләр күрсәтергә мөмкин булыр, үзләре дә файдаланырлар. Бу дәрәҗәдә булган муллалар имана түләүдән һәм солдат хезмәтеннән азат ителерләр. Икенче шөгъбәдә исә тулысынча гимназия ысулынча укытырлар. Аннан чыккан шәкертләрнең турыдан-туры университетка керергә хаклары булыр. Күңелләре ислам белән нурланган, мөселман тәрбиясе белән иманнарын дөресләгән бу шәкертләр, университеттан чыкканнан соң, ислам диненә бик күп хезмәтләр күрсәтә

алырлар. Голәмә шөгъбәсендә укыган шәкертләр мәхәллә приговорыннан һәм Диния нәзарәте имтиханыннан башка да мулла булырга хаклары булыр. Бу мәдрәсәнең еллык 25000 сум кадәр чыгымнары булса кирәк. Аның чарасы болай булыр: мәдрәсә тарафыннан дәүләт сәясәте һәм дәүләт эшләренә бәйле бер журнал чыгарылыр. Шулай ук фикъһ һәм тәфсирдән могтәбәр китаплар басылып, журнал белән һәр номерында бер-ике кисәк таралыр. Журнал бәһасе дүрт тәңкә кадәр булып, һәр мәхәлләгә бер нөсхә алырга мәҗбүр ителер. Оренбург Диния нәзарәтендә 5000 кадәр мәхәллә булса, моннан 20000 тәңкә хасыйль булыр. Бастыру чыгымнарыннан аздан моның яртысы – 10000 сум калыр. Хәзергә һәр никахтан 9 тиен ала иделәр, моннан соң 25 тиен алыныр. Аннан җиде-сигез мең тәңкә хасил булса кирәк. Аннан соң «Коръән», «Сөбател-гаҗизин» китапларын бастыруга бу мәдрәсәнең хокукы булыр. Моннан да күп акча хасил булыр. Мөселманнар үз араларында бераз иганә кылырлар һәм казнадан да беркадәр бирерләр.

[1864]».

*Русчага тәрҗемәдә*[1]*:*

Единственный ученый среди ученых, светящийся своим тонким умом милостивый учитель!

«Мукаддима» Ибн Халдуна на арабском языке у меня на руках. Если Всевышний пожелает, есть надежда, что этой весной буду иметь счастье познакомиться с Вашими трудами. В то время и захвачу с собой. Не смогу подарить Вам, но оставлю хотя бы на время. Сам читаю с большим удовольствием. Есть хорошие и интересные места. Впрочем, чувствуется его слабость в некоторых науках. Во многих местах имеются и совершенно необоснованные доводы, впрочем, по своим взглядам и действиям [явно] не фанатик. Желая выглядеть абстрактным и говоря о духовном мире и с помощью понятий пророчество, святость, благое откровение, последнее

[1] Хусаин Фаизханов. Жизнь и наследие: ист.-док. сб. / пер. со старотат. А. М. Ахунов, И. Ф. Гимадеева; сост. и отв. ред. Д. В. Мухетдинов. Нижний Новгород: Медина, 2008. С. 104–105.

возникновение пытается постичь [суть] многих вещей. Как это Вам? Разумно? Разумно или не разумно, но, тем не менее, он пишет: «Такие понятия, как духовный мир или последнее возникновение имеют преимущества по отношению к понятиям известным, признанными». Эти слова вроде разумны. Также он пишет: «Сторонники суфизма также изучали духовный мир, но тем из-за недостатка и узости используемых ими понятий они так и не смогли объяснить явные вещи, все запутали и сделали смешным». Таких слов много и в этом отношении его слова звучат разумно. Последних два тома, то есть самой «Истории», у нас нет. Да и в мусульманских странах нечасто встречаются.

Насчет поста муфтия новостей нет. Хаджи-эфенди[1] сам хотел снять эту проблему в самые ближайшие дни, но в последние две недели ходит без настроения. В свет не выходит. Впрочем, к нам относится по-дружески – сколько раз посещал наш дом и даже без предупреждения. Да и к себе часто приглашает, где мы беседуем, что-то планируем, предполагаем. По нашему мнению, этот человек вполне беспристрастный и справедливый. Сам он раздумывает над наиболее приемлемой кандидатурой из 2–3 ахунов. Если не получится, то готов попробовать и сам. Как он полагает, высшие власти больше доверяют именно ему, да и вправду его слова более полновесны, благодаря этому, возможно, получится реформировать кое-какие наши мусульманские дела. Хотя он и не говорит об этом в открытую, но из его слов можно понять, что он думает об этом.

Вот кое-что из наших планов: самым тщательным образом подготовив все необходимое, открыть в Казани большое медресе. За счет казны будут обучаться 60–70 шакирдов – остальные в качестве вольнослушателей. Помимо тех предметов, которые преподаются в обычных гимназиях, ввести уроки шариата и арабского языка. Европейские языки, география, медицина и естествознание будут преподаваться на русском языке, остальные – на тюрко-татарском. Будут приглашены преподаватели двух степеней с окладом от 200 до 600 [рублей]. Медресе будет 10-классным. В первые три года все

[1] Имеется в виду Салимгарей Тефкилев.

вместе будут изучать тюркский, персидский, арабский, русский языки, а также географию и геометрию. После того как они как следует изучат Коран, они разделятся на две группы. Первая группа – мусульманская. Их будут обучать тафсиру и хадису, риторике, семантике и стилистике, а также в традиционных мусульманских формах – естествознанию, математике и как минимум фельдшерскому ремеслу, латинскому и основам медицины. Несомненно, что знающие медицину муллы могут оказаться очень нужными в своей махалле, да и самим будет польза. Такого рода мулл будут освобождать от налогов и солдатщины. Во второй группе шакирды будут полностью готовиться по гимназической программе. Таким выпускникам будет дана возможность сразу, напрямую поступать в университеты. Эти шакирды, получившие мусульманское образование, с душами, освященными верой, после окончания университетов смогут оказать большую пользу исламской религии. Те же, кто закончит отделение улемов, смогут занимать место муллы помимо приходского приговора и экзамена в Духовном управлении. Годовые расходы этого медресе могут дойти в год до 25 000 рублей. Как можно решить эту проблему? Медресе будет выпускать отражающий государственную политику журнал. При нем в качестве приложения к журналу можно будет выпускать книги по фикху и тафсиру. Стоимость подписки поставить в 4 рубля и обязать каждую махаллю выписывать по одному экземпляру журнала. Если в Оренбургское духовное управление входит до 5000 махалля, доход выйдет в 20 000 рублей. 10 000 рублей уйдет на типографские расходы, то есть как минимум половина. Сейчас с каждого никаха берется 9 копеек, далее можно брать и 25 копеек. Это в свою очередь принесет 7–8 тысяч рублей. Потом за медресе будет закреплено исключительное право печатать Коран, а также книги типа «Субат ал-аджизин». Это еще прибавит дохода. Да и о меценатах не надо забывать – немного помогут. Кое-что дадут из казны.

[1864]»

# IV бүлек
# Мәрҗани турында шигъри сүз

*Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,*
*Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.*

*Г. Тукай*

*Энциклопедист галим, бөек акыл иясе Шиһабетдин Мәрҗани шәхесе, аның олуг эшчәнлеге хакында мәкаләләр язылып, милләтебезнең горурлыгы булган мәшһүр затка багыш-лап каләм әһелләре аның вафаты сәбәпле мәрсияләр дә иҗат итә, хатирәләр яңартыла. Билгеле булганча, Ш. Мәрҗа-нинең тормыш юлына, иҗатына багышланган, аның тууына һиҗри ел исәбе белән йөз ел тулуга махсус рәвештә 1915 елда «Мәрҗани» исемле мәҗмуга әзерләнә. Әлеге кыйммәтле җыен-тык – аны төзүгә кереш, язылу барышы, әһәмияте хакында матбугатта игъланнар урнаштырыла килә, мәкаләләрдә халыкның бу китапны түземсезлек белән көтүе яктыртыла бара. Китапта җәмәгать һәм дин эшлеклесе, җыентыкның редколлегия әгъзасы да булган Шәһәр Шәрәфнең (1879–1938) Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле хакында тулы, әтрафлы, эзлекле һәм күләмле мәкаләсе урын ала. Мәкалә соңында Ш. Шәрәф «Мәрҗани хәзрәтләре хакында мәдхия вә мәрсия була-рак шигырь язучыларның безгә мәгълүм булганнары ошбулар-дыр: Акмулла, Акай Дагыстани, Исмәгыйль мәхдүм бине мелла Хәбибулла әл-Казани, мелла Җәмаледдин әт-Тинчәли, Рамазан Дагыстани, Шәйхелиислам әт-Тәкәви, Сабирҗан бине мелла Габделбәдигъ әл-Мәмсәви, Салихҗан әл-Баруди, Сибгатулла бине Мөхәммәд әл-Күгәрчени, Зыяэддин әт-Тархани, Галимҗан әл-Баруди, Габделхәким бине Габдулла әл-Бәлбаи, Габделкаюм бине Морад әл-Бәдәхши, Габделләтыйф Дагыстани, Габдулла*

*Тукай, Гобәйдулла әл-Карлыви, Гали бине Салих әл-Чокрый, Фәхреддин бине Арслан әл-Бүкәли, Мөхәммәдшафигъ бине Мөхәммәдшәриф әл-Үтәки, Мөхәммәд бине Ихсан әл-Мәмсәви, Мостафа бине Дауд әл-Чутайи, Нәҗиб Думави, Нурулла бине Габделвәли әл-Карлыви, мелла Вәли Чүпрәли, Йосыф Дагыстани» дип, шигырь язучыларның исемнәрен атап, алар язган нәзым һәм шигырьләр йөз илле бит күләмендә җыелганын күрсәтә, ләкин җыентыкта «бик күп урынны алачагыннан, бу урында исемнәрен генә телгә алу илә канәгатьләндек» диелә. Кызганычка каршы, бүгенге көнгә исемлектәге бик аз кешеләрнең генә мәрсияләре билгеле. Алар арасында иң беренче булып торган Акмулла (1831–1895) – Мәрҗанинең замандашы, билгеле булганча, галим шәхесен, аның эшчәнлеген олылап мәдхия яза, шагыйрь аны тәмамлагач, Мәрҗанинең үз кулына тапшырырга уйлый, ләкин өлгерми кала, аннан инде мәрсия бүлеге язылып, «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе» 1892 елда аерым китап булып басылып чыга. Н. Думавиның «Шиһабеддин Мәрҗани хәзрәтләренең кабере янында», Г. Тукайның «Шиһаб хәзрәт» исемле шигырьләре дә шәрәфле галимгә тирән ихтирам белән язылганнар. Шулай ук Ш. Мәрҗанинең йөзьеллыгы уңаеннан да аны хөрмәтләп язылган матур шигырь үрнәкләре дөнья күрә. Түбәндә шуларның берничәсе тәкъдим ителә.*

## Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе

Казанда бер фазыйль[1] чыкды алмас булып,
Хасидләре[2] күбәйде гам-хас булып[3],
Мәгани җәваһирен[4] кулга элгән,
Хәкаикъ[5] диңгезендә гаувас[6] булып,

Мәйданда ул чыкарды артык гайрәт,
Мизмарда сабикълардан чыкды гъәсрәт[7];
Хәмде лиллаһ, бу диярда[8] бездән чыкды
Мәрҗани Шиһабеддин ахунд хәзрәт!

Караңгыда фанусны[9] кабызган ул,
Кайнар сөткә сары майны тамызган ул;
Янбугыссәләмәтдән[10] юллар ачып,
Әнһарелхәкаикъны[11] агызган ул.

Сүз кузгар ул ир асыл – кирәк йирдән,
Ходаем фирасәтле[12] йөрәк биргән;
Мөһәндисләр[13] сизмәгән йирдән казып,
Чыкарды татлы суны тирән йирдән.

---

[1] Фазыйль – өстен, олы (зур галимнәргә карата кулланыла торган эпитет).
[2] Хасид – көнче, көнләшүче.
[3] Гам-хас булу – түбән һәм югары катлам (кешеләре) берләшү.
[4] Мәгани җәваһирен – фикер, идея җәүһәрләрен.
[5] Хәкаикъ – хакыйкатьләр, чынлыклар.
[6] Гаувас – суга чумучы.
[7] Мизмарда сабикълардан чыкды гъәсрәт – бәйге мәйданында элгәргеләрдән ялгышлар чыкты.
[8] Дияр – мәмләкәт, ил; җир, өлкә.
[9] Фанус – фонарь, маяк.
[10] Янбугыссәләмәт – сәламәтлек чишмәсе.
[11] Әнһарелхәкаикъ – хакыйкать елгалары.
[12] Фирасәтле – сизгер, кыю.
[13] Мөһәндис – инженер.

Болагы саф[1], чәйгә һәркем су алгандай,
Хаклыкка чүлләгәнләр куангандай;
Дөррәсендән[2] канча бала сөткә туеп,
Башкалар була калды су алгандай.

Тәхкыйкләрен[3] күргән адәм куангандай,
Голямага сәрдар[4] булып ту[5] алгандай;
Мөбариз майданына бу чыккан соң[6],
Батырлар була калды җугалгандай.

Аңнаусыз һичкем аңа тотынмасын,
Анау-монау кеше имәс чобалгандай.
Палуанлардан[7] йыгълып бу күргән юк,
Бәйгене берәү алса – бу алгандай!

Мөселманга каршуга лаикъ имәс,
Инсафлы урыс күрсә инангандай,
Ул бер фазыйль галляма[8] – узган тапдан[9],
Хаззы[10] бар дәрәҗәи иҗтиһаддан;

Әгъдасенә[11] җан аямый каршы торып,
Аның өчен мөҗаһидмез[12] алгы сафдан.
Дәкаикътә[13] мөшкил чишеп калдырган ул,
Биш йөз елгы батырларны талдырган ул,

[1] Болагы саф – чишмәсе саф.
[2] Дөррәсендән – энҗе бөртегеннән.
[3] Тәхкыйкләр – хакыйкать ачыклаучылар.
[4] Голямага сәрдар – галимнәргә баш, җитәкче.
[5] Ту – байрак.
[6] Мөбариз майданына бу чыккан соң – көрәшчеләр мәйданында бу (Мәрҗани) чыкканнан соң.
[7] Палуан – пәһлеван (батыр).
[8] Галляма – галим.
[9] Тап - гади халык (гавам).
[10] Хазз – өлеш.
[11] Әгъда – дошманнар.
[12] Мөҗаһид – тырышучы.
[13] Дәкаикъ – нечкә фикер, тирән уй.

Мисленә әһле гасыр гъәдил тапмай[1],
Йөрәген мөганиднең[2] яндырган ул.
Һәр йирдә сәнәд[3] илә сүзе баһир[4],
Халенә къале[5] шаһид көндәй заһир;

Бу заманда туган юк аңа нәзыйр[6]
Мәгърифәтерриҗальдә[7] мондый маһир.
Үтә алмайлар эзендән басып аның,
Китә алмыйлар юлындан ашып аның;

Хакъ нурын сиздерә алмай мөганидләр,
Күрә алмайлар галәмгә фашын аның[8]!
Аһ, дәрига[9]! Баралмадым кашына аның,
Сүзенә артыкча мин гашыйк аның;
Һәр тарафка сөйүлед–дәкаикъдан[10]
Агызган йиме гыйрфан[11] ташып аның.

***

Бер китаб бар, иясе кайсыңыз ул?
Китабында исме юк, шәхсе мәҗһүл[12],
«Тәварихел-Болгар» дип исем биргән,
Эчендә сәвабендан[13] хатасы мул.

---

[1] Гъәдил тапмау – тиң тапмау.
[2] Мөганид – киребеткән, карышучы.
[3] Сәнәд – дәлил, документ.
[4] Баһир – ачык,. анык.
[5] Къаль – әйткән сүз.
[6] Нәзыйр – охшаш, тиңдәш.
[7] Мәгърифәтерриҗальдә – мәгърифәтле ирләр арасында.
[8] Галәмгә фашын аның – аның дөньяга мәшһүр булуын.
[9] Дәрига – ни үтенеч.
[10] Сөйүлед–дәкаикъдан – дәкаикъ силләре, ягъни нечкә фикер ташкыннарыннан.
[11] Йиме гыйрфан – гыйрфан җиме (белем җимеше).
[12] Мәҗһүл – билгесез, беленми.
[13] Сәваб – дөрес.

«Назурә»гә бер мөганид[1] батыр икән,
Тиз керсә ярар иде оҗмахка шул!
Үз тарафын күтәргән күккә чаклы,
Муллалары булган соң үзенә кол.

Бөрадәр[2], сезгә үтенәм сәлам язып,
Күзең сал: Мәрҗани – ул Тимерказык!
Булмаса, кыйбла тапмай адашырсың,
Караңгыда җүн белмәй юлдан язып!

Имгәнеп, коры, бикяр[3] азапланма,
Бакыр чыкмас урында алтын казып!
Төлкедәй йөгрекмен дип ашсаңыз да,
Сыйракдан ала торган мин бер таз эт[4].

Бу сәбәбдин сезләргә сәлам язам,
Бу якка килеп ятыр сезнең азан;
Ир булган ирәнләрне хур тотмаңыз –
Гатасына[5] шарт имәс Кышкар, Казан.

Әдәбсезлек имәсме бу кылганың:
Ишәккә тиңәрәсез ир толпарын!
Мөхакәмә кылмас[6] дип уйладыңмы,
Сукыр дип белепмидең йортның барын?!

Сезләргә таң каламын уйлай-уйлай, –
Калайынча[7] сезнең як зиһен куймай?
Болытдай, көннең нурын пәрдәләгән
Сезләргә шул сәбәбдин күңел тулмай!

---

[1] Мөганид – дошманлык күрсәтүче, карышучы.
[2] Бөрадәр – туган, кардәш.
[3] Бикяр – бушка, тиккә.
[4] Таз эт – *бу урында:* йөгерек ау эте.
[5] Гата – бүләк, әҗер.
[6] Мөхакәмә кылу – хөкем чыгару, фикер йөртү.
[7] Калайынча – ничек итеп.

Хәленчә голямага мәдех[1] лаикъ,
Вәләкин һәр кош очып лачын булмай.
Мондан башка әйтер сүзем тулып ятыр,
Тәгъйинләп һәрбер сүзне әйтеп булмай.

Эшеңез мөзәйяндер вәһмеңездә,
Сүзеңез мөбәйяндер зәгъмеңездә[2],
Мең мулла рәдд кылсаңыз[3] – ни кайгы бар? –
Дустлар да бар кагарлык рәгъмеңезгә[4]!

Җик күргәч, бер яланы ябарсыз сез,
Кик кылгач[5], бер караны ягарсыз сез;
Арткы як ачылганның ачуындан,
Әлбәттә, бер яман ат тагарсыз сез;

«Бәркыльвәмиз[6]» чигәңезгә чирткәндән соң,
Чаяндай, чыдай алмай чагарсыз сез.
Ул фазыйль Газалидәй булсадагы,
Рәдденә тәһафөтләр язарсыз сез[7].

Хәкаикыль–голүмдән әгъраз кылып,
Киберсеп, ул ягына нәзарсыз сез[8].

---

[1] Голямага мәдех – галимнәргә мактау.

[2] Күрсәтелгән ике юлның хәзерге татар теленә тәрҗемәсе:
Эшегез бик күркәмдер үз уегызда,
Сүзегез бик ачыктыр үз фаразыгызда.

[3] Рәдд кылу – кире кагу.

[4] Рәгъмеңезгә – каршылык итүегезгә (рәгъм – карышу, кире кагу).

[5] Кик кылу – үч тоту, ачу саклау.

[6] Бәркыльвәмиз – яшьнәгән яшен, яшен уты.

[7] Рәдденә тәһафөтләр язарсыз сез – кире кагу өчен, үзара юкка чыгарулар язарсыз сез.

[8] Хәкаикыль–голүмдән әгъраз кылып,
Киберсеп, ул ягына нәзарсыз сез –
Чын гыйлемнәрдән аңлатмалар биргән булып,
Һаваланып, әлеге ягына игътибар итмисез.

Үзеңездән бер фазыйль була калса,
Иттифакы җәмилгә[1] – начарсыз сез;

Хәсәд бәгъзы гадаүәткә мөбдаэ булып[2],
«Фә-исляху[3]!» әмерендә качарсыз сез.
Арслан берлә алышып арыклаган,
Хәсәд берлә саргайган аҗарсыз[4] сез.

Әлбәттә, инде мине сөймәссез сез,
Бер бичара хакъгүй[5] икән димәссез сез.
Карендәш, бер инсафка килсәңез ни? –
Фиргавеннең варисы имәссез сез!

Бөрадәр, минлекне куй галялхосус[6],
Мин-минлек иясенә китерер носс[7],
Мәрҗанигә алышырга кем чыдасын? –
Куәсенә даләләт кылса носус[8]!

Фазыйльне фазыйль белсәң, эчең көймәс,
Һәрчак тәвазыйгда бармы нәкыс[9]?
Батыр менән көрәшсәң, сау калмассың,
Аяймын, бил-умырткаң өзелсә, дус.

Ул сезгә җәүһәр җыеп нәсар кылды[10],
Инде син кадерен белеп итәгең тус[11];

---

[1] Иттифакы җәмил – күркәм бердәмлек.

[2] Хәсәд бәгъзы гадаүәткә мөбдаэ булып – көнчелек кайбер дошманлыкка чыганак булып.

[3] Фә-исляху! – төзәлегез!

[4] Аҗарсыз – нурсыз, чырайсыз.

[5] Хакъгүй – туры сүзле, дөрес сөйләүче.

[6] Галялхосус – бигрәк тә, аеруча.

[7] Китерер носс – төгәлсезлек китерер.

[8] Куәсенә даләләт кылса носус – үз куәтенә язмаларны дәлил кылса.

[9] Тәвазыйгда бармы нәкыс – тыйнаклыкта (әдәплелектә) кимчелек бармы.

[10] Нәсар кылу — өскә сибү.

[11] Итәк тусу – итәкне тоту.

Ала алмай ул җәүһәрдән коры калсаң,
Бәхетеңне шомыңдан, бел, артыңны кыс!

Кил, зинһар, бөрадәрем, инсафка кил,
Куәтең канча икән – чамаңны бел!
Халь килсә, аның эшен сез дә эшләңез.
Булмаса – файда бирмәс такылтак тел.

Белгәнгә нигә эчең көя синең? –
Эшен күр моталәга иясенең[1]!
Һәр фәннең бер сайлаган риҗале бар, –
«Иясе серен белер биясенең».

Керләсәң һәр нәрсәне – карайтырсың,
Хасидсез[2] андай фазыйль калай[3] торсын?
Истанбул, Мисыр, Шамда нәзыйре юк, –
Кышкар, Казан, Дагстан болай торсын!

Бу чакда һичкемне аңа тиңәрмәйде.
Батырлары мәйданга чыгып күрсен,
Булмаса, «ул белмәй»не кем белмәйде?!
Үлчәде истыйрлябен мөһәндисләр,
Тәхкыйкын тәхсин күреп мөбарисләр[4],
Һәр йирдә табгы сәлим[5] әфазыйльдән[6],
Хосусән Труйски мөдәррисләр.

---

[1] Моталәга иясе – укытучы, өйрәтүче.
[2] Хасид – көнче, көнләшүче.
[3] Калай – ничек.
[4] Үлчәде истыйрлябен мөһәндисләр,
Тәхкыйкын тәхсин күреп мөбарисләр –
Инженерлар астролябияләрен үлчәделәр,
Үз фикерендә торучылар тикшерүен яхшы күрде.
[5] Табгы сәлим – саф табигать, сәламәт табигать.
[6] Әфазыйль – өстенрәк, иң өстен галимнәр.

Хосусән хаҗи хәзрәт кылды тәсдикъ,
Ушандак ишан хәзрәт галяттәхкыйк[1] –
Фокарага[2] кыйбә-и хаҗәт булган,
«Хәвалиһе мин көлли фәҗҗе гъәмикъ»[3].

Болар да сез белгәнне белгәндәйләр,
Китабны сез чамалы күргәндәйләр;
Шаһбаздай[4] ялтыраган бер шоңкарлар,
Тойгынның[5] аягындан элгәндәйләр.

Моталиб галиядә хәккан мәркат,
Мәкасыйд талиядә хакка миръат[6],
«Игътибар»да игътибарга алган икән
Хөрмәтле Ризаэтдин – бер кямил зат.

Җөмлә дилсаф[7] әһле инсаф алды гыйбрәт,
Казанга бу сәбәбдин килде фәхрәт,
Рөтбәсенә мөтталигъ мөхлис икән[8]
Дамелла Борһанетдин казый хәзрәт.

Әлхасыйль, күп әфазыйль салды колак,
Барып табып әйтүгә телем чулак;
Мәмсәви дамелланың мәдхе калай?
Ләззәтле гыйбарәте – егет сымак.

[1] Галяттәхкыйк – чынлыкта, дөреслектә.
[2] Фокара – фәкыйрьләр, гади халык.
[3] Фокарага кыйбә-и хаҗәт булган,
«Хәвалиһе мин көлли фәҗҗе гъәмикъ» –
Фәкыйрьләргә сыену урыны булган
Йорт-җире аның барлык тарлавыклардан тирән.
[4] Шаһбаз – лачын, шоңкарларның затлысы.
[5] Тойгын – ау кошларының бер төре.
[6] Моталиб галиядә хәккан мәркат,
Мәкасыйд талиядә хакка миръат
Бөек мәсьәләләрдән чыннан да нечкә күзәтүче,
Максатта эзлеклектә дөреслек көзгесе.
[7] Дилсаф – саф күңел.
[8] Рөтбәсенә мөтталигъ мөхлис икән – дәрәҗәсен аңлаган ихлас (күңел) икән.

Гайре чит вилайәтдән ничә ирләр,
Исламбул, Һиндстандан мөшаһирләр[1]
Китабларын кабул кылып бастыртканлар, –
Чалкаеп йөри бирсен мәкябирләр[2]!

Тәгассыбын калдырмас бозык замир[3],
Сусыныңны кандырмас корык гадир[4],
Ай торганда чулпанга гашыйк булган, –
Ни кылсын көннең нурын ул бер зарир[5]!

Ай булмаса, йолдыз берлә төн яктырмай,
Фәркъдандан мөстәгъни бәдре мөнир[6],
Замирем мөзәккәр[7] дип мактанмасын,
Кояшка хурлык бирмәс тәэнис замир[8].

Ничә мин-мин дигәннәр йокысын ачкан,
Гафләтдән тәнбиһ кылган бу бер назир,
Җиһанда хале гайан, къале бәйан[9],
Әфазыйльдән мөсәлләм җами гафир[10];

«Җәлал»га хашиясе аңа шаһид,
Нә кадәр мәдех кылсак, шунчә җәдир[11].
Ливаъи тәхкыйкатьне хамил булган[12]
Мөбариз арасында бу – бер әмир!

[1] Мөшаһирләр – шөһрәт иясләре.
[2] Мәкябирләр – үзләрен эре тотучылар, тәкәбберләр.
[3] Замир – вөждан, йөрәк, күңел.
[4] Корык гадир – коры (корыган) чишмә, кипкән күлчек.
[5] Зарир – сукыр.
[6] Фәркъдандан мөстәгъни бәдре мөнир – нур сибүче тулган ай фәркъдан йолдызларына мохтаҗ түгел.
[7] Замирем мөзәккәр – йөрәгем ир җенесле.
[8] Тәэнис замир – хатын-кыз җенесенә әверелгән йөрәк.
[9] Хале гайан, къале бәйан – хәле ачык, сүзе аңлатылган.
[10] Әфазыйльдән мөсәлләм җами гафир – бик күпсанлы танылган галимнәрдән.
[11] Җәдир – лаек.
[12] Ливаъи тәхкыйкатьне хамил булган – хакыйкать байрагын күтәргән.

Җәридәи замандан җәмал ачып[1],
Күргәзде йәде бәйза бу ир.
Кайсысындан күренде мондый бәйан?
«Өййәһум йүнәббиъүкә мисле хәбир?»[2]

«Хикмәте балигасе» кандай икән?
Зәукы сәлим[3] иясенә балдай икән;
Осуле хәкаикъны хамил булган[4]
Адәмнең тәнендәге җандай икән.

Хәдисдә мәһарәтен нәзар кылсаң,
Әсхабдән ишеткәндәй аңлай икән[5].
Мондый гали галимгә тел озайткан –
Ул үзе дүрт аяклы малдай икән!

***

Казакъча шигырь яздым ачык кылып,
Хасидләрнең йөрәген ачындырып.
Тәхкыйкләрен күргән соң куангандан,
Китабларын карыймын да гашыйк булып.

Тәсныйфлары басыйрәтне ярук кылган[6],
Нәфис, хәсис арасын фәрекъ кылган[7];
Адашканда киз килеп[8] балга төшкән –
Мин байгыш бер кырмыска гарык булган.

---

[1] Җәридәи замандан җәмал ачып – замана газетасының (басма сүзнең) күркәмлеген ачып.

[2] «Өййәһум йүнәббиъүкә мисле хәбир?» – Алар сиңа белгән булып хәбәр иттеләрме?

[3] Зәукы сәлим – сәламәт зәвык.

[4] Осуле хәкаикъны хамил булган – хакыйкать нигезләрен күтәрүче булган.

[5] Хәдисдә мәһарәтен нәзар кылсаң,
Әсхабдән ишеткәндәй аңлай икән – Хәдистә осталыгына карап карасаң, Сәхабәләрнең үзләреннән ишеткәндәй аңлый икән.

[6] Тәсныйфлары басыйрәтне ярук кылган – язганнары күңелләрне (аңны) яктырткан.

[7] Фәрекъ кылу – аеру.

[8] Киз килү – туры килү, очрау.

Унбиш ел «Назурә»сен алганыма,
Карай-карай баш очыма салганыма;
Шифаи садр андан хасил итдек[1],
Эленмәй хасидләрнең кармагына.

Морадлары мөкябәрә[2] булгандан соң
Хасидлар күз салмайлар аръягына;
Гавамлары, мулласына табигъ булып[3],
Дөрләтеп ярыа йөри ярмагына[4].

Нигә мончә безләрдә әдәб кыска.
Кәмаләт болай торсын – гакыл вуста[5].
Бер йиргә килештереп хат язалмай,
Берәүне яманларга кандай оста!

Бәгъзысе укый да алмай гыйбарәтен,
Кямилгә кандай кыла хәкарәтен?
Дамеллалар бәгъзысе, белә торып,
Хасмының морад кыла хәсарәтен[6].

Әдвия хамил булмас бәгъзы мәрыйз,
Нәсыйхәт кабил булмас фәззы гализь[7].
Шәятыйнның әбһәрен[8] өзеп киткән –
Атылып түбәсендән «Бәркыльвәмиз».

---

[1] Шифаи садр андан хасил итдек – йөрәккә дәва аннан хасил иттек.

[2] Мөкябәрә – эрелек, һавалылык, мин-минлек.

[3] Табигъ булу – буйсыну.

[4] Ярмак яру – *биредә:* зур эшне ваклап, «буш фикер таратып йөрү» мәгънәсендә (элекке сум металлдан вак тәңкәләр яруга ишарә).

[5] Кәмаләт болай торсын – гакыл вуста – камиллек болай торсын, акыл да уртача.

[6] Хасмының морад кыла хәсарәтен – көндәшенең зыян күрүен максат кыла.

[7] Әдвия хамил булмас бәгъзы мәрыйз,
Нәсыйхәт кабил булмас фәззы гализь –
Кайсыбер чир дәваны күтәрә алмас,
Нәсыйхәтне кабул итүче тупас, мәрхәмәтсез булмас.

[8] Әбһәр – кан тамыры.

«Җарүдә» иясенә сүземез юк,
Аларга каршы килер йөземез юк,
Рәхимуллаһи рәхмәттән васигатән[1],
Дөньяда сүземез бар – үземез юк!

Ул да бер галим икән сөйләй торган,
Голяма мәҗлесендә мәйдан алган,
Морадына мөнафины[2] сөймәй торган,
Курае килешкәндә көйләй торган.

Без дә күрдек угының аткан йирен,
Кай йиргә угы төшеп яткан йирен, –
«Фәликөлли вәҗһәтин муәҗҗиһәтин»[3],
Бәрәкалла, килештереп тапкан йирен.

Аңа шәрик дамелла Мөхибулла,
Раббани голяманы мөхиб мулла[4],
Әүвәлдә кырын-ярын йөреп иде,
Ахырында кайтып булды мөхикъ[5] мулла.

Дамелла Рәхмәтулла аңа нәзыйр,
Тәхрират иттилягъда рәүшан замир[6],
Мәрхүмнәр Мәрҗанигә гъәкс төшкән[7],
Аларга һәм мөтабигъ җәме гафир[8].

Озтазлары Кышкар хәзрәт алга чыккан,
Галялхосус кәлямдә данга чыккан,

---

[1] Рәхимуллаһи рәхмәттән васигатән – Алланың рәхмәте иксез-чиксез.
[2] Мөнафи – каршы, килешмәүче.
[3] Фәликөлли вәҗһәтин муәҗҗиһәтин – һәрбер кешегә үз йөзе бирелгән.
[4] Раббани голяманы мөхиб мулла – Алла яклы галимнәрне сөюче мулла.
[5] Мөхикъ – гадел, хаклык ягында булучы.
[6] Тәхрират иттилягъда рәүшан замир – аңлатучы әсәрләр язуда күңеле нурлы.
[7] Гъәкс төшү – каршы төшү.
[8] Аларга һәм мөтабигъ җәме гафир – аларга ияргән бик күпләр.

Бәрагатьдә[1], дамелла Мәчкәрәдәй,
Күп галимнәр, мөдәррисләр андан чыккан.

***

Курса хәзрәт алардан борын булган,
Мәдехка ул бер лаикъ урын булган,
Ул, мәрхүм, Мәрҗанидәй мәфтүн булып[2],
Күп галим ул галимгә кырын булган.

Бу зат һәм үз гасырында әгъля галим.
Хасидләрен мөбтәля табгы сәлим[3],
Артына бераз әсәр ташлап киткән,
«Камилгыйльбәдига» гүя сәйфе сарим[4].

Һәр бәндә хәзинәсен идәр изһар[5],
Вәләкин хәзинәдә тәфаүәт[6] бар;
Ни бар-югын белерсез – дөкян ачса,
Һәр кемдә бер сәүдә бар хале микъдар.

Вәләкин Мәрҗанинең эше башка,
Йылкының толпарындай йолдыз-кашка.
Алыстан шәгъшәгасе[7] балкып торган
Җәүһәрдәй кундырылган алтын ташка.

Кай эше ул фазыйльнең таң калмастай,
Кай сүзе ул кямилнең күз салмастай? –
Дәрденә дәрдемәндләр шифа тапды,
Сукырлар күзен ачты карманмастай!

---

[1] Бәрагать – башкалардан өстенлек; белемлелек, сәләтлелек.

[2] Мәфтүн булу – үз-үзен онытып мавыгу, тәмам бирелү.

[3] Хасидләрен мөбтәля табгы сәлим – көндәшләрен сәламәт күңеллелеккә дучар иткән.

[4] Сәйфе сарим – үткен кылыч.

[5] Изһар итү – күрсәтү, ачып салу.

[6] Тәфаүәт – аерма.

[7] Шәгъшәга – нур, балкыш.

Сәрхәбадлы[1] кешеләргә бик килешенде,
Булдылар аяк-кулы сызланмастай.

Кәмале йир йөзенә мәшһүр булды,
Булдылар яманлауга алданмастай,
Әсмаэи мөстәрүдән җәмал ачып[2],
Әхбабын гашыйк кылды җан калмастай;

Шәҗәрәи дәлилнең тамыры тирән, –
Алай-болай койынга[3] кузгалмастай.
Беркеткән хөҗҗәт[4] берлән мөддәгасен[5],
Остайы сылу[6] җунып салагн таштай;

Эше пөхтә машинаның ширазындай,
Җебенең төйгән йире таркалмастай.
Хасидләрнең йөрәкләре салмакланды,
Кирәсе[7] авыр булды тарталмастай.

Батырларның кылычындан каяу чыкды,
Кайтадан эшкә кереп ялганмастай.
Аерылдылыр күп хасидләр әдәбендән –
Хасыйле тәкәбберлек сәбәбендән;

Мөганид күркәм йиргә күзен салмай –
Мәкъбулатка тәмәррөн гадәмендән.[8]

[1] Сәрхәбадлы – авыручан, чирләшкә.
[2] Әсмаэи мөстәрүдән җәмал ачып – яшерен исемнәрдән матурлык ачып.
[3] Койын – өермә, җил-давыл.
[4] Хөҗҗәт – документ, аргумент.
[5] Мөддәга – претензия, дәгъва.
[6] Остайы сылу – сылу оста (уңган оста).
[7] Кирә – төялгән йөк.
[8] Мәкъбулатка тәмәррөн гадәмендән – кабул ителмәгәннәргә/

***

Адәм кямил булмады кайнап пешмәй,
Мәхәббәт фәнҗанендән[1] шәраб эчмәй.
Дошманлар хабаләне[2] салыа карай –
Тургайның тозагына лачын төшмәй.
Һавада ул бер шоңкар әйләнә очкан,
Без йөрәмез кара коштай эзләп тычкан;
Төлкеләр анда чыдап тора алмайлар,
Гүя бер киң апандан[3] йөрәге очкан.
Без сатдык меллалыкның коры атын,
Бездән артык яулыклы дөрест хатын;
Күңелмезне бер сындырып еламаймыз,
Уйланып гарасатның вәкафатын[4].
Ашкан бер галим чыкса – яманлаймыз,
Мәҗлесне гайбәт илән тәмамлаймыз;
Эшемез йә изтиһза[5], йә хәкарәт,
Үземезен һәр гайбдән амандаймыз[6].
Яхшыны сүккән илән аты китмәс,
Яман сүзнең күңелдән даты[7] китмәс;
Саф алтынны нәҗескә буяу илән
Нәҗес китәр алтынның заты китмәс!
Кыйсык ук аткан менән туры китмәс,
Күңелдән яман сүзнең куры китмәс,
Котырган эт һава карап өргән менән
Асманда торган айның нуры китмәс!

*Акмулла*[8]

*1892*

[1] Фәнҗан – чынаяк, касә.
[2] Хабалә – ау, тозак.
[3] Апан – аю яки бүре өне; җимерек кое чокыры.
[4] Вәкафат – киләчәк.
[5] Истиһза – көлү, мыскыллау.
[6] Амандаймыз – исән кебек тоябыз; азат шикелле сизәбез.
[7] Дат – кер, тап; кимчелек.
[8] Акмулла. Шигырьләр / төз. М. Госманов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 271 б.

## Мәрҗани хәзрәтләренең кабере янында

Нинди тәэсирле күңелгә мондагы кабер яны
Чөнки мәдфүн[1] монда милләтнең бөек каһарманы,
Без онытмыймыз сине әй мөхтәрәм карт пәдәремез,
Рәхәт булсын җайыңыз[2] һәм нурлы булсын кабереңез.

Сез вафат җисмән[3], мәгәр мәгънән[4] әбәд[5] вафат түгел,
Сезне тәкъдир әйли, тәгъзиз кыла[6] һәрбер пакь күңел.
Күп терекләрдән[7] мөкаддәм әлдә[8] сез остаз әле,
Барчасындан да гыйлем бабында сез мөмтаз әле,

Һич югалмас дөньядан юлбашчы ул асареңез,
Юк хәзергә без татарда мисленез, әмсаленез,
Сез бит ул чакларда бер ялгыз ачып гыйльми җиһад,
Калдыңыз әгъда вә җөһһаль эчрә мин көллил-җиһат[9].

Инде уйганды бу милләт дә хәзер ачды күзен
Аңлыйлар әһле фазыйльнең әфкярен, әйткән сүзен.
Бәс, онытмас сезне милләт исдә һәрбер хөснеңез,
Һич югалмас дөньядан ул шанлы, данлы исмеңез.

*Н. Думави*

*Шигырь «Йолдыз» газетасының 1912 елгы 24 июль (№860) санында дөнья күргән.*

---

[1] Мәдфүн – җирләнгән.
[2] Җайыңыз – урыныгыз.
[3] Җисмән – тән белән.
[4] Мәгънән – рухи яктан.
[5] Әбәд – мәңге.
[6] Тәгъзиз кыла – олылый.
[7] Терекләрдән – исәннәрдән.
[8] Әлдә – әле дә.
[9] Калдыңыз әгъда вә җөһһаль эчрә мин көллил-җиһат – һәряктан дошманнар һәм җаһилләр (наданнар) арасында калдыгыз.

## Шиһаб хәзрәт

Һәрбер имам бездә койрык булган чакта,
Койрык сүзе безгә бойрык булган чакта,
Фәлән сәләф[1] фәлән әйткән, фәлән бул, – дип,
Җаһил[2] мулла әмер бойрып торган чакта, –

Чыкты, ахры, бездән дә бер бөтен кеше,
Яхшы аңлап, тәкъдир итү[3] читен кеше;
Татарда да гыйрфан[4] уты кабынганны
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.

Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул – шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.

Ул итсә дә хәдис, аятьне күп нәкыль[5],
Булып бетми аның гакълы нәкыльгә[6] кол;
Инсан дигән шәрәфле бер мәхлукта[7] ул
Бар дип белә хаким гакыл вә хөр гакыл.

Дәлили итә «Тәзәккәрү!» аятьләрен[8],
Раушан итә шул аятьнең һәр якларын;
«Тәфәккәрү!» аятьләрен[9] таяк итә
Тик белгүче муллаларга тамакларын.

---

[1] Сәләф – борынгы галимнәр.
[2] Җаһил – надан.
[3] Тәкъдир итү – бәя бирү.
[4] Гыйрфан – аң-белем.
[5] Итсә ... нәкыль – дәлил итеп алса да.
[6] Гакълы нәкыльгә – акыллы бүтәннәр сүзенә.
[7] Мәхлук – *монда:* кеше дип аталган олы зат.
[8] «Тәзәккәрү!» аятьләрен – «Искә алыгыз!» дип башланган аять күздә тотыла.
[9] «Тәфәккәрү!» аятьләрен – «Уйлагыз, фикерләгез!» дип башланган аять күздә тотыла.

Аңлангачтын Коръәндәге бик күп серләр,
Үз-үзеңдән агаралар дини керләр;
Бу эшләргә Шиһаб хәзрәт сәбәп диеп,
Даһи кулын үбә башлый күп мөнкирләр[1].

Кемнән алдык дин фикрендә истикълялне[2]?
Кем ташытты ушбу бәхет, бу икъбальне[3]?
Ничек өздек «уйлауда да» коллык җебен? –
«Хәзрәт»тән ул безгә мирас булып калды.

Чыкты, әлбәт, бу даһигә сәфил[4] дошман;
Чыккан дошман мәгълүб булып[5] чыкты эштән.
Олугълыкта, өстенлектә Шиһаб хәзрәт
Этләр буе җиталмаслык җиргә кичкән.

Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм,
Шәрәфәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм;
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне
Мәхшәргәчә телләр сөйләр. Язар каләм!

*Шигырь «Аң» журналының 1913 елгы 2 нче (1 гыйнвар) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Текст басмага Г. Тукай «Әсәрләр»енең алты томлы академик басмасының II томыннан (2011) алынды.*

[1] Мөнкирләр – монда сүз кабердә сорау алучы ике фәрештә турында.
[2] Истикълялне – иреклелекне.
[3] Икъбальне – якты киләчәкне.
[4] Сәфил – түбән, әшәке.
[5] Мәгълүб булып – җиңелеп.

## Остазы әгъзам Мәрҗани хәзрәтләре

Төн иде ... йоклый идек, безне уятды таң кебек
Шул кадәр каты йокы баскан иде безне элек.
Без һаман йоклый идек, ни чаклы таңлар атса да,
Шад кояш иртән чыгып, мең мәртәбә ул ятса да.

Без каты йоклый идек, таңлар килеп уйгатса да.
Таң белән бар дөньяны кошлар өне яңратса да.
Безне каплаган иде бит шулкадәр гафләт, йокы.
Мәңге уйганмас идек без, башкалар уйганса да.

Бик каты йоклыйбыз, без бөтенләй онытылып.
Сизмичә һәр нәрсәне хиссез булып, җансыз булып.
Мәнге без йоклар идек таңдай, туып ул көлмәсә,
Шулвакытда бездәге гафләт йокысын күрмәсә дә.

Без һаман йоклый идек, безне уяткан изге җан:
Шул мөбарәк зат – матур, ал таңда яңраучы азан.

*Мәрҗани шәкерде – М. Әбрар Сәгыйди*

### Мәрҗани хәзрәтләре

Без шимальдә, каршымызда боз тавы – боз диңгезе –
Коточыргыч, куркыныч күренешләре торган иде.
Мәңге кышы, үткен, ачы җил, котырына боз диңгезе
Агач, үлән, чәчәкләр – булса да кор[ы]ган иде.
Җенләнә карлы буран, төн һәрвакыт, юк көндезе.
Шундый төнләр безне көндән бихәбәр токтан иде.
Анда бер өй, монда бер өй кар астында ялгызы
Юк чыгар хәл – безне шул өйләр тәмам йоткан иде,
Кайсымыз шунда суыкдан тилмереп каткан иде.
Шул вакытда бер гали зат килде дә һәм әйтде: «Сез,
И туганлар! Нишлисез? Кузгалыңыз да, әйдәңез,
Ятмаңыз монда болай. Бар бит җиһанның көнләре,
Җәй дә бар. Шәфкатьле ул, кыска аның бик төнләре.
Анда юк кар: бакчалар, гөлләр, иген басулары ...
Ялтырап ага, көмешдәй, елгаларның сулары.
Юк суык һәм ак аю – шәфкатьле анда барысы да:
Иҗтиһад итсәк, сиңа чын дус була һәркайсы да!».
Шул килеш безне тигез, яп-якты юллар буйлата –
Сөрде алга ул кара тормыш эчендән шул ата.
Шунда белдек бу җиһанда җәй һәм ак көнләр барын.
Иҗтиһад итдек – җөреп чыкдык тирән карның барын.
Шундый эшләр эшләгән зат кем соң ул? Ул – Мәрҗани.
Шул менә ул гали затның безгә биргән мәрҗәне.
Әй гали зат! Хезмәтең зур, белмиләр кадереңне тик
Тукталам, нурга чумырсын бер Ходай кабреңне дип.

*Мөгаллим Габделхәй Габдерахман (Казан – Мәрҗания)*

*Шигырьләр «Кояш» газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар (№601) санында басылганнар.*

*Басмага Гөлчирә Ханнанова әзерләде*

## Мәрҗани хәзрәтләре

Гакыллар чолганып торган вакыт чылбыр, богау берлән,
Хакыйкать былбылы рәнҗү, газаб чикгәндә ау берлән.

Бөтен баш да фикерләр йоклаганда һич тәфәккерсез
Кешеләр хакны җуйганда коры тәкълид, сорау берлән.

Менә шул чакда безнең зур даһи айдан туып чыкды.
Ачы үткен сүзе берлән хорафатны сөреп екды.

Гакылларны чалып торган явыз тәкълид бавын өзде.
Хакыйкать диңгезендә безгә ак нурны чәчеп йөзде.

Хорафат золмәте[1] төнне бетерде, таңны тугдырды.
Хорафат золмәтен бетереп, кояшны, көнне булдырды.

Хәзер бездән даһи хәзрәт мөкаддәс, пакь дога итде
Хәзер алдыңда тезләнгән дип бел каршы углыңны...

Хәзер әйткән мөкаддәс фикереңә тик пакь иман итде.
Кабул иткәндә хазир пакь сүзең барымыз туган инде.

Синең пакь сүзләрең алдыңда күб дошман икән ул чак.
Даһи хәзрәт хазир бел дустларың тулган җиһан итде.

Бәхетле син, даһи хәзрәт! Гөл көрси өстендә,
Хәзер хак сүзләрең угрында корбан барча җан инде.

*Г. Сөнгати*

*Шигырь «Аң» журналының 1915 елгы 1 нче санында басылган.*

*Текстны басмага Ләйлә Гарипова әзерләде*

[1] Золмәте – караңгылыгы.

## Эчтәлек

Кереш........................................................................................ 5

**I бүлек**
**Шиһабетдин Мәрҗанинең**
**иҗат мирасыннан**

Шиһабеддин Мәрҗанинең Оренбург Диния нәзарәтенә басма Коръәндәге хаталарны төзәтү турындагы гаризасы ........................................................................................ 8

Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең үз каләме илә язылган гыйльми вә дини мәкаләсе............................... 15

Важные пользы и дополнения, связанные с наукой о Коране и списком свитков ʻУсмана............................. 22

Очевидная истина относительно достоинств предписаний Ислама ........................................................................ 78

**II бүлек**
**Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлеге хакында**
**вакытлы матбугат**

Йөзьеллык юбилее көннәрендә... 87

*Х.Үтәки.* Мәрҗани хакында җавабым............................ 90

*Ризаэддин бине Фәхреддин.* Идарәгә мәктүбләр: Габделхәбир әл-Мөслими вә Мәрҗани хакында............. 96

*Хаҗцизадә.* Дамелла Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең намын таәбәд итү хакында................................................ 99

Шиһаб хәзрәт Мәрҗани җәнабләренең юбилейсы мәсьәләсенә даир.......................................................................... 101

*Г.Гомәров.* Мәрҗани хәзрәтләренең юбилеена даир. Красноярдан........................................................................ 102

*Ф.Госманов.* Мәрҗани хәзрәтләренең юбилеена даир.... 105

*Г.Баттал.* Шиһабеддин әл-Мәрҗани.............................. 106

*Г.Гыйсмәти.* Мәрҗани хәзрәтләре кем иде?.................... 112

*Гали Хәбибрахман.* Соңгы заман мөселманнары арасында гыйлем таралмау хакында Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең фикере................................ 119

*Ә.Вәлиди.* «Мәшһүр адәмнәр вә олуг затлар» сериясеннән. Мәрҗани........................................................... 123

*И.Бикколов.* Мәрҗани юбилее мөнәсәбәте илә............... 127

Шиһабеддин әл-Мәрҗани................................................ 130

*З. Кадыйри.* Бу көн Мәрҗани туды................................. 133

«*Мөхбир»*. Мәрҗани юбилейсы....................................... 154

«*Мөхбир»*. Мәүлид һәм Шиһаб хәзрәт кичәсе................ 156

*Мәхмүдфуад.* Шиһаб хәзрәт........................................... 157

Шиһаб хәзрәт юбилее...................................................... 162

Бөек остаз вә углымыз Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең йөзьеллык бәйрәме.................................. 164

*Ш. Шәрәф.* Шиһабеддин әл-Мәрҗани............................ 167

Шиһаб хәзрәт.................................................................. 173

*Н.Гасрый.* Беренче мөәррихемез Шиһабеддин әл-Мәрҗанинең бөек рухының тынычлыгы өчен тәңрегә ялварамыз........................................................... 174

*И.Бикколов.* Шималь төрекләренең каһарманы.............. 176

*Я.Хәлили.* Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләре............ 180

*Ә.Вәлиди.* Мәрҗани хакында кечкенәлегемдә язган бәгъзе нәрсәләрем мөнәсәбәте илә................................. 190

*Ш.Әхмәдиев.* Юбилей көне............................................ 198

*Г.Чыгътай.* Шиһабеддин әл-Мәрҗани хакында фикерләр.......................................................................... 204

*Ш.Хөсәенев.* Шиһаб хәзрәт........................................... 213

*Ә. Вәлиди.* Мәрҗанинең яңа мәдәни хәрәкәтемезгә мөн әсәбәте....................................................................................... 219
*К. Тәрҗемани.* Олуг мослих вә мөҗәддимез.................. 227
*С. Вахиди.* Мәрҗани көтебханәсе һәм аның соңгы язмышы........................................................................................ 231
*Р. Дәүләткилде.* Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле................................................................................................ 242
Шиһабеддин хәзрәт кичәсе............................................... 243
Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәт кичәсе......................... 245

## III бүлек
## Хатлар

*Г. Вилдан.* Мәрҗани мәктүбләре...................................... 249
Хөсәен Фәезхановның Ш.Мәрҗанигә хатлары............... 252

## IV бүлек
## Мәрҗани турында шигъри сүз

*Акмулла.* Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе.... 273
*Н. Думави.* Мәрҗани хәзрәтләренең кабере янында...... 290
*Г. Тукай.* Шиһаб хәзрәт.................................................... 291
*М. Әбрар Сәгыйди.* Остазы әгъзам Мәрҗани хәзрәтләре............................................................................................ 293
*Габделхәй Габдерахман.* Мәрҗани хәзрәтләре............. 294
*Г. Сөнгати.* Мәрҗани хәзрәтләре................................. 295

ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ
поиски и открытия

Выпуск 6

Компьютерная верстка Д.Р.Галиуллиной
Дизайн обложки А. В. Булатова

Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л.18,7. Тираж 500 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20